1995 елның
июленнән чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

Мәдәни җомга

№ 1
21 июль
1995 ел

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Миңтимер ШӘЙМИЕВ.* Мәдәниятебез күгендә тагын бер йолдыз кабынды.

3 *Рахмай ХИСМӘТУЛЛИН.* Язучы язганнан кеше үз җанына шифа-дәва ала, өзелгән өметен ялгый, сүнгән күңелен кабыза.

5 *Мансур ХӘСӘНОВ.* Болгарчылар вәсвәсәсе татар халкының санын киметүгә китерде.

10 *Булат СОЛТАНБӘКОВ.* Шымчылар шагыйрь Сириннең Атласов фатирында советка каршы язган шигырьләр укуын хәбәр итәләр.

12 *Мофти Габдулла хәзрәт ГАЛИУЛЛА.* Бисмил-ләәһир рахмәәнир рахиим. Әгүүзү биллааһи минәш-шәйтан ир-раҗиим. Динебездә олугы һәм изгесе булган җомга көнне чыга башлаган газетаның Аллаһыдан килгән хак дин белән гамәл кылуын телим.





ИЗГЕ КӨННЕҢ ИРТӘСЕНДӘ ЧЫКТЫК ОЗЫН СӘФӘРГӘ...

Хәерле сәгатьтә!

Хөрмәтле «Мәдәни җомга» редакциясе хезмәткәрләре!

Хөрмәтле укучылар!

Мин сезне яңа газетаның беренче саны чыгу белән чын күңелдән котлыйм. Күп гасырлык мәдәниятебез күгендә тагын бер йолдыз кабыну мөмкинлеге туган икән, аны, чыннан да, йолдыз итү сездән тора.

Мин ышанам, сез рухи, физик матурлык дөньясында халкыбызны, аеруча яшьләрне әйдәп баручылар булырсыз. Күпмилләтле халкыбызның гүзәл әхлакый кануннарын алга сөреп, яңа газета һәркем тарафыннан яратып укылсын, гыйбрәт, тәүфикъ, инсаф, шәфкать чыганагына әверелсен иде, дип телим.

Безнең заман — бөек сынау заманы. Аны намус белән үтик, чал тарих битләренә туган халкыбызның рухи йөзенә кызыллык китермәслек гамәлләр язылып калсын. Бу изге бурычларны башкаруда милләтебез зыялыларына олы терәк булыгыз!

Юлыгызга ак җәймә!

Татарстан Республикасы Президенты
Минтимер ШӘЙМИЕВ.

3.VI.95 г.

МОСКВА 1/103 67 7/7 1830-

КАЗАНЬ БАУМАНА 19 РЕДАКЦИЯ ЕЖЕНЕДЕЛЬНИКА ''КУЛЬТУРНАЯ ПЯТНИЦА''
ЗИННУРУ МАНСУРОВУ-

ПОЗДРАВЛЯЕМ ВСЕХ ПИСАТЕЛЕЙ ВСЕ ТВОРЧЕСКИЕ СОЮЗЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН РОЖДЕНИЕМ НОВОЙ ГАЗЕТЫ МЕДЕНИ ЖУМГА ТЧК ЕЖЕНЕДЕЛЬНИК ТИРЕ ЗАМЕЧАТЕЛЬНОЕ ПРИОБРЕТЕНИЕ ДЛЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ ЗАЛОГ ЕЕ УСПЕШНОГО РАЗВИТИЯ ТЧК ПУСТЬ ЖУМГА ПОИСТИНЕ СТАНЕТ ПРАЗДНИКОМ ДЛЯ ЧИТАТЕЛЕЙ И АВТОРОВ ТЧК ЖЕЛАЕМ УСПЕШНОЙ РАБОТЫ РЕДАКЦИИ НАДЕЕМСЯ ЧТО ЕЖЕНЕДЕЛЬНИК СТАНЕТ ПОПУЛЯРНЕЙШИМ ИЗДАНИЕМ-МЕЖДУНАРОДНОЕ СООБЩЕСТВО ПИСАТЕЛЬСКИХ СОЮЗОВ МИХАЛКОВ ПУЛАТОВ ЧУЕВ ГАМЗАТОВ АЛЕКСЕЕВ КОЗЛОВСКИЙ СОЛОУХИН ГАНИЕВ-

Казан,
Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга»
атналыгы редакциясе,
Зиннур МАНСУРОВКА

Татарстан Республикасының һәммә язучысын, барча иҗат берлекләрен «Мәдәни җомга» исемле яңа газетаның дөньяга килүе белән тәбрик итәбез! Атналык басма — татар әдәбияты һәм сәнгате өчен искиткеч казаныш, мәдәниятнең нәтиҗәле рәвештә үсә баруын тәэмин итешүче бәрәкәтле җирлек. «Мәдәни җомга»ның чыга башлавы газета укучылар һәм авторларның чын бәйрәменә әверелсен. Редакциягә иҗат уңышлары телибез, атналык газетаның бик тә популяр басма булачагына ышанабыз.

Мәскәү, Халыкара язучылар берлекләре бердәмлеге, Сергей МИХАЛКОВ, Тимур ПУЛАТОВ, Феликс ЧУЕВ, Рәсүл ГАМЗАТОВ, Михаил АЛЕКСЕЕВ, Яков КОЗЛОВСКИЙ, Владимир СОЛОУХИН, Виль ГАНИЕВ.

Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык артисты Илһам ШАКИРОВ:

Җомгалар хәерле! Илһам абый. И. Шакиров

Татарстанның һәм СССРның халык рәссамы Харис ЯКУПОВ:

Минемчә, татар сәнгате-әдәбиятына багышланган бер атналык газетаны күптән чыгарырга кирәк иде. Бу турыда 50-нче елларда «Кызыл Татарстан» газетасында мин мәкаләдә язып чыккан идем һәм аны - ул идеяне - безнең рәссамнарда, күп язучыларда яклап чыкканнар иде. Мин «Мәдәни җомгага» хәерле юл телим...

Якупов 11.VII.95 ел

Татарстан Республикасының
Дәүләт суверенлыгы турында декларация
кабул итүнең 5 еллыгына бәйле рәвештә
Татарстан Республикасының Дәүләт Советы

МӨРӘҖӘГАТЕ

Татарстан Республикасының Дәүләт суверенлыгы турында Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан Декларация кабул ителүгә 1995 елның 30 августында 5 ел була. Декларация күпмилләтле Татарстан халкы исеменнән игълан ителде, һәм ул дәүләтчелек үсешенә, социаль-икътисадый алгарышка, милли-мәдәни яңарышка халык өметен чагылдыра.

Республиканың барлык гражданнарының, милләтенә, дини мөслегенә һәм социаль хәләтенә карамастан, хокукларын һәм ирекләрен үтәүнең демократик принциплары Декларациянең төп нигезен тәшкил итә.

Декларация Татарстан Республикасы Конституциясен һәм җәмгыятьтәге демократик үзгәртеп коруларга юнәлдерелгән мөһим законнар кабул итү өчен нигез булды.

Декларация Татарстан Республикасында милләтара татулыкны һәм халыклар дуслыгын тотрыклыландыручы фактор һәм гарант булып тора.

Декларациянең төп идеяләре көннән-көн заманча һәм мөһимрәк була бара. Бу Татарстан Республикасының яңа дәүләти-хокукый статусының һаман торгызыла баруы һәрдаим аның Россия белән үзара мөнәсәбәтләренең «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне бүлешү һәм вәкаләтләрне үзара тапшырышу турында» Шартнамә нигезендә үсүе белән раслана.

Дәүләт органнарының эшчәнлеге Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килерлек итеп хокукый дәүләтнең мөһим принцибы — закон чыгару, башкарма һәм хөкем хакимиятләре бүленеше нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген җайга салу һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен ныгыту халыкның хокукый һәм социаль яклanышын, төбәктәге тынычлык һәм тотрыклылыкны тәэмин итә.

Биш ел эчендә Татарстан Республикасы төбәкара бәйләнешларын киңәйтте һәм ныгытты, чит илләр белән халыкара элемтәләрнең һәръяклап үсешенә нигез салды. Бөтен кешелек дөньясы Татарстанны гомумтанылган халыкара хокук нормаларын хөрмәт итү нигезендә хезмәттәшлек итү өчен ачык һәм бөтендөнья җәмәгатьчелеге белән үз мөнәсәбәтләрен урнаштырырга әзер торучы дәүләт буларак белде.

Дәүләт корылыш өлкәсендә һәм дәүләтара, милләтара мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасының Дәүләт суверенлыгы турындагы декларациясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә мәдәни юллар белән җайга салу нигезендә республикабыз ясаган адымнарның хакыйкый федерация төзүдә төп таяныч булуларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы нык ышаныч белдерә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасының Дәүләт суверенлыгы турындагы декларациясенә үзенең тугрылыгын раслый, аны гамәлгә ашыру өчен бөтен көчен куярга әзер икәнлеген белдерә. Татарстан Республикасының дәүләтчелеген ныгытуда ярдәм итәргә, халык иминлеге өчен сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрдә актив катнашырга өндәп, без Татарстан Республикасының барлык гражданнарына, барлык иҗтимагый һәм сәяси көчләргә мөрәҗәгать итәбез. Халыкларның бердәмлеге, тупланганлыгы һәм иҗади хезмәт — Татарстан җирендә икътисадый алга киткән демократик дәүләт төзүнең төп шарты ул.

М ӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мөхтәрәм милләттәшләр, газета укучылар!

Менә сез атналык эш-гамәлләргә нәтиҗә ясау, пакьләнү-чистарыну көне булган бәйрәм дәрәҗәсендәге җомга иртәсендә әле буявы да кибеп өлгермәгән өр-яңа газетаны кулыгызга алдыгыз. Кулыгыз җиңел булсын! Һәрбер гамәл башында һәм ризык-төгам җыяр алдыннан бисмилла әйтү гадәте бар. Ышанам: мондый изге сүзне башкарак өммәттәге кардәшләр дә кабатлар, чөнки бүген туган телебезнең сирәк килә торган үзенчәлекле бәйрәме: татар зыялылары хыялланган махсус атналык басма — «Мәдәни җомга» газетасының беренче саны дөнья күрде!

Күңел никтер ышанып бетми: төзү-коруларына караганда җимерүләре күбрәк булган бүгенге җаһиллек заманында күпмедер дәрәҗәдә «кирәкмәгән артык муллык»ны хәтерләтүче затлы басма чыга башласын әле! Мәгънәсез орышта шәһит китүче чечен туганнарыбызның кулында Коръән дөрләп янганда, халыкларыбызның тәрҗемәи хәле теркәлгән кабатланмас ельязма-китаплар, вәхшиләрчә черетелеп, җиргә иңдерелә барганда, «кешә рухы инженерлары», дәүләт кайгыртуыннан тибәрелеп кадерсезгә әйләнгәндә...

(Ахыры 24 нче биттә).

Төркиянең Мәрмәрә университеты профессоры Надир ДӘВЛӘТ:

«Мәдәни җомга»ның хөрмәтле язучылары һәм укучыларына!

Казанга килеп төшкәч, минә бәлки дә иң шатландырган тәрәккыят «Мәдәни җомга» исемле бер әдәбият-сәнгать атналыгының дөнья күрә башлавы турындагы хәбәр булды. Бу мөһим эшне башкаручыларны чын күңелдән котлыйм һәм мәңгелек уңышлар телим.

Надир Дәвләт
5.07.1995
Истанбул - Төркия

МИН ӘЙТТЕМ...

Рахмай ХИСМӘТУЛЛА

ЯШЬНӘ, ЯЗУЧЫ!

Караңгы сахралардагы сыман төн карасында яшәү чытырманлыклары ар...ыннан тагын зарлану-ыңгырашу...ар, сыкрау-сыктау авазлары ...шетелә.

Кеше җаны, мин алдана-алдана ...дым инде, бик-бик арыдым ин...е, мине башка җәберләмәгез, ми...ем хәзер башка беркемгә дә ки...әгем калмады, дип тынычта кал...ыруларын ялвара.

Бу авазлар арасында вакыт-ва...ыт язучыныкына охшаган сыкра...лар да шөйләнә.

Бәгъремнән өзелеп төшкән ...ол-ганҗә сүзләремнең бәһасе су...ыр бер тиен. Аларны инде бер...айчан да китаплар итеп басты...ып чыгармаслар, олуг затлар, ...аф күңелле балалар иҗат чиш...әсеннән авыз итмәсләр.

Сулышым капты, тыным кысыл...ы. Яшьлек хыялларым тәмам сү...еп калды. Күңелем төште, рухым ...ынды, башым катты. Шигырь та...агына тынчу юшкын, сасы ис ...тырды.

«...Бетте көч, сынды кылыч
– шул булды эш...»

Бу зарларны ишеткәч, кырыс ...өнья, үз-үзен яклый вә саклый ...алмаган һәрбер җан иясе, һәрбер ...ни-нәрсә үләргә тиеш, ди... Һәм ...ыннан да алар арасында ...үлем-китемнәр бик ешайды. Китә...ләр милләтнең асыл уллары, бә...хиллешми дә китә баралар... Җы...ы сүзләр дә әйтә алмый кала...быз...

А-а, тайгак ярлардан агып кит...кән бу дөнья язучы дигән затлар...ны гадел яшәү кырларыннан ку...алап, сөреп, шулай ук исерткеч ...ыкыннарында, агулы дулкыннар...: пыран-заран китереп, харап ...итеп бетерермени?!

Шулай итеп дөньяның имансыз ...агымы чын хакыйкать һәм асыл ...натурлык илчыларын вә сакчыла...рын себереп алып китеп, тилереп ...ган бүгенге тормыш утларына ...итеп томырырмыни?!

Юк, тукта, әгәр бүген язучы, аны ...хакимнәр күрми, халык кирәк са...намый дип чигенеп, рухи дау мәй...даннарын ташлап киткәч, союнең ...ала-кырларында, тормыш киңле...кләрендә җырлар тынып, моңарчы ...ылы, ягымлы сүзләрдән йомшап, ...ушлык алып яшәгән җаннар то...ташташ булып калса, нишләрбез?

Шагыйрь сүзеннән мәхрүм кал...ган моңнар кинәт боз сөңгеләре ...булып катып концерт залларын ...караңгы мәгарә итсә, нишләрбез?

Балалар дөньясында әдәп сүз...ләрен сүгенү, усаллык, өшәкелек ...алыштырып, дөнья түзеп тора ал...маслык саташу-мәхшәргә әверел...ә, нишләрбез?

Базар казаннарында шашып вә ...ысып кайнаган бу дөнья язучы ...сүзеннән дә мәхрүм калса, рәнҗе...ген Тукай кабереннән торып басар ...а:

...Күзгә төн. Мин йоклый алмыйм.
...й түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең кур...
...кусыннан ил җылый, - · дип шаш...
...ын күкрәү булып күкрәр сыман.

А-а, юк, язучы сүзенең кирәк...сезлегенә, юкка чыгуына мин мәңгә дә ышанмыйм. Нинди генә чорлар, нинди генә мәхшәрләр кичеп килмәгән ул безгә?!

Юк, язучы һәм язучылык беркайчан да үлмәде һәм үлмәячәк. Чөнки ул әле күрәзәче, әле камчы, әле багучы, әле табибчы, әле җыручы булып, билгесез чорлардан яралып чыгып, һуннар һәм соңнәр дәверләрен бөек татар теленә мәңгеләштергән. Болгар дип гайрәтләнгән гасырларыбызда да халыкның яшәү рухын әкият һәм дастаннарда таза һәм имин саклап, аны киләчәк буынга тапшырган.

Үткәнебездә Бөек Болгарстан барлыкка килгән икән, ул иң әүвәл яшәешнең рухи чыганагы, тәртибе, әдәбе Рухстан иленнән башланган.

Бу рух дәүләтле чорда мәшһүр Кол Гали булып калыккан.

Бу рух дәүләтен җуйгач та аңаят, чит урыс хөкүмәтеннән каткан икмәк валчыгы таммаса да, берниндә иркәсез һәм кадерләүсез калгач та, Кандалыйлар һәм Иманилар, Мәрҗаниләр һәм Акмуллалар булып хәерчелекнә һәм караңгылыкны ерып чыккан.

Рух эстафетасы гасырлардан гасырларга таба исән-аман тапшырылган. Аны бернинди кара реакция чорлары да, бернинди ачлык вә авырулар да, кыерсытулар вә кимсетүләр дә җиңә һәм сындыра алмаган. Этләр өрә торган, сандугачлар әллә нинди билгесез сер-сихер белән сайрый-сайрый халык күңелендә кала килгән...

Хәтта явыз Сталинның мәхшәр тегермәннәре дә бу рухларны сындыра, тарта, юкка чыгара алмады. Кансыз тиранны «мактый-мактый» булса да, бу рух барыбер исән калды. Бу рух фашист төрмәсеннән Җәлилләр булып бәреп чыгып, бөтен дөньяны хәйран калдырды.

Кара син, без белгән социализм чорларында да Рухстан вәкилләре Бәширов һәм Әмирләр, Еники һәм Төхфәтуллиннар, Әпсәләмов һәм Ахуновларның әсәрләре, кулдан-кулга йөреп, халыкка рух бәйрәмнәре ясыйлар иде, җаннарны яшәү нуры белән сихерлиләр иде. Рухстан безне Гыйлаҗевның трагик фәлсәфәсе булып тетрәндерде, Мәһдиевнең үзәк өзгеч якты шигъри моңы булып нурландырды.

Туфан, Хәким, Афзал, Юзеевларның безне милләт буларак тагын да тирәнгә төшеп уяткан шифалы һәм яшенле яңгырлары халык бәгыреннән бернинди явыз кочләр дә кире чыгарып ташлый алалмас инде...

Ил-заман яралы ерткыч сыман бәргәләнгән, изге каннар коелган, дөньясы асты-өскә килеп иңрәгән мондый чорларда Ходай тарафыннан аеруча рәнҗетелгәннәр — дәрвишләр, диваналар хакыйкатьне ярып әйтеп бирә торган булган. Әмма бу юлы алар да, милләтчеләр дә, һәрторле экстрасенслар да әйтеп бирә алмаганны тагын язучылар үз өсләренә алдылар, черреп таркалып яткан җәмгыятьнең борылыш юлларында, утын ташламаган Прометейдай, вөҗдан маяклары булып калыктылар.



Син, Язучы, сине ашсыз, укучыны китапсыз иткән бу болганчык мәлдә тагын юксылларны яклау ягына бастың.

Әгәр дә бүген үз-үзләрен һәм кеше күңелен аңлап бетермичә баеган байлар: акчасыз калган гаиләләрнең ызгыш-талашларын, яшь кызларның ярлы аналарыннан матур киемнәр сорап ялваруларын, соңгы сыныктан мәхрүм карт-корыларның үлем алды ыңгырашуларын, күкрәк сөте кипкән яшь аналарның өнсез сыкрануларын, сабыйларның ими сорап үксеп елауларын ишетсәләр, җиде төүлек буена шуны тыңласалар, җиде төн урталарында җиде юл чатларына чыгып, җидегән йолдызларга карап, җитмеш җиде дога укыгач, кеше ризыкларын байлык итеп мәңгә дә үзләренә җыймаска антлар итәрләр иде... Чөнки аларның байлыгы беркатлы мескеннәрне алдау юлы белән генә, хәйлә юлы белән генә, сәүдә юлы белән генә талап тупланган хәрам байлык иде.

Син, Язучы, ил-көн өстендә өметсезлек куерганда гасырларны ялгаучы Равил Фәйзуллин булып:

Кануннар шартлап ярылды,
Ил-җирләр тетрәнде.
Әтрәк-әләмнәр кәрәйде,
Хезмәтле — бөкерәйде, —

дип хакыйкатьне ярып салдың.

Син, Язучы, бүген батырҗан шагыйрь Разил Вәлиев булып, үч, ачу, нәфрәт, дошманлык ярларыннан ташып чыккан Чеченстандагы вәхшиләргә кан коюга каршы чаң кагып, кыядай күтәрелдең.

Син, Язучы, бүген гайрәтле бәркет канатларыңны кага-кага, Туфан Миңнуллин булып, яшәешнең иң тирән агымнарын, иң нечкә нервыларын саклап, Туган Телне һәм Вөҗданны, ваклык һәм сатлыклардан аралап, иң алгы биеклеккә чыгарып бастырдың.

Әнә шулай Кол Галиләрдән алып туачак Ирекле Галиләргә таба бөек рух Иделе ага. Билгеле һәм билгесез каләм тибрәтүчеләр, танылган һәм танылмаган язучылар, күренеклеләр һәм атаклылар, бөекләр һәм даһилар барысы бергә, бер-берсен тулыландырып, ташлы, чокырлы рух кырларын җан нуры белән сөреп, маңгай тирә белән сугарып килделәр. Алар тудырган рух иле, рух Иделе, беркемгә баш имәс, беркем җиңә алмас әдәп Иделе үткәннән бүгенгегә, бүгеннән киләчәккә таба милли яшәеш булып туктаусыз агып ята һәм мәңгә шулай агачак та...

Дин һәм әдәп аерылгысыз булган кебек, иң бөек Кодрәт тудырган Коръән дә һәм әдәби китап та, якын бертуганнар булып, шушы милли Иделгә коя. Кешене бишектән алып кабергәчә шушы ике бертуган озата барганда гына кеше рухы бөтен һәм иләһи, моңлы һәм бәхетле була ала.

Әле бүген дә кеше үзе исемен атый алмаган хисләренең нәрсә икәнлеген язучыдан таба, аның язганыннан җанына шифа дәва ала, өзелгән өметен ялгый, сүнгән күңелен кабыза.

Чөнки язучы кеше — Рухының илаһият академиясен бетергән төп табибы ул. Бу табиб исән чакта, дөньялар ничек кенә тетрәнмәсен, яшәүнең мәңгелек кануны, рухи дөньяның бинаһая серле бинасы җимерелмәс, кеше язучы сүзе канатында чиксез киләчәккә юлын дәвам итәр...

... Юк, дөнья әле гел болай болганып кына тормас, бөтенләй изге хакимнәрсез дә яшәмәс. Язучының чын мәгънәсендә рух патшасы икәнлеген аңлаучылар да табылыр. Алар татар язучылары үзара аралашып иҗат итә торган иҗат йортлары да салып бирерләр, китапларын да чыгарырлар, җан әрнеп язганнарына җан асрарлык түләүләрне дә җәлләмәсләр.

Ә бүген Язучы, үз гаиләсен, балаларын, хәләл җефетен онытып төшеп тә, үз кайгыларын, фаҗигаләрен атлап чыгып, үз бәхетен кешеләр өчен яндырып, үз шатлыкларын сихерле сүзләр эченә сала-сала, кешеләргә иман, әхлак, әдәп, мәхәббәт итеп бүләк итүче изге җан, әллә нинди авыр төшенкелек чорнаг алган авыру дөньяны яшәртер чарасын эзли, халык рухын яшәү батырлыгына күтәрә, бәхетенә ышанычны һәм өметне кабат терелтә.

И, Язучы! Сафландыр сана син безнең бу бозык яшәвебезне, туры юл күрсәт адашкан вә саташканнарга! Сине ничек кенә сагыш сыкмасын, сине ничек кенә кайгы какмасын, син, кеше җаннарының иң яшерен рухларын, иләһи серләрен аңлаучы олуг зат, җырла әле таза яшәү һәм шокерана җырларын, тоташ гөнаһлардан яралып, котылгысыз моң эчендә торып калган бәндәләр тәүбәгә килсен!

Әй син, халык колы, дөнья фәкыйре булып торып калган Язучы, яшьнә әле бер ясалма караңгылатылган вә авырайтылган тормыш күкләрендә, күкрәсен Дөнья!

Яшьнә, Язучы, иң тәкәбберләрең дә, иң әллә кемнәрең дә бу бөтенкешелек аек яшәү кайгысы каршысында бик бәләкәй булып калып иман китерсен!

Яшьнә, Язучы, мортәтләр дә, иң явыз иблис җаннар да бөтен җир шары күләм иләһи яшәү нурына вә җырына күмелсен! Тазарсын җирләр, сафлансын һаваләр, мәрхәмәт вә шәфкатькә сусап зарыккан җан гөлләре ләйсән яңгырларында коенсын!

Яшьнә, Язучы, яшәсен ачлыктан вә вакыттан, дәүләттән вә хакимнәрдән өстен мәңгелек рух иле!

Яшәсен Рухстан!

ҖИДЕГӘН
ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР
5 6 7 1 2 3 4

Кремльдә мәчет төзеләчәк

Сүз Казан ханлыгы чорында Кремль биләмәләрендә булган Кол Шәриф мәчетен торгызу турында түгел, ә яңасын төзү турында бара. Сөембикә манарасы каршында, Казанның йөрәгендә зур чиркәүнең кукыраеп торуы милләттәшләребезнең горурлыгына тәэсир итсә дә, моңа тешне кысып булса да түзәргә туры килде. Инде безгә килеп ирешкән хәбәрләргә караганда, «Казан Кремле» тарихи-архитектура тыюлыгын булдыру барышында мәчет тә төзеләчәк. Әлегә аның төгаен кайда салыначагы билгеле түгел, шулай да Кремльдә мөселман гыйбадәтханәсен төзү тәкъдиме югары даирәләрдә яклау тапканлыгы мәгълүм.

Язучы улы министр булды

Күптән түгел Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев республиканың тышкы икътисади элемтәләр министры итеп Рәшит Ахуновны билгеләү турындагы Указга имза салды. Яңа министрның мәшһүр язучыбыз Гариф Ахуновның улы икәнен бәлки белмәүчеләр дә бардыр. Рәшит Ахунов Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлаган. Дәүләт эшенә билгеләнгәнче, ул Мәскәүдә Халыкара коммерция берлегенең генераль директоры иде. Эшмәкәрлек белән шөгыльләнсә дә, Рәшит мәдәнияттән бөтенләй үк аерылмады. Язучылар гаиләсендә үсүе (аның әнисе Шәһидә апа да әдәбиятчы) һәм үзенең дә Язучылар берлеге әгъзасы булуы нәтиҗәседер, күрәсең, Халыкара коммерция берлеге Россиянең күренекле музыканты Александр Кролл җитәкләгән джаз оркестрына акчалата ярдәм күрсәтеп килде, сәнгать тормышында башка игелекле эшләр башкарды. Хәзер үзебездә дәүләт эшенә керешкәч, Рәшит Ахуновның турыдан-туры милли мәдәният турында кайгыртучанлыгы бермә-бер артыр дип өметләнәсе килә. Гәрчә, тышкы икътисади элемтәләр министры булса да...

Өметләр өзелмәсен

«Борынгы Болгарның җылы җилләре» кинофильмы турында төрле хәбәрләр йөрде. Кайберәүләр ул фильм инде тумас борынүлде, кайсыберләре исә һаман да өметләнә иде. Менә соңгыларының өметен тагын да көчәйтеп җибәрүче хәбәр килеп иреште. Каян дисезме? Юк, Казаннан түгел... Чистайдан. Бирәдәге агач эшкәртү комбинатында әлеге фильмны төшерү өчен декорацияләр эшләнә башлады. Инде җәйләүнең киртә-коймалары әзер. Комбинат осталары җыелма күперләр, юрта корылмалары ясау белән мәшгуль. Борынгы ат арбаларын эшләү дә эшчеләрдән зур осталык таләп итәчәк, чөнки биеклеге 1,5 метр булган көпчәкләрне ясау өчен генә дә нинди зур түземлелек һәм маһирлык кирәк. Чистайлылар бу эшләрне вакытында һәм тиешенчә башкарып чыгарлар дип өметләнәбез. Ә менә беренче татар фильмын эшләүдә катнашучы башка осталар ышанычны акларлармы?..

Рәссам остаханәсендә

Рәссам Илдар Зариповны илдә белмәгән кеше юктыр. Хәер, ул бездә генә түгел, чит ил сәнгать белгечләренә дә яхшы таныш. Шулай булмаса, 1993 елда Германиядә аның шәхси күргәзмәсен оештырмаслар иде. Шул вакытта рәссамның күп картиналары сатып алынуы да аның иҗатына игътибарның зур булуын дәлилли.

Сез бу рәсемдә Рәсәйнең һәм Татарстанның атказанган рәссамы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илдар Зариповны «Ачылмаган чәчәкләр» циклыннан «Рәйхан» картинасын иҗат иткән вакытта күрәсез.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Аббасов Азат Зиннәт улы

Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

«Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Бармин Александр Петрович — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының балет солисты;

Илюхин Евгений Александрович — Татарстан Дәүләт симфоник оркестры артисты;

Кострова Елена Юрьевна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының балет солисткасы;

Кузнецов Валерий Анатольевич — Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артисты;

Ластовка Василий Иванович — Татарстан Дәүләт симфоник оркестры артисты;

Леонов Петр Юрьевич — Татарстан Дәүләт симфоник оркестры артисты;

Мирзануров Фәрит Фатыйх улы — Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең хор төркеме солисты;

Смирнова Анна Николаевна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының симфоник оркестры солисткасы;

Төхфәтуллин Рамил Чыңгыз улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты;

Федоров Сергей Александрович — Татарстан Дәүләт симфоник оркестры артисты;

Шапиро Давид Мотелевич — Татарстан Дәүләт симфоник оркестры артисты;

Яруллин Вадим Абдрахман улы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының балет солисты.

«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Вайсфельд Яков Хаимович — Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның борынгы рус сәнгате бүлек мөдире;

Лоренц Марина Крутовна — Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее генераль директоры урынбасары;

Максимова Зоя Константиновна — В.Качалов исемендәге Рус зур драма театрының труппа буенча баш режиссеры ярдәмчесе;

Милашевский Георгий Анатольевич — Татарстан Берләштерелгән дәүләт музееның археология һәм туган як тарихы бүлеге мөдире;

Муханов Геннадий Степанович — Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее генераль директоры;

Пиульская Ольга Иосифовна — Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның хәзерге заман сәнгате бүлеге мөдире;

Цой Вера Александровна — Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның сәнгать бүлеге мөдире.

Өстәлдә ак кәгазь...

Танылган драматург Ризван ХӘМИДКӘ телефоннан шалтыратабыз.

— Нинди иҗат газаплары белән янасыз, Ризван әкә?

Ризван ХӘМИД:

— Соравыгыз гадәти тоелса да, бик җитди җавап таләп итә. Чөнки чорыбыз үтә болгавыр һәм матавыклы, кыйблабыз төсмерләнмәгән чак. Байтагыбыз өч каен арасында адашып йөргән «бозау» кебек югалып калдык. Андый мәлләрдә исен җуймаган кеше үз тамырларын эзләргә керешә. Мин дә, тәвәккәлләп, тарихка чумдым.

Ә безнең тарих — күтәрелмәгән чирәм! Дөрес, моңа күпмедер дәрәҗәдә этәреш тә булды: режиссер Әхтәм Зарипов мине «Тукай» дигән кинодрама язышырга чакырган иде. Мавыгып китеп, 650 битлек сценарий язып ташладым. Шул мавыгудан тарихны һаман ташлап булмый: «Хан кызы» дигән тарихи драма яздым (ул әле генә «Мирас» журналында басылып бетте), Рөстәм Мингалим белән бергә, «Татарфильм» студиясе тәкъдиме белән «Идегәй» исемле 3 серияле киносценарий тәгәлләдек һәм ул, Ходайга шөкер, кабул ителде (шушы айдан «Казан утлары»нда чыга башлый).

Бер кызгач, әйтим инде. Телестудия соравын үтәп, кечерәк күләмле «Шекә пәриләре» исемле тарихи драма язып тапшырдым. Хәзер инде язу өстәлемдә әлегә тәгәлләнмәгән «Чура батыр» трагедиясе ята. Аңлашыладыр, ул да тарихи әсәр. Ата-бабаларыбызның изге тарихы моңарчы күзләрне каплап торган юшкыннарны бераз юып төшерде сыман.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

● Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның беренче яртыеллыгында җөмһүриятебезнең социаль-икътисади үсеше йомгакларын һәм киләчәккә төп бурычларны тикшерүгә багышланган киңәйтелгән утырышы булды.

● Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев шәһәр һәм район хакимият башлыклары, министрлык һәм ведомство җитәкчеләре, Президент аппараты һәм Министрлар Кабинетының җаваплы хезмәткәрләре катнашында киңәшмә үткәрде.

● Россия җәмәгатьчелек телевидениесенең «Время» программасы Татарстанда предприятие һәм оешма җитәкчеләренең эш хакы 15 минималь хезмәт хакыннан артмаска тиешлеген законлаштырган Указ чыгуы турында хәбәр итте.

● Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин һәм Россия Федерациясе элемтә министры Владимир Булгак Казанда санлы-күзәнәкле элемтә системасын тәкъдир итүдә катнаштылар.

● Татарстан Промстройбанкы әле яңа гына оешкан Промышленность сәясәте һәм дәүләт милке белән идарә итү буенча дәүләт комитетының вәкаләтле банкына әверелде.

● Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев «Татхимфармпрепараты» берләшмәсендә булды.

● Казандагы Идел-Кама биржасында республиканың кыска сроклы облигацияләрен сату-алулар үткәрелә башлады.

● Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин һәм Россия Федерациясе элемтә министры Владимир Булгак «Терминал» берләшмәсе һәм «Ай-Си-Эл» уртак предприятиесе эшчәнлеге белән таныштылар.

● Татарстан Дәүләт иминлеге комитетының ике прапорщигы Мәскәүгә командировкага баргач, «Пекин» кунакханәсендә кәеф-сафа корып, Казанга акчаларын һәм алтатарларын югалтып кайткан.

● Республика элеваторларына беренче «кызыл олаулар» Спас һәм Буа районнарыннан килде.

● Әлмәттә «Татарстан дулкынында» телевизион программасының «Җәмгыять һәм шәхес» дигән беренче республика фестивале булып узды.

● Казанда Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратов белән Түбән Новгород өлкәсе хакимиятенең ягулык-энергетика комплексы департаменты директоры Андрей Задернюк «Волга-Ойл» нефть компаниясе оештыру турындагы Татарстан хөкүмәте һәм Түбән Новгород өлкәсе хакимияте арасындагы килешүгә имза салдылар.

● Казаннан хәрби хезмәткә ялланып киткән, Таулы Карабахта ике ел ирексез тотылучы рус егетенең әнисенә хаты «Труд» гәзитендә басылды.

● 1996 елның икенче яртысында АлАЗ конвейерыннан беренче «Шевроле-Блейзер» автомобиле төшәчәге мәгълүм булды.

Бик борынгыдан килгән бер мәзәк бар. Галимнең өенә ут каба. Бу хәбәрне ишеткәч, ул бер дә исе китмичә: «Бу турыда хатыныма әйтегез», дип кенә җавап бирә. Утсыз төтен чыкмый, әлбәттә. Һәм аннары халыкта: галимнәр тормышны белмиләр, чынбарлыктан читтә торалар, дигән фикер дә яши. Көн саен, сәгать саен үзгәреп торган бүгенге тормышта, чыннан да, галимнәр битарафмы, киресенчә булса, аларны нинди мәсьәләләр кызыксындыра?

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, филология фәннәре докторы, профессор, академик Мансур ХӘСӘНОВ белән шул хакта әңгәмә алып барабыз.

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

БАШНЫҢ ТАҖЫ ГЫЙЛЕМДЕР



— Мансур Хәсәнович, Сез Татарстанга, илгә, дөньяга билгеле күренекле галим. Сезне фән өлкәсендә эшләргә нәрсә этәрде? Ихтимал, яшь чакта, мәктәптә укыганда ук моның оеткысы булгандыр?

— Әйе, күзәтүчәнлек, тирә-як мохитне төпченеп танып-белергә омтылыш, чыннан да, балачактан ук тынгылык бирмәгәндер. Безнең яшьлек чоры бик авыр елларга туры килде. Мин әле дүртенче сыйныфта укыганда сугыш башланды. Авылда урта мәктәп бар иде. Анда яхшы укыдым. Авылыбызның мәдәни, мәгариф традицияләре бай иде, башка авыл кешеләрен дә сокландыра иде. Туган ягым, авылым турында сәгатьләр буена сөйләргә мөмкин. Билгеле, һәркем үзенең туган җирен мактый.

Безнең авылның табигате дә бик матур. Аны, бер яктан, төньягыннан, таулар уратып алган, аның итәгендә инеш, таулардан агып чыга торган салкын чишмәләр күп. Авылның көньягында иксез-чиксез иген кырлары җәйрәп ята. Басу артында — әллә кайларга сузылган урман: Ул урманнарның теге ягына чыксаң, боргаланып-сыргаланып Зөй елгасы ага. Туган якның матур табигате миндә онытылмаслык тәэсир калдырган. Мин ел саен авылга сабан туена кайтырга яратам, әгәр кайтмасам, елның бер фасылы туктап калган кебек була. Университетта укыган чакта, май урталары җиткәч, имтиханнарның иң кызган чагында да күңелемдә тальян моңнары яңгырый башлый иде. Шуңа күрә имтиханнарны башкалардан алдан ук тапшырып, авылга сабан туйларына кайтып китә торган идем. Сабан туенда катнашу — табигать кочагына омтылыш дигән сүз.

Икенче көчле тәэсир, ул да булса — Алабуга. Минем студентлык чорым шуннан башланды. Ул чакта тормыш матди яктан бик кыен иде. Сугыш яңа гына беткән шул елларда Алабугада укыдым мин. Китапханә техникумында. Менә шунда тәүге тапкыр киңрәк дөнья белән таныштым, күп нәрсәгә күзем шунда ачылды.

Сабый чакта, мәктәптә укыганда нәрсәгә булса да, олы бер максатка омтылмаган бала бар микән? Булмаса, я ул туңган йөрәкле, яки, кайсы җәһәттәндер, тумыштан мәхрүм кеше. Һәркем яшь чагында нинди дә булса бер югарылыкка омтылырга тиеш. Шул омтылыш юк икән, ул камил шәхес була алмый. Яшь буында шундый омтылыш сизелмәсә, иҗтимагый тәрәккыят була алмый.

Техникумда укыганда мине математика өлкәсендә профессор булыр, дип уйлыйлар иде. Чөнки ул минем иң яраткан фәнем иде. Бөтен техникумда иң катлаулы мәсьәләләрне мин чишә идем. Һәм техникумны «кызыл диплом» белән тәмамлап чыктым. Бу диплом, өч ел мәҗбүри эшләмичә генә, югары уку йортына керергә хокук бирә иде. Әмма миңа, тормыш шартлары бик авыр булганлыктан, ике ел китапханәдә эшләргә туры килде. Менә шунда китап «җене» кагылды. Һәм шуннан филология, тарих, сәясәт өлкәсенә кереп киттем. Тарихны, әдәбиятны, борынгы китапларны өйрәнә башладым. Шуннан университетка укырга килдем.

— Сез Кысла йолдызлыгы астында тугансыз. Ә кысла саф суда гына яши ала. Фән дөньясы — тыныч дөнья, кем әйтмешли, бака ефәге сарган күл сыманрак тоела ул миңа. Сез җитәкләгән Татарстан Фәннәр академиясендә ниндирәк мохит, бик тынычмы, җилләр, давыллар купмыймы?

— Юк, мин бездәге атмосфераны тыныч, йокымсыраган дип әйтмәс идем. Фәндә, республика тормышында катлаулы һәм актуаль проблемалар күп. Аларны уңай юнәлештә чишү күп очракта галимнәрнең ничек эшләвенә бәйләнгән. Әмма шунысын да истән чыгарырга ярамый: галимнәр эшчәнлегенең үзенчәлекләре бар. Алар хезмәте һәр ел саен күзгә күренерлек ачышларга китерә алмый. Аның эш нәтиҗәсен күрү белән бәйләнгән ләззәтле, шатлыклы минутларына караганда борчулы, гасабалы сәгатьләре күбрәк. Әмма бу әле безнең галимнәребезнең фундаменталь һәм гамәли фәнни проблемаларны чишүгә керткән бәя биреп бетергесез кыйммәтле, авыр һәм катлаулы хезмәтләрен һич кенә дә киметми. Галимнәрнең эшчәнлеге турында уйланганда, бер нәрсәгә игътибар итми мөмкин түгел: шушы авыр заманда да, Президентыбыз, Дәүләт Советы һәм хөкүмәтебез ярдәмендә Татарстан Фәннәр академиясе, фәнни җәмәгатьчелек республиканың гыйльми потенциалын саклап кына калмады, ә бәлки аны ныгыту һәм алга таба тәрәккый итү мөмкинлеген тудырды.

Безнең академия фән үсешенең гомум хәленә йогынты ясарлык җитди эшләр башкарып килә. Турыдан-туры Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчелегендә эшли торган 5 фәнни-тикшеренү институты бар. Аларның галимнәре җитди проблемаларны тикшерәләр, фундаменталь фәннәр үсешенә зур өлеш кертәләр. Шушы ел башында «Татнефть» акционерлык җәмгыяте белән берлектә җир астыннан чыгару аеруча катлаулы булган нефть һәм табигый битум запасларын файдалану проблемаларын хәл итү буенча фәнни-тикшеренү Үзәге оештырылды. Академия һәм Казан техник университеты каршында «Прометей» исемле фәнни төркем уңышлы эшләп килә. Академия составында авыл хуҗалыгы һәм ветеринария фәннәре бүлеге оештыру, ә гуманитар фәннәр бүлеген 2 мөстәкыйль бүлек итеп үзгәртү турында да карар чыгарылды. Тагын шунысын да өстәп әйтергә кирәк: Татарстан хөкүмәте тарафыннан Фәннәр академиясенә налоглар түләүне, югары уку йортларына коммуналь хезмәт күрсәткән өчен тотыла торган чыгымны киметү, академик яки әгъза-корреспондент галимнәргә, доктор һәм фәннәр кандидатларына гыйльми дәрәҗәләре өчен өстәмә түләү кертү һәм башка чаралар билгеләнде.

Республика Фәннәр академиясенең фәнни тикшеренүләр буенча координатор буларак, дәүләт органнарында социаль-икътисадый, хокук, милли мәсьәләләр, мәдәният проблемалары һәм башка бик күп мәсьәләләрне хәл итү вакытында баш гыйльми консультант роле көннән-көн үсә. Бүгенге көндә законнар, төрле программалар, социаль-икътисадый тормыш өлкәсендәге концепцияләр, милли телләрне үстерү, яшьләр тормышы, бердәм экология системасын төзү, булдыру һ.б. тармаклар буенча Татарстан Республикасында барган эшләргә галимнәр, фәннәр академиясе сизелерлек өлеш кертә.

Шунысы да әһәмиятле: Татарстан Фәннәр академиясе үз эшчәнлеген республика белән генә чикләми: региональ һәм халыкара гыйльми хезмәттәшлегебез офыклары һаман киңәя бара. Россия, Украина, Белоруссия, Казагыстан, Башкортстан, Якутия һ.б. республикалар, Төркия, Франция, АКШ кебек илләрнең фәнни оешмалары белән гыйльми хезмәттәшлегебез көннән-көн ныгый, тирәнәя. Академиябез башкарган эшләр исемлегендә халыкара һәм бөтенроссия гыйльми җәмгыятьләре белән бергә үткәрелгән төрле конгресслар, конференцияләр дә шактый. Аларны үткәрүнең башлап йөрүчесе дә күп очракта — безнең Академия.

Шулай булгач, безнең Академиядәге хәлләр тымызык күлдән бигрәк, шаулап аккан елганы хәтерләтә, дияр идем мин. Безнең галимнәребезгә Ходай энергияне дә, акылны да, эшчәнлекне дә мулдан биргән!.. Бер генә сан китерәм: быелгы ел башына Академиябездә гыйльми тикшеренүләрдә 1366 фәнни хезмәткәр катнашкан, шул исәптән 32 академик, 44 әгъза-корреспондент, 254 фәннәр докторы, 630 фән кандидаты...

(Ахыры 6 нчы биттә.)

«Мәдәни җомга» газетасына

Татар халкының, Татарстанның махсус әдәбият һәм сәнгать газетасы оештырылу — зур әһәмияткә ия булган тарихи вакыйга. Ул милли журналистика үсеше дәрәҗәсен, аның бай традицияләрен генә түгел, татар халкының мәдәни-рухи куәтен, үсеш мөмкинлекләрен дә раслый.

Татар әдәбияты, сәнгате, гомумән, мәдәният, милли журналистика үзенең эчке үсеше белән моңа инде күптән, бу гасырның башында ук өлгереп җиткән иде. Мәгълүм сәяси сәбәпләр аркасында, без моны бер гасырга диярлек соңга калып эшләргә мәҗбүрбез. Әмма соң булса да, уң булсын. Хәерле юл сиңа, газета!

Туган телдә чыга башлаган махсус атналык басма татар әдәбияты һәм сәнгате, мәдәният үсешенә, сәнгать аркылы, аның сихри куәтен җигеп, төрле җирләргә таралып-чәчелеп беткән милләттәшләребезне бергә тупларга, милли аң һәм горурлык тәрбияләргә, татар халкын, Татарстаныбызны дөнья халыклары, дәүләтләр арасында танытырга, мәртәбәсен күтәрергә хезмәт итәр, дип ышанам.

Татарстан Фәннәр академиясе үзенең фәнни-интеллектуаль куәте белән яңа газетаның формалашуына, үсеп-камилләшүенә даими ярдәм күрсәтәчәгенә ышандырам.

Татарстан Республикасы
Фәннәр академиясе президенты
Мансур ХӘСӘНОВ.

5 июль, 1995 ел.

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

БАШНЫҢ ТАҖЫ ГЫЙЛЕМДЕР

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

— Мәгълүм булганча, Совет чорында кайбер «акыллы башлар» әдәбиятыбыз горурлыгы Гаяз Исхакыйга «шпион» кушаматы тактылар. Аның исемен дә телгә алырга ярамаган вакытлар бар иде. Ә күпме чын талантлар, әйтик, халкыбызның язмышы өчен ихлас кайгырган язучы Г.Ибраһимов, драматурглар Ф.Бурнаш һәм К.Тинчурин, шагыйрь Х.Туфан әдәби хезмәттән, җәмгыять тормышыннан читләштерелделәр. Шундый аяныч хәлләр яңадан кабатланмасмы икән? Тарихыбыз киләчәктә ялган тәгълиматлардан, дезинформатор-галимнәрдән азат булыр дигән ышаныч бармы?

— Мин пәйгамбәр түгел. Сезнең бу соравыгызга төгәл җавап бирә алмыйм. Иҗтимагый үсеш барышын бары тик күзалларга, чамаларга гына мөмкин. Тик шуны әйтер идем: тарихта күп нәрсәләр кабатлана. Мәшһүр Гегель: «Тарих дәүләт җитәкчеләрен бер нәрсәгә дә өйрәтә алмавын гына өйрәтә», дип юкка гына әйтмәгән, күрәсең.

Мин җәмгыять үсеше сәяси катаклизмнардан азат булыр, бары тик объектив дөрес, фәнни расланган юлдан гына барачак, хәвефле хәлләр кабатланмаячак, дип әйтә алмыйм. Дөньяның иҗтимагый-сәяси барышы андый оптимизмга нигез бирми. Әмма бу — бик җитди һәм тирән фәнни-сәяси проблема. Аңа газетадагы әңгәмә кысаларында гына җавап биреп булмый.

Совет чорындагы сәяси хәлләргә, алар өчен җаваплылык мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтер идем: ул заман сәясәтенә һәм «идеологиясе»нә автономияле республикаларда нигез салынмады, Татарстан исә Мәскәү куйган сәяси, икътисадый кысаларга куып кертелгән һәм нәрсәнедер үз ихтыяры белән үзгәртә дә алмый иде. Егерменче еллар башында моңа каршы чыккан кешеләрнең язмышы хәзер һәркемгә мәгълүм. Югарыдан «төшерелгән» фәрманнарны гамәлгә ашыру мәсьәләсенә килгәндә, аның сәясәтчеләре һәм идеологлары я үзәктән — Мәскәүдән җибәрелгән кешеләр, я урыннарда Мәскәү боерыгын үтәргә «ләббәйкә» дип торган аерым «акыллы башлар» иде. Алар инде гыйльми форумнарда үзләрен галим буларак күрсәтергә омтылучылар түгел, ә бәлки кабинеттан кабинетка йөреп, нинди дер белешмәләр, сәземтәләр төзеп, республика тормышына йогынты ясарга тырышучылар гына иде.

Ә инде аерым галимнәр тарафыннан фәнни, тарихи дезинформация бирүчеләр киләчәктә булмас, дип бүген дә кистереп әйтү кыен. Республика Фәннәр академиясе җитәкчесе буларак, мин фәнни оешмалардагы эшләр, бигрәк тә гуманитар фәннәр үсеше өчен, һичшиксез, үз өстемдә зур җаваплылык тоям. Әмма фәрман биреп, кемнәрнедер нәрсәдәндер тыеп кына утыра алмыйм (әлеге ысул Фәннәр академиясендә кулланышта юк һәм мондый рәвештә җитәкчелек итү — минем стильдә түгел). Әмма фәнни кадрларны топтән уйлап сайлау һәм кирәк вакытта аларга киңәш бирү, тиешле ярдәм күрсәтү юлы белән фәнни хезмәтнең юнәлешенә йогынты ясарга мөмкин һәм, һичшиксез, кирәк тә. Аннары һәр кешенең үз ихтыяры, холкы бар — «җитәкче» буларак, бар кеше белән дә бертөсле мөнәсәбәттә генә аралашу дөрес тә түгелдер. Кешеләр белән эшләгәндә бераз сабыр, игътибарлы булу, кеше шәхесенә ихтирам һәм таләпчәнлек белән карау зарур. «Киләмгә» чакырып, мөнәсәбәтләрне киеренкелеккә илтү ысулы — фәнне алга илтмәячәк — монысына иманым камил.

— Сез сөйләгәннәрдән укучы Татарстан Фәннәр академиясе һәм республикада аның урыны, йогынтысы турында үзенең фикерен туплар. Минем Сезгә тагын бер бәхәсле сорау бирәсем килә: кем соң без? Болгарлармы, татарлармы? Инде керәшеннәрнең дә үз дәүләтчелеген булдырасылары килүен ишетәбез... Һәм аннары бик якын тарихка борылып карасак, 1977 елда, хәтерләвемчә, Казан шәһәренең 800 еллыгын бәйрәм итү турында бик күп сүз булса да, тантаналар булмый калган иде. Галимнәр киң җәмәгатьчелекне борчыган сорауларга кайчан ачык һәм тулы җавап бирерләр икән?

— Күптән түгел мин үзебезнең Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми советы утырышында булдым. Анда күренекле төрек-татар галиме Надир Дәүләт фәнни доклад ясады. Ул татар дәүләтчелеге, татар милләте, аның язмышы һәм башка мәсьәләләрне кузгатты. Кунактан нәкъ менә шушы болгар-татар бәхәсенә аның мөнәсәбәтен сорадылар. Алдан искәртеп куйыйм: үз вакытында «Шәһри Казан» газетасының беренче санында мин бу мәсьәлә буенча үз фикеремне язып чыккан идем. Өстәп шуны әйтим: әлеге мәсьәлә фәнни яктан да, сәяси һәм дәүләтчелек ягыннан да хәл ителгән, дип саныйм. Шулай да кайберәүләр аны талкуны һаман дәвам итәләр... Әлеге утырышта да шул «без — болгарлармы, татарлармы?», «без — төрекмә, татармы?» дигән сораулар яңгырады. Бу сорауның икенчесе — 19 гасыр азагында, 20 гасыр башында күтәрелгән һәм 1917 елга кадәр үк чишелешен тапкан иде. Без төркиләр дә, татарлар да! Урыстан сорагыз: славянмы ул, урысмы? Әлбәттә, җавабы бер булыр: урыс та, славян да. Без дә — төркиләр дә, татарлар да!

Әмма сорауның бүгенге куелышы юкка түгел, күрәсең. Татарстан 1990 елда үзенең суверенлыгы турында Декларация кабул итте. Ә бу үз чиратында фән, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең офыкларын киңәйтеп, чит илләргә юл ачты. Аеруча Төркия белән ике арада мөнәсәбәтләр активлашты. Бәлки кемнәр өчендер «без төрекләр белән милләттәшләр түгелме?» дигән сорау тугандыр. Гафу итегез, инде үсеп җитлеккән милләтне балалык чорына кире кайтарып булмый. Ике дәүләт тә үсеш ягыннан югары дәрәҗәгә ирешкән. Төркия үзенчә тәрәккый итә, без — үзебезчә, һәм бу халәтләргә үзгәреш кертү мөмкинме? Аннары... татар менталитеты моны үзе дә кабул итәрме? Кемгәдер «татар» сүзе ошамый икән, монда татар халкының ни гаебе бар? Әмма без — татарлар. Шул ук вакытта төркиләр дә. Болгар яки татар атамасына килсәк тә, шул ук хәл. Без болгар да, татар да. Ир уртасы булган урыстан сора әле: син Сашамы, Александрмы? Ул әйтер: Саша булган чагым да булды, хәзер — Александр, дияр. Менә безнең белән дә шундый хәл: халкыбыз яшьрәк чагында «болгар» иде, без болгардан хәзерге «татарларга» әверелдек...

Тагын фараз итик: ярар, милләт исемен алыштырдык та, ди. Моның белән барыбер үз тарихыбыздан кача алмыйбыз бит. Кайчандыр кемнәрдер «татар» исеме белән бик күп халыкларны атаганнар. Әйтик, бөтен Алтын Урда халкын. Тора-бара ул исемнән күп халыклар киткән, аерылган, шушы исем безгә ябышып калган. Бөтен дөньяны шаулатып йөргән мәгърур татар исеме! Алтын Урданың төп мирасчылары булып без калганбыз. Ә бит асылда без үзебез дә Чыңгыз хан яулап алган халыкларның берсе. Хәзерге татарлар берничә этнос кушылуыннан килеп чыккан милләт, әйтергә кирәк, дөньядагы башка милләтләр арасында күренекле милләт.

Тарих туры юлдан гына бармый. Кемнәрдер җиңә, кемдер җиңелә. Кайберәүләр әйтә: Чыңгыз хан аркасында безгә күпме каһәр төшә!.. Һәм моннан исем алыштыру юлы белән котылырга телиләр. Бер нәрсәне яхшы аңларга кирәк: тарихтан исем алмаштырып та, аны үзгәртеп, «яхшыртып» та качып булмый. Аны ничек бар, шулай кабул итәргә, фәнни аңлатырга гына кала. Үткән сугышта Гитлер Германиясе күпме халыкларга, илләргә ҫәҗигә алып килде. Аңа карап, идеологиясеннән, сәясәтеннән, фашизмнан баш тартсалар да, немецлар «немец» булудан баш тартмадылар бит...

Болгар-татар бәхәсе — инде хәл ителгән, хәзер кирәксез бәхәс ул. Алай гына да түгел, сәяси яктан зарарлы бәхәс ул: халык саны алу вакытында татарларның күпмедер өлеше «болгарчылар» вәсвәсәсе аркасында үзләрен «болгар» дип яздырып, татар халкының санын киметүгә китерделәр. Аларны «прочие» дигән графага керттеләр.

Инде керәшеннәрне алыйк. Керәшен — татар милләтенең тулы хокуклы мөһим бер компоненты. Әмма аерым милләт түгел. Ул — татар милләте. Ярар, чукынган булсын, теле бер, дине башка, ди. Ә кемне үз алласына гыйбадәт кылудан тыялар?! Рәхим итсеннәр!

Һәркемгә сүз ирегә бирелгән, кешене фикерләүдән тыеп булмый. Инде цензура кысуы юк. Әмма җитди мәсьәләләр турында фикер йөрткәндә үз-үзеңне тыя белергә, эчке тормозларны ихтыярыңнан ычкындырмаска тиешсең. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә мәдәнилек, эчке культура дигән нәрсә бар. Башыңа килгән фикерне шунда ук гавамгә ташларга, радиотыңлаучыларга, газета укучыларга ярып салырга димәгән бит! Башта позицияңне ачыкла, иманыңны кат-кат тикшер. Менә бит хикмәт нәрсәдә...

Казанның 800 еллыгына килгәндә... Матбугатта бу турыда әйтелде инде: Казанга нигез салынган ел итеп тарихи чыганакларның берсендә 1177 ел күрсәтелә. Әмма бу тарих фәнендәге бердәнбер дата түгел. Бәйрәм итү төрле сәбәпләр аркасында өзелде. Мәскәүнең танырга теләмәве, Казанның топле, ышандыргыч дәлилләре җитмәве — тантананың булмый калуына китерде. Ә менә Казанга нигез салынуга 825 ел тулуны фәнни дәлилләүдән Татарстан Фәннәр академиясе, бигрәк тә республиканың гуманитар галимнәре читтә калмас, үз сүзен әйтер, дип уйлыйм.

— Әңгәмә ахырында, Мансур Хәсәнович, бер сорауны ачыклыйсым килә: беренче татар энциклопедиясе нинди телдә чыгарга тиеш — рус телендәме, әллә татар телендәме? Моңа Сез ничек карыйсыз? Һәм без аны кайчан күрәбез инде?

— Бик катлаулы, мәшәкатьле авыр эш булды ул. Аның беренче энциклопедия булуы эшкә аеруча җаваплылык өсти. Миңа калса, җыелган бу бай мәгълүматны укучы ике телдә дә бер үк вакытта ук укый алсын иде. Башка милләтләр өчен дә бу хезмәт зур кызыксыну уятачак. Минемчә, аны тизрәк тәгәлләп, нәшер итәргә кирәк. Төгәен генә чыгу вакытын атамыйм, шуны гына әйтә алам: без, зур җаваплылык хисе тойган хәлдә, әлеге хезмәтне дөньяга чыгарырга ашыгабыз.

Әңгәмәне
Зөлфирә ТУГАНОВА оештырды.



Илдар ЮЗЕЕВ,
Татарстанның халык шагыйре

* * *

Яшькә килгәндә,
Мактаналабыз:
Кол Галиләрнең
Агалары без.
Хәтта Тукайның
Бабалары без,
Муса Җәлилнең
Агалары без!

Энекәш кенә
Такташларыбыз,
Сибгат Хәкимнең
Яшьтәшләре без!..
Иҗатта алар —
Бабаларыбыз,
Барсының газиз
Балалары — без.

29.03.94.

Тузганак

Кузгалаклы болыннар,
Тузганаклы болыннар,
Балачак узган урыннар,
Чәчем тузган урыннар.

Кузгалаклы болыннардан
Йөрим һаман узгалап;
Җилләр искән, очкан-киткән —
Балачагым-тузганак.

Сибелделәр чәчләрем,
Акты-китте яшьләрем,
Көрешергә килгән идем, —
Балачак, ник дәшмәдең?

Кузгалаклы болыннардан
Йөрим һаман узгалап;
Җилләр искән, очкан-киткән —
Балачагым-тузганак.

Эзлим туган җирләрдән,
Йөгереп менгән үрләрдән;
Кире җыеп алыр идем,
Мөмкин булса, җилләрдән...

Кузгалаклы болыннардан
Йөрим һаман узгалап;
Җилләр искән, очкан-киткән —
Балачагым-тузганак...

1993.

* * *

Хәерче, гарип-горәбә...
Кем генә юк урамда.
Хәер бирергә омтылып,
Кесәмә тыгылам да...
Кулны кире тартып алам.
Сез өмет иткән кеше —
Ул да Казанның билгеле
Рухи бай хәерчесе.
Кесәләр буш... Күңелем хуш...
Акчасыз-нисез җырлыйм.
Гармун уйнап, бөрек тотып,
Урамда гына тормыйм.
Юбилейга бүләк булган
Тунымны киеп йөрим.
Салкында туңып утырган
Баланы сөеп йөрим.
Мин дә заман байларына
Кызыгып карап калам.
Кил әле, кер тун эченә,
Кил, җылын, таҗик балам...
Бу бабагыз — пенсиядә,
Йөрергә вакыты бар.
Илдән, Җирдән куылмаган, —
Бер генә бәхете бар...

30.03.94.

* * *

Чыгармыйм күз яшьләрен мин,
Чыгармыйм,
Еламыйча яшәрмен мин,
Чыдармын.
Елар идем, күз яшьләрен
Кем сөртер?
Әнкәем юк, бәлки, искән
Җил сөртер...
Сабый чакта татлы яшьләр
Коелган,
Мин — нарасый — әнкәемә
Сыенган.
Шәфкать сорап булмый хәзер
Яшь бөлән;
Яшьләремне хәтта җилдән
Яшерәм.
Яшь коюдан күңел барыбер
Бушанмый,
Әнкәйләрдән башка беркем
Ышанмый.
Кызганучлар болай да күп —
Ил белән.
Яшем чыкса, очсын кырыс
Җил белән...

14.08.94.

Безне кемнәр аңлар?

Ф.Гарифуллинга

Мәҗлестән соң бераз гына кыздык...
Кочакларда — гармун.
Төнге шәһәр буйлап җырлап уздык:
Актарылды бар моң.
Исәрекләр, зурлап, кул бирәләр,
Айнып, туктап калып;
Хулиганнар, җырлап, юл бирәләр:
«Тимә, безнең халык!»
Бу урамнан төнлә беркем йөрми,
Хуҗа монда — хәмер.
Без узганда усал этләр өрми...
Ачыл, басыл, бәгырь!..
Изү чишеп, мин дә җырлап килөм.
Йөрәкләрдә — давыл.
«Баламишкин» булып, ярсу белән
Тибә җанда авыл.
Мин дә сездән аерылып тормыйм,
Сукбай, сәрхуш җаннар...
Кочаклашып, үксеп-үкереп җырлыйм:
Безне кемнәр аңлар?!

19.03.94.

* * *

Нәфис сүз остасы
Айрат АРСЛАНГА

Йә, кил әле, Айрат, минем янга,
Сүзсез генә бергә утырыйк,
Дөнья мәшәкатен онытыйк та,
Эчтән шигырь укып, тын торыйк.
Якташлык та, әз-мәз Такташлык та,
Тукайлык та бераз бар бездә.
Омтылыш та аларныкы кебек,
Сулыш юллары да тар бездә.
Күпме чыктың инде сәхнәләргә,
Халкың өчен янып, пошынып,
Сулыш юлларыбыз кебек һаман
Милләтебез яши кысылып.
Оллат тавышыңны тыңлаганда,
Мин дә горурланып куямын,
Тукай, Такташ, Җәлил сулышының
Дәвамнарын синдә тоямын.
Кызыкмадык дөнья малларына,
Сәнгать, диеп гомер кыскарттык;
Сарай җырчылары саналганчы,
Күңелләргә керү — мең артык!
Юк,
Син — татарның Левитаны түгел,
Нәкъ безнеңчә милли Айраты,
Синдә — халкыбызның затлылыгы,
Нәфислеге, өмет, гайрәте.
Яндык, туңдык, көйдек сәнгать өчен
Кызганмадык йөрәк җылысын;
Яшик әле, Айрат, яшик әле
Озынайтып милләт сулышын!

15.01.95.

* * *

Ник кадерсез соң без, кадерсез?
Була кайчак: югаласы килә
Хәбәр-хәтерсез һәм каберсез...

Килә кайчак китеп югаласы,
Рәхимсезлек патшалыгын ташлап,
Гарешләргә — Күккә ашасы...

Китеп югаласы килә кайчак...
Бераз гына мин җитмәүне тоеп,
Эзләп табар, бәлки, Киләчәк?

Киләчәк тә дәшми, Алла да...
Югалырлар шулай миннән соң да,
Югалганнар миннән алда да.

Ник кадерсез соң без, кадерсез?
Күкрәкләрне киереп, иркен сулап,
Бер җырлыйсы килә... хәмерсез.

Бу гөнаһлы Җирдән китәлмәм,
Арды инде җаным җылы көтеп,
Хыялыма барып җитәлмәм.

Күк алмаса, әле Җир алыр,
Безне кабул иткән каберләклөр
Мәңгелектә эзсез югалыр...
Күк астында, балкып, Җир калыр,
Юксынырга, бәлки, җыр калыр...

1992.

* * *

Сезнең якта табигать тә башка,
Бигерәк тә камил.
Йоклап ятсак, күрми калабыз бит
Сихри төннең ямен.
Төннең сандугачын, үкси-үкси,
Тыңлыйсылар килә,
Шул кошларга кушылып, елыйсылар,
Җырлыйсылар килә.
Сезнең якның елгасы да талгын,
Суын ярга какмый.
Усал этләрегез ботны капмый,
Кортларыгыз чакмый.
Сезнең белән, җырлап, таңга каршы
Барасылар килә;
Шушы төндә туып, яшәп, үлеп
Каласылар килә.
Төнге урманнарга керәсе дә
Югаласы килә;
Серле Күккә ашып, Мәңгелеккә
Юл аласы килә.
Бала чакта мин бит Табигатькә
Гашыйк адәм идем...
Аһ, нигә соң кыска гомеремне
Йоклап әрәм иттем?!
Саубуллашыйк, бу дөньяда, бәлки,
Очрашмабыз тиздән.
Кәккүкләргә кушылып, юрыйм мин дә:
Озын гомер — бездән!

1992.



НИШЛӘВЕГЕЗ

Мөбарәк тәсбих өзелсә

Бу язмамдагы фикерләр, күңелемне күптән борчып торсалар да, аларны аңлап бетерүче укучы бардырмы соң, дигән сорау алдында, дәрья ташкыннары дәү кыяга бәрелеп челпәрәмә килгәндәй, гел артка чигерелә тордылар. Ниһаять, җөмһүриятебездә әдәбият һәм сәнгать әһелләре өчен махсус атналык — үзебезнең газета чыгарылуын белгәч, тәвәккәлләдем.

Безне сары сагыш ялкынына салып китәсез дә барасыз, китәсез дә барасыз, егетләр. Башка бер дә кайтмаска. Мәңгелеккә... Ичмасам, кешеләрчә, иләп кенә саубуллашырга да өлгерә алмый калабыз.

Укучым белән уртаклашасы фикерләремне, нигездә, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең гомере турындагы хәсрәтле уйлар тудырган булса да, сүземне әтиемнең вафатыннан башламый тыела алмыйм. Әтисез калганда миңа уналты тулып кына узган иде әле. «Кыз балага әтинең иң кирәк чагы», — дип сукрандым. Чөнки мин — төпчек, абыем, апаларым үз көннәрен үзләре күрә башлаган, әнием... шырпылык кына пенсия ала, мин исә, урта мәктәпне тәмамлап, бер урынга җиде кешелек коточкыч конкурсны үтеп, университетка кердем. 1954 ел. Илдә адәм баласын, хәтта сатып алырга акчасы булса да, туендырырлык ипи җитми. Шушы шартларда мин иң көчле ярдәмчемнән — газиз әтиемнән мәхрүм калдым. Аңа нибары 66 яшь иде. Мине кемгә ташлап киткәндер?!.

Иң-иң газизләребез турында сүз кузгаткач, әйтим инде: әтиле-әниле егеткә кияүгә чыккач, мин кабат әтиле булдым. Әй сөендем! Каенатам үз әтием кебек үк әйбәт кеше иде — укымышлы, акыллы, инсафлы педагог. Туксан яшьлеген уздырган бәйрәмебездә мин аның үз балаларын көнләштереп бер нотык тоттым:

— Сезнең шул бер әтиегез бар — әйбәт әтиегез, ә мин бит, аңа килен булып, икенче кат әтиле кызга әйләндем. Бари әфәнде Ганиев — минем икенче әти! — дидем...

Әти-әниләребезнең дөньядан күчүенә дә шактый еллар үтеп бара инде. Шыр ятимнәр без, әмма шуны ихластан әйтәм: әти-әни үзең әби-бабайга әйләнгәч тә кирәк икән ул. Чөнки сине әтиең белән әниеңнән башка һичнинди карусыз аңлаучы башка зат бу дөньяда юк. Аларның һәркайсы — бердәнбер. Мин исә үземне җаныннан артык күрүче әтиемнән уналты яшьтә үк мәхрүм калдым. Бу хәл безнең буын өчен искитмәле нәрсә түгел иде. Күпләрнең әтиләре безнең сабый чакка туры килгән — каһәр суккан сугыштан кайтмады. Гаҗәеп бер балачак, аннары үсмерчак кичердек без — әтисезләр үсмерчагы. Инде үзебез әбиләр, бабайлар булып җиттек. Мин исә әтиле кордашларымнан көнләшәм, миңа һаман әти кирәк; үз кулымда, 93 яшенә җитеп җан биргән булса да, миңа һаман әни кирәк.

Адәм баласы әҗәл белән мәңге бәхәстә, мәңгелек тарткалашуда яши. Бу хактагы уйларым, нигездә, әдәбият һәм сәнгать әһелләребезнең ифрат яшьли вафат булуы турында гаҗизләнүдән туды. Иҗатлары алдында бил бөгеп, баш иярдәй әдипләр, рәссамнар, композиторлар, артистлар, биюче-балетчылар, безне тәмам чарасыз калдырып, һич уйламаганда «китәләр дә баралар». Алар — минем икенче төр ата-аналарым кебек. Чөнки тормыш итүгә, халыкчан иҗатка мин нәкъ менә алардан өйрәндем.

Тик әле аларга кадәр үк минем сабакташлар, бу дөньяны тарсынгандай, вафат була башлады. Мәктәптәге дусларымнан Зәйнулла Бакиров (ул, университет бетереп, «Татарстан яшьләре» гәзитендә абруй казанып өлгергән иде), кызлар белән танышып та карамас борын, мәңгелеккә китте. Беренче сыйныфтан бер партада утырып укыган ахирәтем Фәүзия Сөләйманова-Мәүлиева, Уфа егете Әдһәм белән бик матур тормыш кичереп ятканда, кинәттән вафат булды. Аннары бу әҗәл дигән зәхмәт минем университетта укыган шәриктәшләремә ябышты: 1959 елда югары уку йортын тәмамлаган 25 кешелек төркемебездән инде алты (!) егет — теге дөньяда. Өчәве «кызлар кулын тотарга» да өлгермәгән килеш «китеп» барды: журналистлар Әнәс, Зоммер, галим Альберт Фәтхи...

Безнең буынны бик оста алдаганнар булып чыкты. Шулай да бер фикердән һич тә ваз кичмәгәнбез: татар теле һәм әдәбияты иманыбыз иде. Шуңа да биниһая зур бәйге-конкурсны үтеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кергәнбез. Юк, башка фәннәрдән курыккан өчен генә түгел. Бу хакыйкатьне раслар өчен мин шул дәлилне генә китерәм: безнең группага укырга керүчеләр арасында алтын медаль иясе күп иде. Алар һичнинди имтихансыз теләсә кайсы шәһәрнең теләсә кайсы институтына, теләсә кайсы һөнәрлек бүлегенә керә алалар иде. Безнең медальчыларны исә татарга бирелгәнлек, татар теле вә әдәбияты, Казан каласы тарткан булып чыкты.

Еллар сизелмичә үтә. Без татар теле һәм әдәбияты белгечләре булып өлгердек, әмма иң кадерле остазларыбыз китә торды: мәшһүр телче Латыйф ага Җәләй, «артистлардан да остарак» әдәбиятчы Якуб ага Агишев, фольклорчы Хәмит ага Ярми, остазым Хатип ага Госман, Ибраһим ага Нуруллин...

Без университетны тәмамлаганчы татар мәктәпләрендәге хәлләр нык үзгәрде, аларны тоташ яптылар, татар теле һәм әдәбияты сәгатьләрен киметтеләр. Безгә үзебез хыялланган эш белән шөгыльләнергә мөмкинлек тәмам чикләнде. Нәтиҗәдә, сабый чактан, мин мәктәптә татар әдәбиятын укытачакмын, дип хыялланып үскән белгечләр билгесез бушлык алдында калдырылды. Беребезгә генә дә үзе теләгән татар мәктәбенә барып, үзе теләгәнчә татар телен һәм әдәбиятын укыту бәхете тимәде. Кем нинди эш тапса, шунда урнаша башлады. Арада милиционерлар да, тракторчылар да барлыгы «беленде». Бәхеткә, сакланып калган татарча басмадагы газета һәм журнал редакцияләре кайберәүләребезне үзләренә сыендырды. Университетта укыган төркемебездәге 25 кешедән инде 6 сының вафат булу галәмәтен мин шушы гайре табигый хәлләрдән дә күрәм. Гомер буе татар әдәбияты укытучысы булырга хыяллан, ачлы-туклы укып, менә дигән диплом ал да... милиционер булып эшләп кара әле син. Җаның күпмегә чыдар иде икән?! Без бит китапларга язылганнарга, устав күрсәтмәләренә ихлас күңелдән ышанган идек. 1937 елгы гаделсезлекләр узган, дини хорафатлардан без «азат ителгән», Бөек Ватан сугышында җиңгән — без барысына да ихластан ышана идек: бары тик без генә гадел илдә яшибез, бары тик без генә туры юлдан алга барабыз... Ә эшләгән акчалар ашарга җитми, яшәргә өйләр юк. Тик без моңа бик игътибар бирмибез, без киләчәк буыннарны бәхетле итәчәкбез, дип ихластан тырышып эшкә ябыштык.

Мин журналистикага кереп киттем, язучылар белән аралаша башладым. Ә әҗәл дигәнең арттан куа килә. Бик якын күргән журналистларым да, язучыларым да китеп кенә баралар бит, китеп кенә баралар — мәңгелеккә: әтиемдәй акыллы киңәшләре белән ярдәм итеп торучы Нәкый абый Исәнбәт тә, әдип вә рәссам Бакый абый Урманче да, якташларым Хәсән Туфан белән Салих Баттал да... Берсе дә юк инде.

Бу әҗәл мәрхәмәтсезлеге язучы Газиз Мөхәммәтшин җеназасында мине беренче тапкыр тетрәндерде. Аңа 40 кына яшь иде әле. Үзе талантлы, үзе бик тә актив һәм... шәфкатьле әдип иде ул. Инде сиксәнгә таба баручы әтисенең авыруын ишетеп, Минзәлә ягына кайтып киткәч, юлда вафат булды. Әтисе ясин чыгып, җеназасын уздырды. Газиз әфәнденең табутын Казандагы Матбугат йортына алып килгәннәр иде. Мин хәйран калдым: аның йөзендә елмаю галәмәте чагыла сыман тоелды. Гүя, Тукайча: «... без китәбез (без бу гаделсез, мәрхәмәтсез җәмгыятьтән китәбез, ә сез теләсәгез ничек томер итегез), сез каласыз!» — дигән кебек ята. Тумрап торган балалары, яшь-яшь алмадай хатыны ятим калдылар. Аннары — Сарьян, Малик Хәмитов...

Өлкәнрәк кешеләрнең «китүе» — бер хәл, әмма соңгы елларда яшь-яшь әдипләребезгә, артистларыбызга, яраткан биюче вә җырчыларыбызга ябыша башлады бит бу әҗәл дигәннәре. Белә идегезме сез Иркә Сакаеваны, Дамир Хәйруллинны, Ревдар Садыйковны?! Рудольф Нуриевны әйтеп тору да урынсыздыр инде. Шагыйрьләребез Дифгать Сирай, Фәннур Сафин, Кадыйр Сибгатуллин. Санап чыгарлык та түгел: язучыларның ике съезды арасында гына да 25 (!) җеназа булган. Ул егерме бишнең кайсы турында да зур-зур кыйссалар язарлык.

Мин үзем өчен иң якыннарына гына тукталырга җөрьәт итәм. Саҗидә, Рәшит, Мөхәммәт Мәһдиев, Фәрваз. Ни өчен алармы? Беренчедән, бу дүртәүнең әдәби сәләтләренә соклаңып яшәдем мин, икенчедән, һәммәсен дә шактый яхшы беләм. Якыннан аралаша торган идек, дуслар идек. «Сүзең «егетләр»дән башланган иде бит, ник Саҗидәне кыстырасың?» — диярсез. Минемчә, Саҗидә-күбәләгем (мин аны гел шулай атый идем) — белгән егетләремнән дә көчлерәк ихтыярлы шагыйрә. Дөрес, мин аның елаган чакларын да күрдем. Берсендә, «Азат хатын» журналында чыгып бара торган шигыренең кыскартылганын белгәч, һич ничек тыела алмыйча бик озак елады. Бүлмәдә без икәү генә идек. «Сабыр ит, мин белешим әле, бәлки эшне төзәтеп булыр», — дип тә карыйм. «Кирәкми!» — аның тавышы кисәктән кырысланды. Башымнан хәтта шом йөгереп узды. «Шигыремнең иң үзәк мәгънәсен бетергәннәр бит. Шуны да аңламаслык булгач, ник бу эшкә тотынырга?! Бу рәвешле чыгасын белсәм, тулысынча төшереп кенә калдырта идем аны мин», — диде ул.

Бәлки, беләсездер: Саҗидә ханым Сөләйманова озак еллар шул ук журналның редколлегия әгъзасы булып, бик якыннан ихлас ярдәмләшеп эшләде. Аның, чыннан да, теләсә кайсы язманы алдыртырга хокукы бар иде.

Икенче тапкыр елаганда, Саҗидә белән без Татарстаннан еракта, Кавказда, Кара диңгез буендагы Гагра иҗат йортында язып-ял итеп ята идек. Апрель ае. Саҗидә бу сәфәргә юри чыккандай итте, чөнки аны кабаттан Тукай исемендәге бүләккә кандидатлыкка тәкъдим иттеләр. «Бу мәсьәлә хәл ителгәләгәнче, Казанда да, Әлмәттә дә торасым килми, нервларны сакларга кирәк», — диде ул. Бүләк бүлү нәкъ шул айда була бит. Саҗидә исә инде бик нык авыру, һәм якасына ябышкан әҗәл явызлыгын үзе дә бик яхшы белә иде. Шуңа сакланыуы булгандыр. Үлемгә каршы Саҗидәдәй, җиң сызганып, бөтен шартын туры китереп көрәшкән башка кешенең миңа очраганы юк әле. Биш-алты еллап авыруы дәверендә ул әллә ничә китап чыгарды, повесть язып, «Казан утлары»нда бастырды, әсәрләрен русчага тәрҗемә иттереп, аларның һәммәсен йә китап, йә журнал сәхифәләрендә укучысына җиткерде. Берничә операция, «пычактан» соң үткәрелә торган биниһая авыр процедураларны кичерде. Үзе һич зарланмый, ыңгырашып та күрсәтми иде. Ә менә Гаграда, оҗмахтай җирдә, рәхәтләнеп иҗат итеп ятканда, көннәрнең берендә ул м[illegible]еп янга елап килеп керде.

Ашык-пошык бирелгән сорауга тиз генә җавап ишетмәвемне белгәнгә, баштa берни дә әйтми тордым. Ул үзе сөйләп китте:

— Әлмәттән хат алдым...

— Калганын дәвам итә алмый торды, еларга тотынды.

— Ә-ә, Әлмәтең сагындырдымы, шуңа елыйсыңмы?

— Юк. Хатны Әдип абыең язмаган. Шагыйрь... (исемен әйтмим инде) салган. Көлкегә салтырмакчы, үзенчә. «Саҗидә, үпкәләштән булмасын, Тукай бүләтен сиңа түгел, миңа бирәчәкләр. Миңа моны мәгълүм «абзыебыз» үзе (!) вәгъдә итте...» дигән.

Саҗидә елый, теге «мәгълүм абзый»ның биниһая үзсүзле икәнлеген сөйли, инде Тукай бүләгенә мәңге ирешә алмаячагын аңлата. Мин исә аны тиргәргә тотындым. Гадәтем шул — елаган кешене йомшак сүз белән түгел, аны ачулангандай кыйланып тынычландырам. «Соң, дим, Саҗидә-күбәләгем, мин сиңа баштан ук ул вакыйгалардан

БУ, ЕГЕТЛӘР?!

ерак торырга кушкан идем бит инде. Ничәнче мәртәбә кандидат булдың?! Бирмәделәр. Берәсе булсалар, бу кадәргә сузып та тормыйлар иде инде аны. Син комиссия әгъзаларына шигырь китаплары өләшеп чыгасың, ә егетләр дипломатларына коньяк тутырып, шафталу-өрек салып, аларны . . сыйлап, турыдан-туры килешү төзеп йөриләр. Син үз шигырьләрең турындагы мәкаләне миннән яздырдың: «Тукайга — чәчәкләр» имеш! Ә егетләр әллә нинди зур исемнәре булган профессорлардан яздыралар. Елама, төкер!» — дим.

— Кояш, мин бит үз шигырьләремнең әлеге хат иясенекеннән көчлерәк икәнен беләм. Мәкаләне синнән яздыраммы, башкаданмы — бусы да әһәмиятле түгел, авторның минем шигырьне аңлаган булуы гына шарт. Синнән дә тирән аңлаучы кемем бар минем?!

Бирмәделәр Саҗидәгә бу бөек бүләкне. Шушы гаделсезлек аны кабат аяктан екты. Ул яңадан Казан Кремле янындагы коточкыч хастаханәгә операциягә килде. Беренче күрсәтмәсе: «Минем янга теләсә кемне китереп йөртмәгез! Син йөр, «Азат хатын» кызларыннан Фәния Хуҗиәхмәт белән Рәйсә Йосыпова килә ала. Башкаларга рөхсәтем юк!» — дигән сүз булды. Тыштан караганда, ул үзенең терeләчәгенә ышана кебек иде хәтта. Язучыларның шушы елны булачак съездына катнашачагын, «Голбадран» повестен китап итеп чыгарачагын, киләчәккә билгеләнгән тагын әллә нинди гамәлләрен бәйнә-бәйнә сөйләп ятты. Шулай да... әҗәл белән очрашуына да чаралар күргән икән Саҗидәбез. Әлмәткә кайтып китәр алдыннан ул безгә — миңа, Рәйсәгә, Фәниягә — истәлекле бүләкләр, кешәмир яулыклар, Фәниягә алтын балдак бирде. Миннән ак мамык шәл табуымны үтенде. «Әй кыйммәт инде ул, Саҗидә-күбәләгем», — дим. «Әле генә повестем чыкты, акчам бар минем, — диде. — Зур, матур, нәфис булсын!» Таптым мин аңа нәкъ үзе теләгән мамык шәлне. Ап-ак челтәр иде, бик зур, йомшак, җылы иде...

Саҗидәкәйнең Әлмәттә вафатын ишеткәч, көчкә барып өлгердем. Аның табутын өйләреннән алып чыгып баралар иде инде. Йөзе ачык. Тик мин аны Саҗидә-күбәләгем дип кабул итә алмадым. Бутаганмын, ялгыш башка йортка килеп эләккәнмен, дип торам — танырлыгы калмаган иде. Бары әнә шул шәлгә күзем төшкәч кенә, күземнән яшь ага башлады. Әйтеп калдырган икән бәгырь: минем башыма шушы шәлне бөркәндерерсез! — дигән...

Күрәсез: Саҗидә Сөләйманова белән азмы-күпме аңлашып, саубуллашып кала алдым әле мин. Башкалар кичерә күрсеннәр! Рәшит Әхмәтҗанов белән соңгы сөйләшүем искә төшсә, җаным тетрәнә, үз-үземне өзгәләп ташлардай булам. Аның белән без аеруча дуслар идек. Вафатына ярты елдан артык вакыт үтте, мин әле аны һаман исән дип беләм, аның белән сөйләшкән-киңәшкәннәрне, бәхәсләшкәннәрне аз гына да истән чыгара алмыйм.

Соңгы унбиш еллап дәвердә без аның белән гел бергә «Казан утлары»нда эшләдек. Башта икәү генә бер бүлмәдә утыра идек, аннары аердылар. Тик бүлмәдәмени хикмәт! Эшкә мин алданрак бара идем. Ул да иртән килә. Мин коридорда, аның аяк тавышын ишетүгә, каршы чыгам, ә кайчакта ул мине каршы ала. Беренче сорауларыбыз: «Берәр нәрсә яза алдыңмы?» Бу бездәй эшләп иҗат итүче язучыларның төнге эше турындагы сүзләр. Мин үземнең ниләр эшләвемне, ул үзенең ни язганын әйтә. Миңа «мактану» бик эләкми, чөнки төнге язудан башка, аш пешерү, идән-кер юулар да бар бит әле. Рәшит исә һәр төндә диярлек, дүрт кенә юллык булса да, шигырь чыгара.

— Йә, укып күрсәт әле, зинһар! — дим.

— Чынмы? Тыңларсыңмы? — ди.

— Аның нәрсәсенә гаҗәпләнәсең? Кем инде синең шигырьне тыңлаудан баш тартсын?!

— И-и, Кояш, белмисең син, артларыннан инәлеп йөреп тә укыта алмыйм кайберәүләргә, ишетергә дә теләмиләр...

— Әйдә, ярар, зарланып торма әле! Укы, хәзер ятлап алам да бөтен коридор буйлап, кем очраса, шуңа сөйләп күрсәтермен үзем! — дим.

— Җүләрләнмә инде, миңа шул гына җитмәгән! — дип көлә Рәшит һәм укый башлый.

Шагыйрь буларак кына түгел, кешеләрчә ярдәмчеллеге белән дә миңа бик илтифатлы иде ул. Берсендә бик тә авыр хәлдә калдым: өебезнең бер бүлмәсендә 93 яшьлек әнием хәрәкәтсез авырып ята, икенчесендә — ирем, мин уртадагы залда, читлектәге коштай, кая барып бәрелергә белми интегәм. Ике бик җитди авыруны карарга да, эшкә йөрергә дә, җитмәсә, бакчаны барлап торырга да — барына да бер ялгызым. Бакчабыз ерак-та, электричка белән барып, аннан тагын җәяүләп йөри торган урында. Шулай ут йотып яшәгән көннәремнең берендә Рәшит эш бүлмәсенә керде дә:

— Карале, бакчагыз һаман казылып бетмәгән. Мин дустың Марсель Галиев белән дә килешеп куйдым, бер көн билгелик тә, әйдә, бергәләп казып куйыйк! — ди бу. — Җир кызганыч бит,бәрәңге генә үстерсәң дә...

Әй ачуым чыкты, әй гарьләндем!

— Шул безнең уч төбе кадәр бакчадан башка кайгың юкмы, Рәшит?! Булмаса, бар, эчемне пошырып торма әле!

— И-и, нишлисең соң син? Ярар, ярар, миңа димәгәе...

— Сиңа шул сазлык җир кадерлеме, әллә кешеләрне савыктырумы? Өемдә ике хаста ятканын беләсең ич!..

Җүләр димә инде мине: рәхмәт әйтеп, егетләрнең ярдәменә таянасы урынга, Рәшитне эт итеп сүгеп, туздырып ташладым. Алай да эчкә шом кереп калды. Ял көнне өни янына апамны чакырып китердем дә бакчаның эшен бетереп кайттым. Рәшит тә күргән моны. «Молодец, гөл иткәнсең бакчагызны!» — дигән була.

Бакча турында тагын бер фәлсәфә куертып алыйм әле. Безгә ул кишәрлекне: «Язучыларга гына!» — дип, 1975 елда биргәннәр иде. Әй мыскыл да иткәннәр икән. Бу җир кирпеч заводы өчен ике метр тирәнлегендәге сары балчык алынган карьер төбе булып чыкты. Әле дә азапланабыз: аны ел саен су баса, анда алмагачларның тамыры чери, юньле берни үсми. Язучылар — җир белгечләре түгел бит; бергәләп эшкә тотындык, йортлар сала башладык. Мактаныйм әле, безнең өй — миңа калса, иң матуры. Ул Ленин бабайның Петербург янында патшадан качып яткан шалашы рәвешендә салынды. Ике як дивары гел түбәдән генә тора, җирдән үк шифер күтәрелә башлый. Шул сәер кыяфәтне тагын да матурайтыр өчен биниһая биек бу шалаш очына без берәр нәрсә сурәте дә ясап кадакларга булдык. Мин рәссам Илдар Әхмәдиев белән киңәштем. «Үзебезнекенә көнбагышка охшатып, кояш рәсеме кадаклап куйдым, — диде ул. — Кайберәүләр әтәч элә...» Илдарның сүзләре турында уйландым да, әтәчне кире кактым, бер кызыл әтәч, кечкенә чагымда, мине талаган иде, гайрәтем чигеп калды әтәч халкыннан. Инде көнбагыш төслерәк кояш сурәте хакында ни дияргә? Бездә, мишәрләрдә, көнбагышны «айбагар» дип тә йөртәләр. Башыма шул сүз кереп оялады. «Айбагар, айбагар, ай...» Таптым: әтәч тә түгел, кояш та түгел, көнбагыш та түгел, без өй кыегының очына яңа туган ай сурәте кадаклап куярга булдык. Шалаш-өебез биек, аңардан да өстәрәк, колга очында күккә тиярдәй булып ай кадакланган... Аебызны беренче булып Сәет абый Шәкүров котлады, иремә әйтә:

— Кара, кызык иткәнсең син, — ди. — Хатыным — Кояш, өем — Ай! — диярлек бит бу...

Бераздан дустыбыз Марсель Галиев килде. Ул башка яктанрак, яхшы җирле бакча алган иде. «Безнең бакчадан сезнең ай күренә! — ди бу шатланган кебек. — Аны мин сезгә буяп бирим әле! Бик шәп буяуларым да бар...»

Бу егет Рәшит кебек: «Ярдәм итим!» — димәде. Монысы хәйләкәррәк. Аннары аның рәсем сәнгатенә осталыгын да беләбез. «Әйдә соң, буя!» — дидек.

Менеп китте ул сигез-тугыз метр биеклектәге түбә очына. Баскыч-мазар юк, эләгеп кенә тора инде. Җитмәсә, бу көнне бакчабызга бер дустыбыз да килгән иде. Ул, астан, Марсельне тиргәп, әллә нинди күрсәтмәләр биреп тора. Марсель бер кат буяп чыккан иде, дустыбыз, бот чабып, көләргә тотынды.

— Ник көләсең, затсыз? — дип сорый Марсель.

— Мин сиңа яңа кушамат тагам: «Сары ай», ник айны сарыга буядың?

— Әй, ярар инде, — дибез без. — Сары чагы да буладыр айның. Марсельне каушата күрмә, егылса-нитсә, нишләрбез?..

— Егылмыйм! — ди Марсель. — Алай да бу өйрәтүченең сүзендә хаклык бар, акка да буяп алам әле!..

Ай тарихы моның белән генә бетмәде. Берәр атна үттеме-юкмы — мине Язучылар берлегенең ул чактагы җаваплы секретаре Фәрвазыбыз чакыртып алды. Йөзе-бите кара көйгән, иреннәре дерелди, ачы миләш капканмыни:

— Син, кызый, бер дә тик кенә яши белмәдең, — дип башлады ул. — Инде тыныч кына эшләп, шуннан пенсияләргә чыгарсың, дип, ышанып, синең өчен шатланып тора идем...

Фәрваз — группадашым, дустым, миңа зыянга бер эш тә эшләмәде. Мин аннан тел яшереп тормый идем. Әле дә:

— Нәрсә булган, вәгазьләреңне калдырып торып, турысын гына әйт әле! — дим.

— Ни пычагыма әллә нинди айлар куйдырдың бакчаңа? Обкомга китәбез хәзер. Мусинга. Үзе парторг, үзе мәчет ачып куйган, дип шикаять язганнар.

Киттек. Партия өлкә комитетында Мөдәррис Мусиновичның мине ничекләр мәсхәрәләгәнен язып тормыйм. Ул да — гүр иясе бит. Үлгәннәр турында йә яхшыны гына сөйләргә, йә берни дә әйтмәскә өйрәттеләр мине.

Университетта бергә укыган һәм инде теге дөньяга күчәргә өлгергән алты егетнең берсе — Татарстанның күренекле тәнкыйтьчесе Фәрваз Миңнуллин. Ул минем әсәрләрне беренчеләрдән укып, һәрчак гадел бәя биреп, иҗатыма нык ярдәм итте. Узган ел исә, табиблар тарафыннан өметсезләр сафына теркәлеп, үлем түшәгенә ятты. Нишләргә? Хәл беләрә барасы бик килә, тик аңа теләсә кайчан, теләсә ничек барып кереп булмый; ул кызгануларны да, юатуларны да кабул итә торган шәхес түгел. Шулай да җае чыкты: 1994 нең 5 августында аңа 60 яшь тула. Без, Казанда яшәүче сабакташлар, бергә җыелдык та, тәвәккәлләп, киттек өйләренә. Ул чәчәкләр ярата иде. Бер кочак чәчәк алдык. Хатыны, шагыйрә Асия ханым Минһаҗева, безне авыру ире янына үткәрергә бик ашкынып тормаса да, Фәрвазның йокы бүлмәсенә, бәреп кергәндәй, уздык та киттек.

Сүзләр бик табигый башланды. «Шәһри Казан» газетасында эшләүче кызыбыз Рәисә Яхина тиз арада Фәрвазның 60 яшьлегенә карата мәкалә чыгачагын, радиодагы егетләребез Мидхәт Миншин белән Әхмәт Рәшитов шушы көннәрдә аңа багышланган чыгышлар яңгыраячагын хәбәр иттеләр. Китте әңгәмә, истәлекләр. Мин исә, Фәрвазның яраткан җырын ук сузып җибәрдем, миңа фәнни юлда хезмәт итүче кызыбыз Резеда Рәхимова һәм... Фәрваз үзе (!) кушылды:

...Җылы, йомшак җилләр искәндә,
Тәрәзәмне гөлләр чирткәндә,
Карамадың нигә каерылып,
Яннарыңнан үтеп киткәндә?
Җылы җәйләр тик башлана гына,
Әле генә яшелләнә кыр;
Әйтер сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр...

Иң соңгы сүзне Фәрваз алды, гаҗәп сабыр иттереп әйтте ул:

— Мин күп кешеләрнең җеназасын күрдем. Ул чакта мондый хәл миңа да җитә бит инде бер, дип башыңа да китермисең. Җитә икән ул, егетләр, һәрвакыт әзер булып торырга кирәк икән...

Соңгы очрашуыбыз шушы булды. Берничә айдан Фәрваз да мәңгелеккә китеп барды.

Ә бакчабыздагы ай-җаныем һаман тора, селкенми дә, әллә кайдан балкып, күңелләребезгә дәрт биреп тора. Марсельнең буявы да бик шәп булды — һаман ялтырап җемелди.

Бакчаларыбызның бер җирдә булуы Рәшит Әхмәтҗанов белән, гаиләләребез даирәсендә дә, тәмам дуслаштырып җиткергән иде инде. Менә быелгы җәйнең чәчәкләре дә, җиләк-җимешләре дә, Рәшитне юксынып, боегып утыралар. Кем уйлаган? Аңардан мәңгелеккә аерылышуны белсәм, мин үземне соңгы очрашу-сөйләшүләрдә бөтенләй башкача тоткан булыр идем. Әй, бу дөнья!

(Ахыры 23 нче биттә.)

Бу шәхес турында мин беренче мәртәбә Һади Атласов эше белән танышканда белдем. Ләкин әлеге исем моңарчы миңа таныш түгел иде, дип әйтергә җыенмыйм. Татарстан мәдәниятенең үсеш баскычлары турындагы лекцияләргә өзерләнгәндә «Совет Татарстаны язучылары» дигән җыентыкны кат-кат актарырга туры килә иде. Бик мәшһүр булмаган шагыйрьләр рәтендә аның турында да мәгълүмат бар: Б.Сирин (Батыршин

Сират күперен кичкәндә

С.Х.), 1896 елда туган, диелгән. Аннары инде гади крестьян баласының, авыл укытучысының тәрҗемәи хәле сөйләнә. Әдәби таланты Казанга килгәч ачыла... Ун җыентыгы дөнья күргән. Бу инде егерменче елларның ахыры — утызынчы елларның башында шактый мул басылу дигән сүз. Аның соңгы, «Җимеш бакчасы» дигән җыентыгы белән укучы 1933 елда таныша... Монысы белән 1959 елда чыккан җыентыгы арасында утыз еллык тәнәфес була. Сугышта катнашкан, контузия алган дип тә әйтелә белешмәдә. Армиядән кайткач, гади колхозчы булып эшләгән һәм «социалистик Ватанның матурлыгына, бөеклегенә, совет кешесенең бөхетенә дан җырлый торган шигырьләр язган».

СЕРЕҢ АЧ, СИРИН!..

Шагыйрьнең биографиясен шулхәтле шома һәм күтәренке рухта язганы өчен авторны шелтәләмәс идем, билгеле. 1970 еллар башы бу, һәм XX съездда җимергеч ударга дучар ителгән «сталинизм» инде идеология өлкәсендә яңадан башын калкыткан; 60 еллар башында ялтырап киткән хакыйкать кыйпылчыклары инде тоныклана башлаган; зур террор чорында НКВД подвалларында пулялардан һәлак булганнарның үлеме рәсми кәгазьләрдә «авырып үлде»гә әйләнгән, өстәвенә әле үлгән елы да дөреслеккә туры килми торган итеп күрсәтелгән... Әллә кайчан исемсез каберләрдә яткан кешеләрне дә кемнәрнендер «лагерьда күрүе» шуннан килеп чыккан екияттәр.

Инде Атласов эшенә килик. Күренекле фикер иясе һәм галимнән 1936 елның 25 октябрендә чираттагы сорау алына. Шул чакта аңа яшерен шымчының шаһитлар тарафыннан расланган хәбәрнамәсен укып күрсәтәләр. Анда 1935 елның февралендә шагыйрь Сириннең Атласов фатирында советка каршы язылган «Ана», «Анама», «Күтәрик бокалларны» дигән шигырьләрен һәм Сталинга карата язылган ниндидер эпиграмма укуы бәян ителә. Шигырьләр турында тулырак итеп әйтербез, ә менә эпиграмма мәсьәләсендә мәгълүмат бирүчеләр дә, шаһитлар да, ишетеп тә бетермәдек, дигән сылтау белән, шактый тыйнак сөйлиләр. Монысы да аңлашыла, әлбәттә. Тыңлап тордым, истә калдырдым, дип әйтеп кара шунда! Нишләп «тиешле җиргә» шундук хәбәр итмәдең, диярләр иде бугай!

Безгә шунысы мәгълүм: Атласов, бу эпизодны яхшы хәтерләмим, дип әйтә. Ә менә Сиринне белүен һәм аны яшь шагыйрьләр арасында иң күренеклеләр дип санавын, ләкин егетнең футуризм белән мавыкканын хупламавын искәртә. Тикшерүченең футуризм яхшымы, яманмы дигән әдәби бәхәскә керешергә бөтенләй дә теләге булмый. Ә менә Сталинга карата булган эпиграмманың тексты алар кулына кәтелмәгән җирдән килеп керә. Бу турыда соңрак әйтербез.

1933—1959 елларда Сирин Батыршинның тормышында ниләр булган соң? Сугышка катнашуы инде мәгълүм. Тырышып сугышкан, кат-кат контузия алган. Әмма ләкин аңа кадәр Сирингә фронт авырлыкларыннан да зәһәррәк сынаулары үтәргә туры килә.

Илдә һәм, әлбәттә, безнең республикада да иҗтимагый-сәяси вазгыять бу вакытта гаять катлаулы була. Егерменче елларның азакларында һәм утызынчы еллар башында зыялыларга каршы «шахта» эше һәм «промпартия процессы»ннан башланган репрессия тукталмый гына түгел, хәтта соңыннан «зур террор» дигән исем алып, 1937 елда биниһая көч белән күтәрелеп китә. «Зур террор»ның башы булып исәпләнгән «солтангалиевчеләр» эшеннән кала, утызынчы еллар башында Татарстанда төрле дин руханиларының зур-зур төркемнәре репрессияләнә, «Госиздат эше», «Яңа китап», «Сәгыйдуллинчылар», «Җидегәнчеләр» дигән эшләр оештырыла. Бу «эшләрне» өзерләгәндә бик күп күренекле зыялылар: язучылар, галимнәр, журналистлар, наширләр һ.б. кулга алына. Дөрес, ул чакта тикшерү изоляторларындагы гадәтләр әле чагыштырмача йомшак була — кызулык белән бер-икене тондырып алуны исәпләмәгәндә — кыйнаулар кулланылмый. Әмма якыннарыңны утырту белән янау, тоткынлык шартларын начарлату һәм һәртөрле башка махсус уйланган алымнар шәхесне сындыру өчен яхшы чара булып тора.

Киров үтерелгәннән соң террор аеруча көчәя. XX гасырда булган иң серле үлем бит ул — Кировның үлеме. Сталинның бу эшкә турыдан-туры катнашы булуы расланмаса да, режимны тагын да аяусызрак итәр өчен ул моннан файдаланды, билгеле.

Сәяси вазгыять соң дәрәҗәдә кызган шушы мәлдә, түрәләр дә, гади кешеләр дә үзләренең язмышы өчен дер калтырап торган бер вакытта, 1935 елның августында Казанда бер төркем «әдәбият

әһелләре» кулга алына. Барысы турында да сүз алып бармасак та, аларның исемнәрен атыйк әле: Батыршин Сирин, Айдаров Әсгать, Ризванов Габдулла, Кулиев Ибраһим һәм соңрак кулга алынган Хәкимов Исмәгыйль-Энгельс белән Якубов Әхмәт. Баштагы материаллар нигезендә аларны советка каршы коткы таратуда, советка каршы әдәбият һәм порнографик әсәрләр язып, шуларны таратуда гаепләләр. Гаепләүнең соңгы өлеше ачыктан-ачык ясалма булганлыктан, соңыннан төшереп үк калдырыла.

Гаепләнүчеләрдән Хәкимовның эше аеруча катлаулы була. Үзенең бер бик көнче «каләмдәшенең» әләкләвенә караганда, ул «Сталинны үтерергә» теләк белдергән икән. Шул ук әләкченең әйтүенә караганда, Ризванов исә фашистик пропаганда алып барган. Бу эшне ОГПУ хезмәткәрләре бик тиз генә өәвәләп чыгармакчы булалар. Өстәвенә, барлык сорау алынган шаһитлар шымчылык итү юлы белән табылган мәгълүматларны бик рәхәтләнеп раслап торалар, кайберләре хәтта үзләреннән ни дә булса өстәп җибәрәләр.

Бу төркемдә, иң зур һәм иң абруйлы фигура буларак, төп гаеп Сирин өстенә ташлана. Шаһитларның берсе Сиринне Тукайның, Өмирхан, Исхакый һәм Дәрдмәнднең турыдан-туры варисы дип атый. Такташтан кала, барлык шагыйрьләр, Сирин белән чагыштырганда, барысы да икенче сортлы шагыйрьләр икән. Һәм бу, дип өстәгән әләкче, башкаларда көнчелек хисе һәм үч алу нияте уята.

Турыдан-туры яла ягуларны һәм «кеше рухы инженерлары» арасындагы кайбер яшерәк иҗатчыларның кулга алынучылардан үч алуларын исәпкә алмаганда, татар әдәбиятының торышы һәм каләм әһелләренең, аеруча шигърият өлкәсендә эшләүчеләрнең, дәрәҗәләре шактый анык булып күренә. Рәсми әдәбият утызынчы елларда Татарстанда берничә күренекле исем бар, дип әйрәтте, һәм шул ук исемнәр соңыннан әдәбият тарихына да кереп китә торган булдылар. Болар — үзләренең яхшы һәм яман яклары да булган, кылган гамәлләре дә төрле булган кешеләр. Ул гамәлләрне дә тулаем намуслы гамәлләр дип әйтеп булмый. Әмма тормыш тормыш инде ул, шулай булгач, әлеге кешеләр турында да иң элек шигырьләренә һәм чәчмә әсәрләренә карап фикер йөртергә кирәк.

Рәсми даирәдә Сирин бөтенләй искә алынмый. Ә дөресе ничек соң? Талантының көченә, куркусызлыгына, гражданлык позициясенә, иҗтимагый тормышының һәм кешеләр язмышының иң авырткан нечкә кылларына кагыла белүенә карасаң, минем уемча, кулга алынганга кадәр үк ул татар шигъриятендә иң зур фигураларның берсе була. Фактлармы?

Утызынчы елларда аның «Ана» исемле кечерәк кенә поэмасы коллективлаштыру чорында харап ителгән меңнәрчә язмышларның шигъри мәрсия-реквиемына әйләнгән. Әсәрнең герое, яшь коммунист, якыннары, авылдашлары, әнисенең газап чигүләрен күреп; үзенең фирка билетын тотып ыргыта. Аның: «Их, совет, нишләп болай соң бу!» дигән соңгы сүзләре әчке әрнү белән сугарылган. Поэмасын автор тар даирәдә генә укыган, югыйсә, әмма аның кайсыдыр әдип тарафыннан истә калдырылган варианты, машинкада бастырылып, ОГПУ кулына барып эләккән. «Күтәрик бокалларны», «Паганини» дигән шигырьләре һәм башка әсәрләре дә яшәп килгән хакимияткә карата тәнкыйть күзлегеннән чыгып язылган дип табыла.

Булат СОЛТАНБЕКОВ.

(Ахыры киләсе санда).

Кинорежиссер, профессор Булат МАНСУРОВ:



Желаю Вам побольше средств и бумаги, чтобы удовлетворить читательский спрос, вызванный популярностью вашей газеты — Булат Мансуров 22.06.95г

Гариф АХУНОВ, Татарстанның халык язучысы:

«ӘДӘБИЯТТА МИН ТАҢ КОШЫДЫР...»

Атналыгыбызның беренче саны чыгуга әзерләнгән көннәрдә махсус хәбәрчебез Татарстанның халык язучысы Гариф ага АХУНОВ белән әңгәмә корды.

— Яңа гәзит «Мәдәни җомга» чыга башлауга ничек карыйсыз?

— Шундый махсус басманың мәдәниятебезгә багышланып чыгуы Татарстанда яшәүче һәрбер зыялы өчен кадерле. Без бу атналыкны озак көттек. Зарыгып көттек. Яңа бер гәзитнең туган телебездә чыгуы әдипләр, рәссамнар, музыкантлар, артистлар, архитекторлар, башка сәнгать әһелләре өчен ифрат дәрәҗәдә кирәк иде. Ләкин аның кирәклеген иҗат интеллигенциясенә генә кайтарып калдырырга ярамый. Әгәр чыгара белеп чыгарсак, бу гәзит халыкның барлык катламнарын да, магнит кебек, үзенә тартып торачак.

— Моның өчен нәрсә кирәк?

— Моның өченме? Гәзитнең проблемалы булуы зарур. Җитмешенче, сиксәненче елларда иң зур тиражлы басма «Литературная газета» иде. Бу атналыкта илдәге ямьсезлекләр дә, матурлыклар да бердәй тигез яктыртылып барды. Ул гәзит битләрендә дөньяның иң зур акыл ияләре чыгыш ясый, иң көчле проза, иң көчле поэзия әсәрләре басыла иде. Безгә үзебезнең эштә «Литературка»ны үрнәк итеп алырга кирәк түгелме икән? Бездә акыллы язучылар аз түгел, әмма туган телнең кадерен белгән, тел стихиясендә Хәсән Саръян кебек йөзә алган әдипләр аз. «Мәдәни җомга»ның теле туган телне өйрәнү мәктәбе булуын телим мин. Татар телен дәүләт теле итеп ныгыту өчен дә көрәшергә кирәк. Бу мәсьәләдә яңа гәзит төп рольне уйнарга хаклы.

Тормыш белән мәдәният, бүгенге көн белән иртәгәсе көн ныклы бәйләнештә алып барылсын иде. Шул чагында гәзитебез кызыклы булачак.

Язучылар берлегендә хәзер остаханәләр эше җайга салынды. Иң зур әдәби-иҗтимагый журналыбыз «Казан утлары» каршысында яшь каләмнәр берләшмәсе оешты. Ә Татарстанның төрле төбәкләрендә һәм республикабыздан читтә яшәп килгән әдәби берләшмәләр ни хәлдә? Алар җан тәслим кылып ятмыйлармы? Берсен дә күз уңыннан ычкындырмаска иде.

— Ә башка иҗат оешмалары?

— Әйе, мин әле бары тик язучыларны гына кайгыртып сөйләдем. Башка иҗат оешмаларының да хәл итәсе проблемалары күп.

— Аларны безгә кем ачып күрсәтер?

— «Мәдәни җомга», минемчә, һәр иҗат оешмасыннан үз сәнгатенә фидакарьләрчә бирелгән берәр активистны гәзит эшенә тартырга тиеш дип беләм. Әйтик, мәшһүр композиторыбыз Фасил Әхмәтов музыка проблемаларын биш бармагы кебек белә. Профессор Мәхмүт Нигъмәтҗановны мин музыка урманының «санитар бүресе» дип саныйм. Тоталитар система котырып чәчәк аткан чорда да бары тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәгән кайбер «даһилар»ны ул үз урынына утырта алды. Музыкада халык иҗатын, фольклорны аңардан да күбрәк белүче бармы икән?

Җыр мәсьәләсе бездә бик четерекле хәлгә әйләнеп бара. Фасил Әхмәтов әйтмешли, эте дә бете дә көй яза, җыр сүзләре яза. Ул гынамы? Кайберәүләр, хезмәт урыннарыннан файдаланып, үзләренең «...үбәсем килә...» дигән «җырларын» көн саен диярлек (радиодан да, телевидениедән дә) «әйләндерәләр». Ни өчен әрсезләр алга чаба? Чын тәнкыйтьче булмаганга. Иҗат оешмаларының җыр мәсьәләсендә күмәк җыен үткәрүенә 15 еллап вакыт узды. Яңа пленум җыеп, якаларны чишеп сөйләшергә һәм шул сөйләшүне «Мәдәни җомга»да зур итеп яктыртырга кирәктер. Безгә җыр мәсьәләсендә чаң сугарга вакыт!

— Гариф абый, көтелмәгәнрәк бер сорау бирим әле: Александр Солженицын Сезнең өчен кем иде, хәзер кем?

— Солженицын — элек тә, хәзер дә урысның зур шовинисты. Аңа, мәсәлән, «Иван Денисовичның бер көне, яки Җиңүчеләр параді» дигән әсәрендә татарларны мыскыллаган өчен генә дә безнең протест белдерергә хакыбыз бар. Татарның кайбер зур әдипләре, чын мәгънәсендә талантлы әдипләре, Александр Исаевич, дип, авыз суларын корыталар. Без, язучылар коллективы, моңа да каршы чыкмыйбыз. Әнә бит, украин һәм казах язучылары, үзләрен мыскыллаган өчен, бөтен дөнья каршында Солженицыннан баш тарттылар. Үзен халыкларны бик яратучы, аларның хәленә керүче дип санаган Солженицын Россиянең Федераль гаскәрләре Чеченстан халкын канга батыргач, ләм-мим бер сүз дәшмәде. Икенче бер урыс язучысы Ольга Чайковская, җаны ачынып, Солженицын әфәндегә ачык хат язарга мәҗбүр булды. Ул аның халыкларны юкка чыгару сәясәтенә бер сүз дә дәшмәвен гаепләде. Ольга Чайковская белән мин тулысынча килешәм. Ичкерияне буйсындырыр өчен басып керүчеләр гаскәр дип атала, ә туган җирен, туган туфрагын батырларча саклаучылар бандитлар яки законсыз коралланучылар исәпләнелә. Безнең гәзитебездә бу хәлләргә дә анык бәя бирелергә тиеш.

— Солженицын хакындагы бу сораудан тагын бер сорау үсеп чыга бит, Гариф абый. Октябрь революциясен без җитмеш ел буена Бөек Октябрь революциясе дип килдек. Ленинны иң зирәк акыл иясе дип санадык. Хәзер үзгәртеп кору заманы килгәч, Бөек Октябрь революциясен фетнә дип атыйбыз, Ленинны дөнья болгатучы, дибез. Үзгәртеп кору заманын башта озак кына мактадык, инде хәзер тиргибез, совет дәверен сагынабыз. Сезнең моңа карашыгыз ничек?

— Дөнья, кешелек алга таба боларны ничек бәяләр, ә татар халкы өчен боларның икесе дә файдалы булды. Бүген патшаны сагынып, күпме генә күз яше коймасыннар, патша сатраплары татар халкын да, башка халыкны да изгән, кол итеп асраган. Бакча-парклар буена: «Татарларга һәм этләргә керергә рөхсәт ителми», дигән язу куелуы үзе генә ни тора! Татар солдатын рәхимсез кыйнау турында Лев Толстой хикәясен, Горький әсәрләрен, Леонид Леоновның татарларга чиксез бер ихтирам белән караган повестьларын истән чыгармыйк. Рәсәй империясенең халыкларны, милләтләрне никадәр изүен күреп, аларны якларга ташланган Короленколарны истән чыгармыйк. 1905 ел яки 1907 ел революциясе дә татарларга матбугат иреге алып килде, театрларны ачып җибәрде, мәктәпләрдә белем алырга мөмкинлек тудырды. Әгәр коммунистлар партиясе башына оялаган бер төркем бандит, чын мәгънәсендә бандит, шуларның барысын юкка чыгарган икән, биредә революциянең ни гаебе бар?! «Перестройка» дигән сүзне без, татарлар, үзгәртеп кору заманы дип алдык. Мин аны, җимереп кору заманы, дип әйтер идем хәзер. Әмма шушы җимереп кору заманының да безгә, татарларга, файдасы күп тиде. Инде юкка чыгып бара торган татар теле, туган телебезне, мыскыллanудан туктатып, дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрергә мөмкинлек бирелде. Әгәр татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелеп җитә алмаган икән, моңа бары тик без үзебез генә гаепле. Димәк, мөмкинлектән файдалана белмибез. Дөньялар, әлбәттә, бозылды. Моңа шулай ук үзгәртеп кору заманы түгел, җимереп кору заманы гаепле. Дәүләт башына тоталитар заманның элекке түрәләре килеп утырды. Һәм, әлбәттә, алар халык мәнфәгатен түгел, үзләренекен кайгыртып яшиләр.

— Инде, Гариф абый, Сезнең үз тормышыгызга күчик. Тагын ике айдан Сезгә 70 яшь тула. Зур юбилей. Үзегезгә бүләккә берәр нәрсә эшли алдыгызмы?

— Эшләдем, Сөембикә ханым. Өч повесть тәмамладым. Аның берсе — «Арча җиренең ачык китабы» дигән документаль повесть. Без аны журналист Мәгъсүм Гәрәев белән бергәләп яздык. «Казан утлары»ның быелгы икенче санында басылып чыкты инде. «Татарстан хәбәрләре»ндә ул уңай бәя дә алды. «Тимерханның авыл юллары» дигән икенче документаль повестем «Татарстан» журналында дөнья күрәчәк. Заманында мин «Йолдызлар калка» дигән автобиографик повесть язган идем. Быел шуның икенче китабын тәмамладым. Повестьның кайбер бүлекләре минем бәйрәмемә «Казан утлары»нда басылачак.

— Шул уңайдан бер сорау: документаль әсәр язуны иң авыр эш, диләр. Сез — зур романнар авторы, нигә документаль повестьларга керештегез?

— Беренчедән, мин кырык ел буена көндәлек алып барам. Тормыштагы бер нәрсә дә минем күздән ычкынмый. Соңгы елларда документаль повестьлар язуыма, ихтимал, шул да сәбәп булгандыр. Урыс әдәбиятының бөек даһие Лев Николаевич Толстой әйткән иде: «Килер бер көн, язучыларга үзләре уйлап чыгарырга кирәк булмас, язучы үзе күргәнне, кичергәннәрне генә язар». Моны миңа университетта укыткан остазыбыз, мөхтәрәм язучы һәм галим Хатип ага Госман да 25 еллар элек әйткән иде инде. Документаль әсәрләрнең кирәклегенә мин көннән-көн ныграк инана барам. Менә сезнең адашыгыз Ханбикә-Сөембикә ниндирәк булды икән? Аның төсе, чәчләре, толымнары нинди булды икән, дип баш ватабыз. Әгәр елъязмачылар безгә Сөембикәнең сурәтен һәм башкарган эшләрен язып калдырган булсалар, без нинди бәхетле булыр идек, гөман кылып утырмас идек.

— Гариф абый, Сез — татар әдәбияты, халкыбыз өчен үзегез бер хәзинә. Юк, бу «Хәзинә» романы исеме белән сүз уйнату гына түгел. Шулай да алда язылачак нинди хәзинәләрегез бар?

— Мин, Сөембикә сеңлем, үзем өчен максат итеп, минимум һәм максимум дигән планнар корган идем. Минимумга әдәби әсәрләр иҗат итүне керттем. Ул планым инде үтәлеп бетә язды. Монда бары тик «Идел кызы» трилогиясенең өченче китабын тәмамлау гына калды. Дөресен әйткәндә, бу эш тә эшләнә. Мин аны озакламый тәмамлармын да. Максимум итеп мин Тукай турында нәфис фильм төшерүдә катнашуны санадым. Аллаһыга шөкер, ул максатым да тормышка ашып бара. Талантлы режиссер Әхтәм Зарипов мин һәм үзе язган сценарийның фильмнарын төшерде инде. Мин аңа бик рәхмәтле.

— Гадәттә, талантлар тудыргач, табигать ял итә, диләр. Сезнең улыгыз Рәшит Ахунов та республикада гына түгел, күрше төбәкләрдә дә танылып китте. Күптән түгел аны Президент Указы белән Татарстан тышкы икътисадый элемтәләр министры итеп билгеләделәр...

— Ял итәдерме, юкмы, белмим, мин улымның хезмәт яратучы кеше булуына шатланам.

— Аны хезмәт яратучы итеп Сез тәрбияләгәнсездер бит?

— Юк. Аны әнисе Шәһидә Максудова тәрбияләде. Үзем җәмәгать эшеннән бушамадым. Минем өстә 17 төрле вазифа бар иде. Мәскәү һәм чит ил юлларында да күп йөрергә туры килде.

— Шулаен шулайдыр да бит. 55 китапны 70 яшькә ничек яза алдыгыз соң? Минем аңлавымча, Сез 45 ел хезмәттә булгансыз, ягъни, университет бетергәннән башлап...

— Әдәбият һәм сәнгатьтә бар «таң кошлары», бар «төн кошлары». Әдәбиятта мин — таң кошыдыр. Көн саен сәгать 4 тә торып, җәмәгать вазифамны үтәргә керешкәнче, язу өстәле янына утыра идем. Биш бит язу язмасам, тынычлануны белмәдем. Китаплардан укыганым бар: дөньяның 90 процент язучысы көненә биш бит яза алган.

— Арча җире бик күп талантлар бирде. Хәзер бу төбәк ял итмиме соң?

— Ихтимал, ял итүе дә мөмкин. Соңгы ун ел эчендә, ялгышмасам, Арчадан талантлы шагыйрь Наил Касыймов кына чыкты. Арча хакимиятенең әдәбияткә һәм сәнгатькә бик нык игътибар итүен исәпкә алсак, анда талантларның яңадан калкып чыгуы мөмкин.

— Гариф абый, алайса, соңгы сорау: Сез Татарстан Язучылар берлеген озак кына җитәкләдегез, РСФСР һәм СССР Язучылар берлекләре секретаре булдыгыз. Язучыларны үстерүнең иң мөһим чарасы нәрсә дип саныйсыз?

— Яшьләр белән эшләү, яңа талантларны табу, аларга ярдәм итү. Бөек остазыбыз Алексей Максимович Горький: «Физик яктан мин Түбән Новгородта тусам, рухи яктан Казанда тудым», — дип исәпләгән кеше. 1934 елны Бөтенсоюз язучылар съездына йомгак ясаган чакта, «Безнең төп эшебез яшьләр белән эшләү булырга тиеш. Шулай булмаганда, мондый зур җыенны җыеп азаплану да кирәк түгел иде», — дип әйтте.

Татар әдәбиятына мин зур өметләр баглыйм. Безнең халыкларның әле талантлар чишмәсе кипмәгән. Әмма без соңгы елларда Татарстаннан читтә, аерым төбәкләрдә тупланып яшәүче татарлар белән эш алып бармый башладык. Ә бит Такташлар, Җәлилләр, Нәҗмиләр, Тинчуриннар, Хатип Госманнар, Әпсәләмовлар татар әдәбиятына башка өлкәләрдән килгәннәр. Сибелгән-чәчелгән татар дөньяның барлык почмакларына барып урнашкан. Аларны рухи берләштерү, туплау, алардагы яшь талантларга игътибарлы булу — безнең мөһим бурычыбыз.

Әңгәмәне Сөембикә КАШАПОВА оештырды.

МӨФТИ ФАТИХА БИРӘ

Бисмил-ләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Әссәламе галәйкүм вә рәхмәтуллаһы вә бәракәтүһ, мөхтәрәм газиз кардәшләрем!

Мәркәзебездә «Мәдәни җомга» басмасы чыга башлау уңаеннан һәрберегезне дә ихлас күңелемнән котлыйм, Аллаһы сөбханә вә тәгаләдән килгән хак дин белән гамәл кылуыгызны телим!

Динебездә көннәрнең олугы һәм изгесе булган Җомга көн бар. Бу көнне атабыз Адәм галәйһиссәлам яратылган. Димәк, барыбызның да бар булган изге көнебез. Җомга мөселманнар өчен бәйрәм көн, әһле ислам каршында догалар һәм изге гамәлләр кабул була торган мөбарәк көндер. Рамазан һәм Корбан бәйрәме айларында, шулай ук башка изге айларда, изге кичләрдә һәм бөтен көннәрдә дә күңелләребезне, рухыбызны агарту һәм пакьләндерү, бакый иманыбызны ныгыту, гамәлләребезне барлау белән мәшгульбез.

Газета укучылар да «Мәдәни җомга» басмасының тәүге санын укып, икенчесен кулына алганда, үз-үзенә сорау бирсә иде: мин дөрес яшимме? Теге яки бу гамәлемне дөрес эшләдемме? Тапкан дәүләтем, акча, ризыгым хәләлме? Безгә зирәк зиһен, үткен фикер, камил гакыл, күркәм холык, тулы иман бир, дип, Аллаһыдан сорадыммы? Гамәл-гыйбадәтем бармы?

Ният-эш-гамәлләребез барып чыкса, юлларыбыз уңса, Аллаһының безгә биргән бихисап нигъмәтләренә шөкер итүебезне белдерәбезме? Менә шушы сорауларны үзебезгә һәрдаим биреп, иманыбызны ныгыта, рухиятебезне агарта барсак, холкыбызны төзәтсәк, яшәү рәвешебезне шәригатьчә үзгәртсәк, Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып көн күрсәк, гөнаһлы эшләрдән, хөсетлектән, сәрхүшлектән, ямьсез хәл-күренешләрдән, бәла-казадан, афәтләрдән, әхлаксызлыктан котылырбыз, яхшы яктан үрнәк мәмләкәткә әйләнербез, дәүләтебезгә ирешербез, иншаллаһ.

Әйтәсе сүзләрем күп, газета битләрендә очрашырбыз, Аллаһ насыйп итсә. Халкыбызның дини-иҗтимагый тормышын тагын да җанландырып, тергезеп җибәрерсез, дигән өметтә калам. Милләтебезнең Ислам белгечләре, галимнәре дә күп бит. Алар турында һәм аларның да хезмәтләрен дөньяга чыгаруыгызга ышанам.

И, Раббыбыз, Татарстан җөмһүрияте башлыкларына зирәк акыл бир, ил-көннәребезгә иминлек бир! Кардәшләрем, сезнең барчагызга бәхет-сәгадәт, хәерле гамәлләр һәм сәламәтлек телим. Вәссәламе галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Сезгә котлау, олы ихтирам вә хөрмәт һәм изге догалар белән: Татарстан җөмһүрияте мөселманнарының Диния Нәзарәте Рәисе, Мөфтие Габдулла хәзрәт Галиулла.

ЕРАКТА — ЙӨРӘКТӘ

ОКЕАННАР КИЧЕП КАЙТКАН АКЧАРЛАК

Мин дә сибелгән татарның
Бер газиз баласы ла!..

Шагыйрә дустым Флера Гыйззәтуллинаның бер җырында әнә шундый сүзләр бар.

Бөтен дөньяга сибелгән татар халкының бик күп газиз балалары төрле тарихи фаҗигаләр, төрле тормыш шартлары нәтиҗәсендә чит җирләрдә һәлак булып калганнар яки милли йөзләрен югалтып, башка милләт кешеләренә әверелгәннәр. Ә менә ерак Американың Сан-Франциско шәһәрендә яшәүче Шәмсия Апакай төрле сынауларга, авыр язмыш әзәрлекләвенә карамастан, чын татар булып калган. Әлеге җырда әйтелгәнчә — сибелгән татарның бер газиз баласы... Шулай булмаса, ул 20 ел буена, һәр елны, ә берсендә хәтта ике тапкыр Татарстанга кайтып, туганнары белән күрешеп, Пенза якларына барып, ата-бабалары туфрагына баш орып, нәсел-нәсәбе күмелгән зиратка, Казанда танышып-дуслашкан Рөстәм Яхин, Бакый Урманче, Мостафа Ногман кебек дусларының каберләренә зиярәт кылып йөрмәс иде.

Менә быел да Шәмсия апа, океан артларыннан очып кайткан акчарлак кебек, Казаныбыз туфрагына тагын аяк басты. Инде туганнары гына түгел, хәзер монда аның сагынып күрешергә ашкынган бик күп дуслары бар. Һәр кайтуындагы шикелле, быел да ул театрларга, концертларга йөри, музейлардагы очрашуларга катнаша, радио, телевидение буенча чыгышлар ясый. Кунак булып, сыйланып кына яту аңа хас түгел, ул актив мәдәни тормышта кайный.

Шәмсия апаның яше шактый зур инде — сиксәннең өстендә. Шулай да үзен яхшы хис итә, сәламәтлегеннән зарланмый. «Кайтмый кала алмыйм, чөнки сагынам, исән чакта, иншалла, һәр елны кайтачакмын», — ди ул, ягымлы елмаеп. Ягымлылыгы аның йөрәкләрне эретерлек. Яшь чагында аның Харбин шәһәрендә үткәрелгән чибәрләр конкурсында җиңеп чыккан гүзәл ханым булуы да мәгълүм. Йөзе, бите, күзе, кашлары — чын татар хатын-кызларына хас камил, матур; борынгы Болгар кызлары, мөгаен, шундый булгандыр, татар хатын-кызларының гүзәллеген борынгыдан бүгенгегә алып килгән заттыр ул.

Әти-әниләре Пенза өлкәсе, Юнә авылы кешеләре булган. Ә Шәмсия апа үзе Пензада да, Татарстанда да тумаган югыйсә, ерак Камчаткада Петропавловск шәһәрендә дөньяга килгән. Бер уйласаң, нигә Татарстанга ашкына икән соң бу, туган җире дә түгел бит, дип әйтергә мөмкиннәр. Юк, Шәмсия апа үзен Татарстанда туган кеше итеп тоя, татарның мәркәзе булган Казан аңар туган каласы кебек якын. Аңарда чын татар каны ага, аны чын татар җаны яшәтә. Татар халкы язмышы — аның язмышы. Ул — милләтебезнең бер очкыны, сүнмәс очкыны.

Бөтен гомерең чит илләрдә үтсен әле. 1924 елда алар Кытайга күчеп китәләр. Тире-яры белән сәүдә итүче әтисенә илне тетрәткән давыллы революция киңәеп яшәргә мөмкинлек калдырмый, күрәсең, бик күп татар гаиләләре күчеп киткән Кытайга барып урнашырга мәҗбүр була ул. Шәмсия апа 1937 елны шунда яшәүче Салих Апакайга кияүгә чыга. 1951 елны алар Төркиягә күчеп китәләр, 1961 елдан инде Америкада гомер кичерәләр. Менә 58 ел буена алар матур гаилә булып яшәп, Вилдан атлы ул үстергәннәр, хәзер оныкларын тәрбияләшәләр.

Шәмсия апа гаять дәрәҗәдә укымышлы кеше. Гимназия, колледжлар тәмамлаган, аннары үзлегеннән укып, белемен күтәргән. Әдәбиятны, музыканы, тарихны яхшы белә. Аны «аяклы энциклопедия» диярсең, белмәгән нәрсәсе юк. Инглиз, төрек, кытай телләрендә иркен сөйләшә. Чит илләрдә гомер иткән кешенең бу телләрдә сөйләшүе гаҗәп түгел, ә менә татар телен, шулай ук урыс телен камил белүе сокландыра. И аның саф татар телендә сөйләшүе, чыгышлар ясавы! Күпләр Шәмсия ападан үрнәк алсын иде. Ни аяныч, үз илебездә яшәп тә, күбебез ана телебезне белмибез, белергә тырышмыйбыз. Бигрәк тә балаларыбыз. Аларны татарча тәрбияләргә, күңелләренә татар рухы кертергә омтылмыйбыз. Шәмсия апа татар телен «күз буяу» өчен генә белүче түгел, ул татар әхлагында тәрбия алган, шуңа да милли йөзен саклап калган. Саф татар телендә сөйләп кенә калмый ул, саф татарча моңлы итеп җырлый да, мөнәҗәтләр дә әйтә. Шәмсия апа балачагыннан ук бик төпле дини тәрбия алган. Коръәнне яттан белә, догалар укый, уразасын да тота, намазын да калдырмый.

Үзе татар булып калу белән генә чикләнмәгән Шәмсия апа, балаларын, оныкларын да чын татар итеп тәрбияләгән. Үз балаларын, үз оныкларын гына түгел, үзе яшәгән илләрдәге татарларны да, аларның кыз-улларын да чын күңеленнән татарча тәрбияләү эшенә бирелгән. Балалар бакчалары, якшәмбе мәктәпләре ачып, яшь милләттәшләренә ана телен өйрәтә, дини гыйлем бирә.

Шәмсия апа сәясәт белән шөгыльләнми. Әмма аның тормыш рәвеше, яшәве, тәрбияче буларак тынгысыз хезмәт белән үткән гомере үзеннән-үзе сәясәткә килеп бәйләнә. Ул халыклар арасында тынычлык, дуслык булуын тели, кан коюларга каршы килеп, һәр сәяси мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә чакыра. Безнең Татарстан сәясәтен чын күңеленнән яклый. Хөкүмәтебез җитәкчеләренең, бигрәк тә Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең җөмһүриятебезне тыныч юл белән мөстәкыйльлеккә алып баруына өметләнә, милләтебезнең киләчәге турында борчылып, кайгыртып яши.

Америкада ул зур җәмәгать эше алып бара. Анда яшәүче татарлар җәмгыятендә милли мәдәниятебез һәм сәнгатебез казанышлары белән таныштырып баруда көчен кызганмый. Хәләл җефете Салих ага белән бергәләп, Америкада яшәүче милләттәшләребезгә татар китаплары, татар җырлары язылган пластинкалар, кассеталар тарата. Алар — безнең сәнгатебезне, моңнарыбызны океан аша ерак Америкада, анда гына түгел, Австралия, Германия, Финляндия, Канадада яшәүче татарларга да җиткезүче игелекле җаннар.

Казанда яшәүче туганнары Нури, аның җәмәгате Әлфия ханым Апакайлар һәм аларның балалары Шәмсия апаны хөрмәтләп каршы алалар, зурлап кунак итәләр. Бу килүендә мин Әлфия ханым әзерләгән чәй табынында Шәмсия апа белән иркенләп сөйләшеп утырдым. Мондый кеше белән бер сөйләшү үзе бер гомер.

Әңгәмәбез ахырында мондый сораулар бирдем:

— Чит илләрдә яшәп тә, чын татар булып калу җиңел булмагандыр. Моңа ничек ирештегез?

— Әлбәттә, татар булып калу җиңел түгел. Беркайда да безне, ишекләрен киң ачып, татар мәктәпләре көтеп тормады. Беркайда да безне, татарларны, башка милләт кешеләре кочакларын җәеп каршы алмадылар. Һәркайда тырышып хезмәт итеп, үз көчебез белән үз тормышыбызны алып бардык. Мин үзем аэрофлот ширкәтендә озак еллар аш-су әзерләүче булып эшләп, пенсиягә чыктым. Күп нәрсә һәр кешенең үзеннән тора. Һәр кеше, кайсы илдә яшәсә дә, әгәр теләсә, үзенең милли йөзен саклый ала. Америкада — ирек. Һәр кеше үзе теләгәнчә яши, үз динен тота. Ләкин анда милләтләрнең үз йөзләрен саклау өчен махсус чыгарылган законнар юк. Үзеңне, үз милли йөзеңне саклау өчен үзең тырышырга тиешсең, — диде Шәмсия апа соңгы сүзләренә аеруча басым ясап.

Әйе, һәр кешенең үзеннән тора. Безнең дә үзебездән тора. Милли мәсьәләләргә кагылышлы шактый әйбәт законнар чыгарылса да, арабызда милли йөзләрен сакламаучыларның бик күп булуы өчен без үзебез гаепле. Әйдәгез, кадерле милләттәшләр, үзебезнең татар икәнлегебезне бер минутка да онытмыйк, милли йөзебезне саклап, телебезне, моңыбызны саклап, балаларыбызны татарча, татар әхлагы белән тәрбияләп, ана телебездә сөйләшеп яшик.

— Казанга 20 ел буена кайтып йөрисез. Соңгы елларда кайтуыгыз күңелегездә нинди тәэсирләр уятты? Казанда үзгәрешләр сизеләме? Без кайсы якка үзгәрәбез? — дип сорадым.

— Яхшы якка үзгәрәсез. Ни дисәң дә сездә хәзер сүз һәм гамәл иреге. Ә бу бик мөһим нәрсә. Аннары соңгы елларда
Казан пөхтәрәк күренә. Казан
зурая. Яңа бинлары белән
зур-зур кварталлар үсеп чык-
кан. Яшелләндерү эшләре дә
бара. Тик шунысын әйтми бул-
мый: кызганычка каршы, исе-
рекләр күп. Эчүчелек арткан.
Хәтта татарлар да, татарның
хатын-кызлары да эчә. Бу без-
нең милләткә хас сыйфат тү-
гел. Зур гөнаһ бу. Аннары кай-
бер кешеләрдә ялкаулык бар-
лыгы сизелә. Балаларын тата-
рча тәрбияләүгә, ана телен бе-
лүгә әһәмият бирмәүчеләр
шактый.

Шәмсия апаның милләтебез
язмышы өчен борчылып әйт-
кән бу сүзләре белән әрнеп ки-
лешәсең.

Милләтебезнең ерак Аме-
рикада яшәүче күркәм дәү
апасы Шәмсия Апакайга бар-
лык газета укучыларыбыз исе-
меннән сәламәтлек, озын го-
мер, бәхет-сәгадәт телик. Шу-
лай ук затлы милләттәшебез
Салих ага Апакай белән бер-
гә-бергә тигез, матур гомер ки-
черсеннәр. Шәмсия апабыз
безгә гыйбрәтләр, үрнәкләр кү-
рсәтеп, Казаныбызга шулай
кайтып йөрсен.

Афәрин, Шәмсия апа!..

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА.

Утырганнар: Шәмсия Апакай, Бакый Урманче; басканнар:Әлфия Апакай, Флора Әхмәтова.

Татарстанның, Россия Федерациясенең халык артисты, композитор Фасил ӘХМӘТ:

Мин, мәдәният өлкәсендә эшләүче шәхес буларак, «Мәдәни җомга»га сандугачтай моңлы аһәң телим.

Ф. Әхмәтов
13/VII-95 ел.

Рашат НИЗАМИ

Йортны ничек табасы...

Юмореска

Шулай бервакыт шәһәргә кунакка килдем. Мин инде үзем авыл гыйбады: авылча үскән, авылча тәрбияләнгән. Сүгенергә туры килсә дә: «Корт чаккыры!» дигәннән узганым юк. Шәһәр бөтенләй башка инде, анда «культурный» халык яши, дип эчтән генә сокланып йөрим.

Шәһәргә нигә дип килгәнемне әйтим, булмаса. Энекәш калада яши минем. Бик булдыклы, эшчән егет. Менә шул тырышлыгы аркасында 39 нчы мәхәлләдән өч бүлмәле яңа фатир алды. Фатирларын күрәсе, рәхәтләнеп котлыйсы иде бит энекәшне! Менә шуңа да, бер капчык авыл күчтәнәчләре төяп, ишек төпләренә килеп туктадым. Звонок төймәсенә басам, ачылмый гына ишек. Өйдә түгелләр, күрәсең. Ярый әле күршеләре чыгып кичен генә кайтачакларын аңлатты. Күчтәнәчләрне шуларда калдырып, «гуляйть»кә чыгып киттем.

Яшерен-батырын түгел, шәһәргә килдемме, мин үзем сыра эчәргә бик яратучан. Чөнки авылда ачы балны күпме теләсәң, шулай эчәргә була, әмма ләкин сыраны таба алмыйсың инде. Тансык ул миңа. Әйләнә-тулгана торгач, таптым бит сыраханәне. Ни өкемәт, бер чатта өч кеше басып тора. Авыз тутырып сүгенәләр: фәлән-фәсмәтән... «Авызыгызны корт чаккыры!» дидем дә, сыраханәгә уздым. Тамак бик чатнаган иде. Каршымдагы бокалга карыйм. Әй, күбегенең җемелдәп торулары! Әй, гәрәбә төсендәге сыраның мөлдерәп миңа караулары...

Кыскасы, бик тә кәефләнеп чыктым мин урамга. Ләкин өстегезгә гөнаһ ала күрмәгез: мин һич тә исерек түгел, бары тик күтәренке кәеф белән асфальт өстеннән бер көйгә шак-шок атлый бирәм. Менә шуннан соң минем өчен көтелмәгән тамаша башланды да инде.

Энекәшнең өй адресы күчтәнәчләр сумкасында онытылып калган бит. Әй... Барам да барам, карыйм да карыйм: тирә-юньне игезәк йортлар басып алган — кайсына барып керергә дә белгән юк. Миңа илле дүртенче фатир кирәк, энекәш шунда тора. Бер йортка барып керәм, шалтыратам — ни энекәшне белмиләр, ни күршеләре миңа таныш түгел. Шакмак-шакмак булып утырган биш-алты йортны әнә шулай урап чыктым — юк, һич кенә дә табып булмый бит энекәшнең йортын. Бу архитектор дигәннәрен әйтер идем, һәр йортка аерым бер кыяфәт биреп булмас иде микәнни соң? Юкса, ике тамчы су кебек, бер-берсенә тәмам охшашканнар әнә...

Чү! Таныш нәрсә күзгә чалына түгелме соң? Әйе, энекәшләр йорты подъездының бер почмагына, кадак белән тырнапмы шунда, урысның өч хәрефле... әшәке сүзен язып куйганнар иде. Шул бит бу, шул! Соңгы хәреф өстендәге «көймә» сыманрак тамгасына хәтле таныш... Димәк, энекәшнең өе табылды дигән сүз.

Ә шулай да, җәмәгать, йорт тикле йортның маңгаена шундый әшәке сүзләр язып кую бер дә яхшы түгел. Тикшерә китсәң, исем-фамилиясен дә юньләп язэ белмидер әле ул мәлгунь кисәге. Мондыйларның кулына сугарга кирәк, корт чаккыры!

Әмма дә ләкин шушы өч хәрефле сүзнең кечкенә генә булса да ярдәме тисә дә тияр икән!

Хәниф ХӨСНУЛЛИН

Гомерлек спонсор*

Спонсор эзли Нургата,
Авылында тапмады.
Өмет итеп, айлы төндә
Күрше авылга атлады.
Килеп керде нурлы йортка —
И клуб, дөртле клуб!
Яшә син яшь йөрәкләрнең
Күрешү җире булып!
Тик ни хәл бу, Нургатаның
Юлы тагын уңмады.
Чыгып, бишле биергә дә
Кызлар җыеп булмады...
Булды заман, интектерде
Шырпы һәм тоз юклыгы.
Аннан да зур җан ачлыгы —
Авылда кыз юклыгы!
Башкалар күк Нургата да
Ялгызы калсынмыни?!
Заграничный кызлар сорап,
БМОга язсынмыни?!
Их, үз авылында булса соң,
Я күрше авылныкы!..

Дошманына да теләми
Ул мондый авырлыкны...
. . . .
Шушы сагышларын көн дә
Чүмәләләп әйгәндә,
Кызлар эзләп, авылыннан
Чыгып китәм дигәндә,
Бәрәкалла! Күк капусы
Ачылып киткән ләса;
Авыл җирен кунак кызы,
Калып, үз иткән ләса!
Күрде һәм әйтте Нургата:
«Менә ул көткән җырым,
Кара кашлы, озын чәчле
Гомерлек спонсорым!..»
...«Ничек торалар?» — дисезме —
Матур гына, авылча...
Мин дә шулай яшәр идем,
Бер спонсор табылса...

*** Әле былтыр гына вафат булган шагыйребезнең бу әсәре аның шәхси архивыннан алынды.**

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Китап шулай куша...

Каенана киленнең өй эшләрендә булышмавыннан, аның гел музыка тыңлап, «Файдалы киңәшләр» китабы укып кына ятуыннан зарлана. Бу хакта киленнең үзенә дә әйткән. Ә тегесе аптырап калмаган:

— Мин туачак балам композитор булсын өчен музыка тыңлыйм бит! «Файдалы киңәшләр» китабында шулай кушканнар, — дигән.

Авыл күчтәнәче

Маһибәдәр әби күчтәнәчсез кайтып төшкән кунакларга гел: «Һи, сез үзегез күчтәнәч», — дип әйтергә яраткан.

Бу юлы әби улларының берсенә мондый эчтәлекле телеграмма суккан: «Заманалар авыр, быел җәй үзем сездә күчтәнәч булып яшәрмен инде».

Үлем түшәгендә

Утыз өч ел буе хәмердән айнымаган илле өч яшьлек Мордар үлем түшәгендә телдән кала. Хәлен белергә килгән шешәдәше аның кулына буш шешә тоттыра. Мордар шунда ук телгә килә һәм «Российское пиво-о-о!!!» дип кычкырып җибәрә.

Керсәң — чабып-йөгереп кер

— Начальник янына абына-сөртенә керергә кирәк. Эш өчен янып-көеп йөри икән бу, дип әйтерлек булсын, — дигән бер ялкау.

Әйттем бит, югыйсә...

— Дәү әни, кичә ике туңдырма ашагач, тәти апаның тамагы шешкән.

— Мин аңа туңдырманы табага салып, кыздырып бирим, дип әйттем, сүземне тыңламады бит.

Мәзәкләрне Нил ГАРИФУЛЛИН язып җибәрде. Лаеш районы.

Мәкальләр елмаяламы?

■ Бохар ханына: «Халык бик ачка үлә», — дип хәбәр иткәч, «Нигә пылау ашамыйлар?» — дип сораган, имеш.

● Сигез көнгә тугыз бәйрәм.

■ Әби патшадан калган... һөнәр (фахишәлек күздә тотылмый. — Ред.)

■ Түшәктән тәгәрәмәскә түмгәк, җеннән курыкмаска иптәш.

● Ике киленнең чабатасы мичтә сугыша.

■ «Чыкмый, чыкмый, дип әйтәсең, чеметеп-чеметеп саласың; сал бер уч, чыгармын нибуч!» — дип әйтте, ди чәй.

■ Аракы бер стакан эчкәч әйтә икән: «Иптәшем калды, аны да алып кер!» — дип.

● Башың түгәрәк тә, колакларың мишәйт итә.

■ Җилкә чокырымны күрми торам, сине дә күрми торырмын әле.

■ Ике кодагыйның арасына алтмыш ел элек кар тавы үсеп куя, ди.

● Әй доньья, буялган йонга, буялса иде мамыкка, рәхәт булыр иде халыкка.

Сәяси мәзәк

Бөяләр арткан заманда

Кремльнең зиннәтле бер кабинетында Брежнев җыйнак кына түгәрәк өстәл тирәли үзенең якын ярдәмчеләре белән утырып алган да «Бөяләр арта» уенын уйната. Өстәлдә күрсәткеч угы булган бөтерчек әйләнә. Ә түгәрәк кырые буйлап алфавит тәртибендә тиешле хәрефләр язылган. Бөтерчек угы бер хәреф өстенә килеп туктавы була, Брежнев нинди әйбергә хак артуын әйтеп бирә.

— «А» хәрефе, — ди уенны алып баручы Суслов.

— Автомобильләр, — дип җавап кайтара Брежнев. — Җиңел автомобильләр...

— «Т» хәрефе...

— Таблеткалар. Барысы да...

— «А» хәрефе.

— Әйттем бит инде, — ди Брежнев, тавышын күтәрә төшеп.

— Тагын килеп чыкты бит, Леонид Ильич, — ди Суслов кыюсыз гына.

— Ә, ярар. Алтын, алайса...

— «К» хәрефе.

— К-к-к... Келәмнәр... Уф, арытты!..

— Соңгысы, соңгысы, Леонид Ильич. Менә «П» хәрефе...

— Петте-китте, алайса...

— Бетте, бетте, Леонид Ильич. Хәзер йокы бүлмәгезгә алып китәрләр үзегезне, ял итәрсез...

Брежнев шунда ук: «Бәй, нигә татарча килеп чыкты соң әле бу уен?» — дип уйлап куйды. Һәм бер нәрсәне исенә төшереп алды: «Ә-ә, Татарстаннан яшьләр өчен бер журнал чыгару турында үтенеч җибәргәннәр бит. Шуны искә төшерәләрдер әле, — дип нәтиҗә ясап куйды. — Юк инде, апаем, бөяләр арткан заманда...»



Чит ил матбугатыннан.

Кәбир Бәкернең тууына 110 ел тулу мөнәсәбәте илә

Тукай исемен әйтүгә аның белән янәшә иң әүвәл Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал күз алдына килеп баса, алардан соң Сәгыйт Рәми, Сәгыйт Сүнчәләй мәшһүр шагыйрьнең дуслары буларак телгә алына. Әмма Тукайга тагын да якынрак торган берәвенең исеме ничектер онытылып кала. Исемнәре аталган шәхесләр шагыйрьгә иҗат, эстетика, рух химаячеләре сыйфатында якын торса, Тукайның иң якын сердәше, яшерен халәтен яшермәенчә сөйли алырлык җандус булган бер кеше бар — Кәбир Бәкер. Тукайны бик-бик якыннан өйрәнгән, белгән, гаять сәләтле, күзәтүчән кеше генә «Тукай Петербургта» кеби тирән вә кыйммәтле әсәр яза ала. Шагыйрь турында язылганнар арасында, миңа калса, иң әһәмиятлесе шушы китаптыр.

Кәбир Бәкер турында бик әз языла. Исмәгыйль Рәминең «Әдәби сүзлеге»ндә дә аның хакында мәгълүмат саран. Ул 1885 елда Орынбур янындагы Зубачы (Түбән Үзарнай, Нижнее Озерное) авылында күп балалы мулла Кәримҗан Бәкер гаиләсендә дөньяга килгән. Заманында журналист, хикәяче, драма әсәрләре һәм театр сәнгате турында күп санлы мәкаләләр язучы буларак танылган. Кәбир әфәнденең театр турында язучы буларак, иң нәтиҗәле, иң тирән мәгълүматлы белгеч икәнлеген без һәнүз Мәхмүт вә Илтани Илалованың Бәян Гыйззәт белән берлектә чыгарган «Революциягә кадәрге татар театры» исемле китабындагы астөшермәләрдән дә чамалый алабыз. Һәр бүлек вә һәр сәхифә саен дип әйтерлек, «К.Бәкер» һәм «Казак» имзалары укучыны китап азагына хәтле озата бара. «Казак» — Кәбир Бәкернең кушаматы. Чөнки ул атлы казаклар авылында туган.

«Тукайның якын дусты» дәрәҗәсен яулау теләсә кемгә тәтемәгән, Тукай турында шундый тирән мәгънәле әсәрне теләсә кем язалмый. Шундый сирәк очрый торган шәхес турында тарих нигә дәшми икән, дип мин эзләнергә тотындым.

Кәбир Бәкернең исеме Фатих Әмирхан хатирәләрендә бер-ике тапкыр мактау сүзләре илә телгә алына һәм аны без 1907 елда «Әльислах» гәзитәсе бүлмәсендә алынган сурәттә Фатих Әмирхан, Тукай, Вафа Бәхтияр, Ибраһим Әмирханнар арасында күрәбез: бөекләр белән янәшә. Кара мыеклы, куе-кара чәчле, кара кашлы, зыялыларча киенгән мәһабәт җегет Фатих Әмирханга аркадаш булып утыра. Без аны Тукайның Уфадан Питербургка, Кәбир Бәкернең үзенә язган хаты буенча да бераз беләбез. Бу хат — Кәбир Бәкернең, Шакир Мөхәммәдьярның, Сафа Баязидның Тукайга күрсәткән хөрмәте өчен олуг рәхмәте.

Кәбир Бәкерне без әнә шул саран мәгълүмат буенча гына белә килдек. Баксаң, ул язучы гына түгел, ул маҗарапәрәст тә икән. 1912 елда Балкан сугышы башлангач, шәфкать туташларыннан бер команда туплап, үзе аларның җитәкчесе булып, Кәбир Төркиягә китә. Һәм бөтен дөньяга мәшһүр генерал Әнвәр паша белән дуслаша; ике дус бергә сурәткә төшә. Бу фотолар Исмәгыйль Һилал архивында сакланган. Әнвәр паша белән Кәбир Бәкер; икенче рәсемдә Әнвәр паша татар кызлары, шәфкать туташлары: Мәрьям Якупова, Гөлсем Камалова, Рокыя Юнысова, Мәрьям Поташова арасында утыра.

Төрек ягыннан сугышта катнашкан Кәбир, атаклы генерал, басмачылар хәрәкәтенең башында Кызыл гаскәргә каршы көрәшкән Әнвәр паша белән дус булган Кәбир; НЭП чорында Ташкентта асылташлар-алтын кибете тоткан, губернаторныкыннан да биегрәк йорт салган, бай, язучы, мулла баласы Кәбир Бәкер Совет хакимияте вакытында утызынчы-кырыгынчы еллардагы кырылышларда исән кала аламы? Кәбирнең маҗаралары ни белән тәмамлана? «Кәбир кайда, ничек вафат булган» дигән сораулар, эзләнүләр мине Кәбир Бәкернең балалары янына алып килде. Алар Самара шәһәрендә яши икән: 73 яшьлек инженер Тургут ага белән 63 яшьлек доктор Гөлнар ханым хатирәләре нигезендә, Исмәгыйль Һилал вә Бакый Урманче истәлекләре, Кәбирнең авылдашларыннан алган хатларны файдаланып, мин, ниһаять, «Яралы бүре» дип исемләнгән кыйсса — әдәби-документаль әсәр яздым. Әсәрдә Кәбир Бәкер белән очрашкан яки аның язмышына кагылышта булган шәхесләр: Тукай, Муса Биги, Шакир Мөхәммәдьяр, Зәки Вәлиди, Әнвәр паша, Бохара әмире Алимхан, сәяси авантюрист, үзе казыган чокырга үзе төшеп һәлак булган Фәйзулла Хуҗай, Каганович, Ленин, Троцкий кебек мәшһүрләр дә күренеп-күренеп китә.

«Яралы бүре» кыйссасы Кәбир Бәкернең тууыннан алып, үлеменә кадәр булган (1885-1944) 59 еллык араны тасвирлый. Шушы әсәрдән бер өзекне «Мәдәни җомга» укучылары хөкеменә тапшырам. Кыйсса тулысы белән «Идел» журналына тәкъдим ителде.

АХИРИ

● әсәрдән өзек ●

Рабит БАТУЛЛА

ЮЛДАШ

Орынбурдан Самарага кадәр утлы арба-поезд белән баргханнан соң, Кәбир Бәкер «Тургенев» парахутына утырды. Икенче класслы каютада сәяхәт итүче яһүди гаиләсе янына урнашкач, ул тамак ялгап алды. Аннары парахутны әйләнеп чыкты. Кызык иде парахутта. Өстәге катта бер генерал, яшь хатыны илә: кәттә кыяфәтле бай хатыннары; кирәксә-кирәкмәсә дә шалт-шолт үкчә бәргәләүче кадетлар, курсисткалар ялкау гына йөренәләр. Икенче класс катында фәкыйрьлектән дә, байлыктан да ерак торучы, урта хәлле пассажирлар әйләнеп тулгана. Иң кызыгы — өченче класста баручылар. Урынсыз баручылар парахутның койрыгына чыкканнар. Анда дөнья купкан. Җырлаш, көлеш, бию. Кемдер гармун уйный. Парахутның борынында күбрәк татар кешеләре бара. Кемдер сезонлы эштән туган ягына кайтып килә, кемдер бәхет эзли чыккан.

«Тургенев» ашыкмый, пристиннәрдә озаклап йөк бушата, йөк төйи. Кәбир, йөреп аргач, бүлмәсенә кайтты. Яһүдинең җитеп беткән кызы инде изрәп йоклый. Хатыны да ятарга әзерләнә. Гаилә башлыгы, сәгать төзәтүче булса кирәк, Кәбирне көтеп, чишенмичә, өстәл янында утыра иде.

— Әйдә, кенәз, — диде яһүд. — Утыр. Аяк өстендә хакыйкать булмас! Хәзер чәй китерерләр. Мин Виктор Самойлович Брахман буламын!

Кәбирнең күптәннән чәй эчәсе килә иде инде. Самаурырчы чәй өсбапларын куеп, бүлмәдән чыгып киткәч, яһүди янә сүз катты:

— Алыгыз, кенәз! — диде ул, чәй салынган касәне җегеткә сузып. — Шикәрне кабып эчәсезме, әллә...

— Мин шикәрсез эчәм, — диде Кәбир, яһүдигә ул бурычлы булып калырга теләмәде, шикәргә үрелмәде, чәйдән баш тартырга да базмады.

— Сүләгез, — диде яһүд, мишәрчәләтеп. — Кая юл тотасыз?

Алар шулай танышып киттеләр. Яһүд кешесе, чыннан да, сәгать төзәтүче булып чыкты, моның өстенә ул бизәнү әйберләре дә төзәтә, алкалар, беләзекләр дә ясый икән. Кыскасы, көр тормышлы кеше.

— Ни калган сезгә анда? — диде Виктор Самойлович. — Казан бик тә борчулы бүген. Вообще, Русия бик борчулы, куркыныч. Революция — ул ике яклы пәке, мырзам. Бер яктан — яхшы, патша өректе. Ул аз-маз яхшылык эшләгән булыр. Икенче яктан, революциядән соң мәхшәр булачак ведь Русиядә... Казанда губернатор, жандармерия, өченче бүлек тагын да хәтәррәк эшли башлаячак. Син шул мәхшәргә барасың, мырзам.

— Виктор Самойлович, — диде Кәбир. — Революция безгә, татарларга, аеруча кирәк иде. Беренче революция безнең өчен 1773-75 елларда булды. Пугачау явының сиксән өлеше татар-башкорттан тора иде. Бу яу, бу революция безгә мәктәпләр, мәчетләр, аң-белем, китап китерде. Динебезне кайтарды. Монысы да, иншаллаһ, шулай булыр, дибез. Бәс, без — моны аңлаганнар — Казанга җыелырга тиешбез. Бу заман — татар халкының яңа тәрәккыять заманы булачак, Виктор Самойлович. Өч йөз илле ел тыгылып торган буа ачылды инде. Аны туктату мөмкин түгелдер...

Виктор Самойлович аның сүзләрен игътибарсыз тыңлады кебек. Ул фикерен бая әйтеп бетермәгән, ахрысы, Кәбир сөйләп бетергәнне сабыр гына көтә бирде. Һәм аннары нәкъ туктап калган җирдән сүзен дәвам итте:

— И, вообще, мин гаҗәпләнәм, кенәз, ни өчен татар кешесе урыс Казанына тартыла? Нәрсәсе тарта? Кала тулы чиркәү, шәһәр тулы урыслар, яһүдиләр, жандармалар; бөтен власть урыс кулында, судлар, поплар, исправниклар, адвокатлар татарны талый, изә. «Татарларга һәм этләргә керү тыела», дип һәр бакча капкасына язылган. Әнә, Казансу елгасындагы һәйкәлгә «В честь победы над татарами», диеп язылган. Вон есть указ его превосходительства губернатора: Булакның уң ягына йорт салу татарга ярамый... Татар бистәсендә һава бозучы заводлар корылган, яңаларын төзеп яталар. Христиан ягында ник бер төтен торбасы булсын! Татар үз туфрагында хокуксыз, үз ватанында чит-ят кавем, ни өчен соң шул татар әллә кайлардан: Себердән, Кырымнан, Әстерханнан Казанны эзләп килә? «Казан» сүзен ишеткәч, һәр татар җирси башлый, торган җире һәйбәт булса да, Казанда ярым ач килеш, кеше өстендә торасын белсә дә. Нигә дип татар, менә вот сез, кенәз, нигә дип Казанга йөрисез? Орынбурыгызда сез яхшырак торыр идегез, ә?

Кәбир Бәкер яһүд сөйләгәннәрне сабыр һәм җитди тыңлады; хәзер, төгәл җавап бирү зарурыятендә калгач, бераз каушады, юлдашы аның авырткан җиренә каты итеп басты кебек. Ләкин Кәбир аңа кызмады, чөнки яһүд кешесе бу сүзләрне ачу китерерлек итеп әйтмәде; ул, чыннан да, бу сорауга җавап эзли кебек тоелды.

Кәбир җавапка әзерләнде, дөресрәге, ул төгәл җавап бирәсен үзе дә белми, чөнки моңа кадәр берәү дә мондый сорауны биргәне булмады.

— Уважаемый Виктор Самойлович, — диде Кәбир кыюсыз гына. — «Казан» һәр мөселманга, һәр татарга могҗизалы сүз. Ул шәһәр — һәр татарның мәгънәви кыйбласыдыр. Мине бүгенгә урыс каласы түгел, ә ханнар заманындагы Казан, дин мәркәзе булган Казан, сәедләр үзәге саналган Казан, шагыйрьләр каласы, гүзәл хансарайлар шәһәре, бай көтебханәләр, гөлбакчалар, мәктәпләр, Сөембикә манарасы, атаклы ханнарымыз җирләнгән изге зиратлар тарта.

Виктор Самойлович көлемсерәде. Бу көлемсерәүнең мәгънәсе: бүген юк бит ул гөлбакчалар, хансарайлар, ханнар каберлеге, дигән кебегрәк тоелды. Кәбир тавышын күтәрә төште:

— Кайчандыр булган алар, булган, — диде. — Ә Сөембикә манарасы хәзер дә тора. Әнә шул, элек булганнар тарта. Һәр татарның канына сеңгән җирсү, юксыну, сагыну, шуларны кайтарырга өметләнү тарта Казанга!

— Кайтарырга өметләнү? — диде юлдаш.

— Рас! — диде Кәбир. — Кайтарырга өметләнү.

— Менә монысы яхшы, — диде Виктор Самойлович. — Өмет яхшы. Нигезе бармы соң кайтарырга, кенәз?

— Нигезе бар, әфәндем, — диде Кәбир. — Төп нигез — Ислам. Рәсми Исламны татар, кан коеп, Кәтри кулыннан тартып алды. Кәтри патшабикәгә бик кирәкме синең Исламың? Әмма веротерпимость фәрманын Кәтри чыгарды түгелме? Мәҗбүрән! Кәтридән соң йөз утыз ел буена Русиядәге Ислам татар телен саклады.

— Ислам гарәпчә язылган. Нәрсә, әллә татарча Коръән бармы? — диде яһүд.

— Татарча Коръән юк, әмма аңлатмасы бар. Гарәп телендәге Коръән татар-төрек телен саклаган.

— Һым, парадокс, — диде яһүд. — Прямо-таки уникально... Оригинально вы выразились, Кәбир Кәримович.

— Шушы йөз утыз ел безгә Мәүлә Колыйларны, Кандалыйларны, Акмуллаларны, Мәрҗаниләрне, Фәхретдиннәрне, тагын әллә кемнәрне биреп өлгерде.

— Хак, кенәз, хак, — диде юлдаш. — Дин татарны әхлаклы халык буларак саклаган. Татарны дин аракыдан ерак тота. Менә нәрсә сезне саклый, мырзам.

— Исән калган йолаларыбызны, аеклыгыбызны гына түгел, зиһниятебезне, рухи байлык илә матди байлыгыбызны да, Исламны да бу революция коткарыр, шәт!

— Бирсен Ходай! — диде Виктор Самойлович. — Тик карагруһчылар, держимордачылар моңа юл куймас.

Юлдагы сөйләшү Кәбир өчен эзсез калмады, тора-бара бу бәйләнчек яһүд Кәбиргә ошый башлады. Аерылышыр вакыт җиткәч, юлдаш яһүд Кәбиргә кәгазь кисәге сузды:

— Ну, кенәз Кәбир бәй, кирәк чыкса, кил, сәгатең ватылса, йөзегеңнең кашы төшсә, миңа кил, менә сиңа адресым...

Очраклы гына юлдаш булган шушы яһүд кешесе Кәбир Бәкергә бик тә якын, кирәкле булып китте. Ашказарский биргән адресларның берсендә дә эш барып чыкмады. Яңа бистәнең Аккомасты урамында торучы кешеләр, йортларын бикләп, күршеләренә күз-колак булып торырга кушып, Җаек ягына кымызга киткәннәр икән; Бишбалтадагы Габдел Сабир хәзрәт тә хаҗ сәфәрендә булып чыкты. Озак баш ватмастан, ул Виктор Самойловичның өен эзләп китте. Хуҗа аны күптән көткән кебек:

— Һу-у, Кәбир мырза! Уз әйдә, уз! — дип каршы алды.

Һәм шундук, эшне аңлап, мәсьәләне кабыргасы белән чиште дә куйды:

— Танышларың кайтканчы, үзебездә торырсың, кенәз!

Аннан соң ул кемгәдер:

— Гей, кто там? — дип кычкырды.

— Я здесь, хозяин, — дигән тавыш ишетелде.

— Чарлакны әзерлә, кунак бар, — диде хуҗа.

Агач йортның олы ягыннан бер хатын чыгып:

— Ччас! — диде дә текә баскычтан менеп китте.

Кәбир Бәкер чарлакка урнашты.

Дөресен генә әйткәндә, Кәбир Бәкер дөньяга бәхетле кеше булып килгән. Моңа кадәр аның һичбер олы кайгысы, мохтаҗлыгы булмады. Нык-төпле хуҗалыкта үсте, уку аңа җиңел бирелде. Үзе теләгән якка тәртә каерып, сәүдә белән дә, әдәбият белән дә, театр белән дә якынаеп, һәрберсендә дә үз булып китте. Инде менә Казан тикле Казанга килеп төшүгә матур гына торыр урыны да булды. Виктор Самойлович аны үз кардәше кеби кабул күрде. Торак өчен дә, ашау өчен дә акча алырга теләмәде, ләкин Кәбир бурычлы булып кала торганнардан түгел иде, фатир өчен акчаны ул хуҗабикә өстәленә калдырып чыкты... Әйе, Кәбир Бәкер бәхетле иде. Атасы аны кичерер. Шулай урнашып алгач ул, дога кылды:

— Я, Рабби, милләтем өчен, халкым өчен шушы бөек Казанда олуг эшләр майтарырга насыйп әйлә! — диде ул беренче көн йокларга ятар алдыннан.

Сәламәт бәдәнле, чибәр йөзле, чем-кара мыеклы Кәбир Бәкернең алдагы юлы якты, эшләрә бихисап, теләкләре изге иде.

ТУКАЙ

Кәбир Бәкер дә, әдәбият-сәнгать мәйданында шөһрәтле исем яулап, татар халкының иң олуг затлы-галиләре илә табындаш-сердәш булыр дәрәҗәдә үсеп килә иде. Әдипләр аның белән санлаша, сәнгатьчеләр арасында аның сүзе үтә. Барыша,

сы да ал да гөл. Әмма Кәбир Бәкернең гөләмә арасындагы абруен Тукай арттырды.

1907 ел Кәбир Бәкер өчен генә түгел, бөтен Казан өчен, алай гына да түгел, бөтен татар өчен олы вакыйгаларга бай булды. Шуларның берсе — мәшһүр Тукайның Казанга килүе иде. «Тукайның Казанга кайтуы», дисәң дә дөрес булыр. «Казанга килүе», дигәндә дә хата түгел, чөнки Тукай өчен Казан яшьли ук чит-ят булды. Үз баласын, үз шагыйрен урам буйлап, базардан-базарга барып, чит-ят кешеләргә сатып йөргән калага үз итеп кайтып буламы икән? Шул ук вакытта бүгенге Казан Тукайны инде күптән сөя, күптән олылый, күптән көтә. Бөтен Казан халкы Тукайга баштанаяк гашыйк ки, хәтта Тукайның кайтуыннан Казан шүрли дә кебек. Әдипләр, шагыйрь-шогарә, сәнгатьчеләр: безнең хакта Тукай ни әйтер? дип шүрләү катыш ихтирамлылык кылса, надан мулла-мунтагай вә урыс этенең йонын уңайга сыпыручы эшйертерләр аның өче һөҗү-тәнкыйтеннән курка, жандарм идарәсе исә Тукай кайткач, үзенә күп мәшәкатьләр өстәлүенә хәвефләнеп, шагыйрьне теләмичә генә көтә иде.

Өйләнмәгән яшь җегет-шагыйрьнең Казанга кайтуы турындагы хәбәр буй җиткән кызлы өйләрнең тынычлыгын алды. Кызларның күңеле кымырҗый башлады. Кызларыннан битәр, аналарының, яучыларның йокысы качты. Тукайны кунакка алдыру, җөйге йортларына, җәйләүгә алып китү хыяллары белән тулды башлар... Шәһрәтле кешедән көнләшү, аның даны-дәрәҗәсенә кызыгу — ул табигый хәл. Шул көнләшү аркасында мәшһүр кешене сөймәү, аңа бөһтан-яла ягу, аны астан чагу, каралтырга тырышу да — фани дөнья галәмәтләре. Әмма, ни гаҗәп, Тукай бу мәсьәләдә аерым бер шәхес, ахрысы: шагыйрьләр дә аннан көнләшми, аңа нәфрәт хисен сиздерми. Тукай үтә бөектер алар өчен, үзеңнең буең җитәрдәйләрдән генә көнләшәсең бугай бит ул. Шуңа күрә, Тукайның кимчелекләрен кичерәләр, бу сөерлек-кимчелекләрне даһилык галәмәте буларак уздырып җибәрәләр кебек. Хәсетле кешеләр дә Тукайны курку аралаш хөрмәт итәләр.

Шулар арасында Тукайның Казанга килүен иң зарыгып көткән адәм Кәбир Бәкер булгандыр, мөгаен. Ләкин ул Тукайдан шүрли иде. Якын килә алырмы ул бөек шагыйрьгә? Каушап, оятка калмасмы, шырпы холыклы Тукай аңа каты төртелмәсме? Шуңа күрә, Кәбир беренче көннәрне Тукай күзенә чалынмаска булды. Кешеләр белән күрешсен, танышсын, өйләне-тирәсен танып белә башласын. Эш йөртә белүче Кәбир, оештыручы Кәбир, театрчы Кәбир, хәреф җыючы Кәбир, кирәксә, никах укып, мәет өстендә ясин чыгучы Кәбир — бар җирдә. Ләкин әле Кәбир Бәкер үз урынын, үз мәсләген тапмаган. Килеп терәлгән йомыркасын кайда салырга белмичә йөргән тавык кебек, арлы-бирле чабып йөргәндә, Кәбир Бәкернең юлына язмыш Тукайны чыгарып куйды.

«Әльислах» редакциясенә килеп керүгә үк, Кәбирне Вафа каршы алды:

— Фатих әфәнде көтүебез белән редакциядә булырга кушты. Өйләдән соң сәгать икеләрдә фотога-рәткә алынабыз...

— Кемнәр инде ул көтү? — диде Кәбир һәм бер дә исе китмичә генә өстен сала башлады.

— Син, мин, Мөхәммәд Әмин, ягъни Фатих әфәнде дә Тукай!

— Тукай! — дип кычкырганын сизми дә калды Кәбир.

— Габдулла Тукаев белән! — диде Вафа әфәнде.

— Бу харикылыгадә бер эш! — диде Кәбир, куанычын йота алмыйча. — Тукай ризамы?

— Риза! — диде Вафа. — Тукайны алып килү сиңа йөкләтелгән.

Кәбир тотлыгып калды.

— Миңа?.. Нигә миңа? — диде ул һәм бу сорауларның никадәр мәгънәсез икәнен шундук аңлап: — Ярар, мәйлең! — диде.

Кирәгә булмаса да Вафа аңлата башлады:

— Мин бүлмәне әзерлимен. Ибраһим фотография эше белән йөри. Фатих әфәндене җибәрмәбез бит инде йомышка!

Кәбир аны тыңламый иде инде, ул шушы мәлдән үк Тукай белән бергә-бер, йөзгә-йөз очрашу турында кайгырта башлады. Тукайны ул инде берничә тапкыр күргәләде. Шагыйрь редакциягә кергәли, дәшми-тынмый гына гәзитәләр, китаплар караштыргалап утыра да чыгып китә. Ул инде, килеп җитәр-җитмәстән, берничә кеше белән бәхәскә дә кереп өлгергән, бер-ике бөтчәне нумирыннан куган, үзенең мондагы тормышыннан Фатих Әмирханга зарланырга җитешкән иде. Бәс, Тукайны кунакка чакырырга бару да куркынычсыз йомыш түгел. Олылап кунакка чакырырга килгән «прикашшикларга» ул берничә отказ да биреп куйган.

Беркөнне ул, гәзитә йомышлары белән йөреп, редакция бүлмәсенә өйләнеп кайтканда, кечкенә түгәрәк өстәл янында Фатих әфәнде белән аңа таныш булмаган бер шәкерт утыра иде. Шәкерт дигәнебез Тукай булып чыкты. Фатих Әмирхан, Тукайны Кәбиргә тәкъдир иткәннән соң, Кәбир турында:

— Бу — Казак, — диде.

Тукай шунда ук:

— Казакка бер дә охшамаган! Бәлки нугайдыр ул! — димәсенме.

— Юк! — диде Фатих Әмирхан. — Аның кушаматы, имзасы — Казак, чын исеме Кәбир Бәкер.

— Кызык, — диде Тукай. — Ни өчен сез «Казак» имзасы сайладыгыз?

Кәбир кыскача гына үзенең чыгышын аңлатып бирде.

— Безнең борынгы бабаларыбыз Орынбур якларына казак гаскәрләре буларак китереп куелган.

Тукай башта елмаеп тыңлады, соңра җитдиләнде, бераз уйланып утырганнан соң ул:

— Атлы казак, нагайкалы казак, дип күңелгә баткан инде, нишләтәсең, — диде. — Әмма «Казак» имзалы хәбәрләр бик төпле. Язарга кирәк, — дип өстәде дә Кәбир турында кабат сүз булмады.

Шуннан соң ул Тукайны ике тапкыр күрде, сәламләшүдән ары сөйләшүләр булмады. Менә бүген Кәбир үзе Тукай янына барырга тиеш.

Ах-ух килеп, соңга калып йөргәнче, Кәбир кунакханәгә иртәрәк китте. Ишеккә бармак сөяге белән өч тапкыр шакып:

— Рөхсәтме? — диде.

— Ишек ачык! — дигән тавыш ишетелде.

Ул кергәндә Тукай гәзитә караштырып утыра иде. Бер тимер карават, өч урындык, бер өстәл, кечкенә кием шкафы бар, киң тәрәз төбендә китаплар чәчелеп ята.

— Ә-ә, Казак, уз өйдә, уз, утыр! — диде хуҗа, өстәл янындагы урындыкка күрсәтеп.

Кәбир күрсәтелгән урынга утырганда чәчелгән китапларга күз сирпеп алды: анда Пушкин, Гоголь китаплары, татарча мәҗмугалар ята. Гогольнең «Ревизор»ы ачык килеш, күрәсең, Тукай аны укый башлаганмы, укып бетергәнме, китап ялгашында карандаш та бар.

Кәбир йомышын әйтте.

— Алайса: чәй китертәм, — диде шагыйрь. — Әле вакыт бар.

Самаурчы малай чәйне тиз китерде. Сөйләшми генә чәй эчүе кыен. Бүлмәдә ачуланышкан ир кардәшләр утыра диярсең. Шулай да Тукай искәрмәстән:

— Казак, сиңа ничә яшь? — дип әйтеп салды.

— Егерме ике, — диде Кәбир, сүз әйтелгәнгә сөенеп, тагын өстәп куйды: — Мең сигез йөз сиксән бишенче елгы мин...

— Уһу, — диде Тукай. — Син миннән картрак икән, мин сиңа «абзый», «агакеше», диярмен, ату «Казак» исемен әнеп бетермим. Шулай, ага кеше, мин мең сигез йөз дә сиксән алтынчы елгы, миңа егерме бер яшь.

Тукай бу сүзләрне шаяртып әйтәдер, дип, Кәбир шагыйрьнең чыраена бакты, аның йөзе бик тә җитди иде. Кәбир Тукайның күзләрен «тотарга» уйлаган иде, ләкин аның карашын туры китереп булмый, очрашканда да күзләр, үткен караш пычак булып, сине өтеп ала да, шул мизгелдә үк узып та китә. Тукай үзенең күзе каты икәнен белеп, кешегә озак карап тормыймы, әллә ул нидән булса да кыенсынамы, Фатих Әмирхан белән сөйләшкәндә дә ул яны белән утыра иде. Гадәттә, кеше әңгәмәдәшенә үпкәләгән чакта шулай читкә карап сөйләшә.

— Ниләр язасың, агакеше? — диде Тукай.

— Төпле эш майтарган юк, Абдулла әфәнде! — диде Кәбир. — Әле моңарчы хәреф чүпләдем. Өнинең шәлләрен сатып көн күрдем. Хәзер менә рәтләнеп барам. Театрга йөрим, дигәндәй...

— Театр? — диде Тукай. — Театрга йөрү — эш инде ул, абзый кеше, соңра язар булсаң, әлбәттә. — Тукай тәрәзә төбендәге китапларга ымлады. — Әнә, язган бит кешеләр. «Борис Годунов»ын да, «Ревизор»ын да язган. Патшалар үпкәләр, дип тормаганнар.

— «Ревизор» бик тә хәтәр әсәр, — диде Кәбир. — Астыртын пьеса.

Тукай, тустаганын читкәрәк этеп, Кәбиргә беренче тапкыр туры карады. Бу караашта гаҗәпләнү, сорау бар кебек тоелды. Ләкин шагыйрь озак карап тормады, күзен читкә алды.

— Туры пьеса, хәйләсе-мәйләсе юк, — диде шагыйрь, үпкәләгәндәй. — Хәтәр сатира. Маңгайга күсәк. Патша режимын каһкаһәгә алган әче, ачык тәнкыйть. Шунысы белән кыйммәтле дә «Ревизор», шунысы Гогольне каһарман ясый да, абзый. Тискәре образлар җыелмасы. Әсәр шуның белән бөек.

— Шулай язалар, шулай шәрехлиләр, — диде кунак.

— Азагына бак: күсәк белән органнан соң, бар да катып кала, саңаклар асылынган, күзләр акайган...

Тукай, бөтен сәхнәне-күренешне күзаллап булса кирәк, сабыйларча көлә башлады. Усал, төксе Тукай шундук юкка чыкты, каршыда — самими, көләч бала Апуш. Рәхәтләнеп көлгәч, янә Кәбиргә карап:

— Җә, кай төшендә хәйлә бар «Ревизор»ның? — диде.

Тукай бу пьесаны күп тапкыр укыган, күренеп тора. Ул һәр аңлатма сүзне хәтерли. Кәбир әңгәмәдәшен азакка чаклы игътибар белән тыңлады. Тукайның сүзе төкәнде:

— Тагын ясыйммы? — дигәч кенә, Кәбир салмак кына сүз башлады.

— Хәйләсе нәкъ сез әйткән соңгы ремаркада, — диде.

— Ташлале шул «сез-мез»ләреңне! — диде хуҗа, ачулангандай турсаеп. — Әллә каян өйрәнеп алалар да, сез-мез, галиҗанәп...

Кәбир:

— Әллә ничек бит, Абдулла әфәнде, — дип аклана башлаган иде, Тукай аны кырт кисте:

— Фатир Әмирхан кеби олуг шәхеснең ышанычлы каләмдәше икәнсең, син миңа да чит түгел, абзый кеше.

— Алайса, мин сез... сиңа, кем диеп, әйтим, Тукай әфәнде?

— Апуш, диген, Тукай, диген, дустым, агайне, кардәш... беткәнме матур, җанга якын сүзләр татарда?!

Тукай ачуын юып җибәрер өчен чәй йотты. Кәбирнең дә чәйгә тотынмый хәле юк иде. Шулай тын гына чәй эчеп утырганнан соң, Тукай бөтенләй сабыр-салмак кына:

— Һәйдә, абзый, теге хәйлә дигәнең белән тынычлыгымны алдың да... Сөйлә!

Арадагы киеренкелек бетте, чәй барысын да юып алып китте. Кәбир сөйләшүне эзгә төшерер өчен сүз башлады:

— Хәйләсе соңгы ремаркада, — дип кабатлады. — Шул хәйлә Гогольне Себердән коткарган, Габдуллаҗан... «Ревизор» уйналасы көнне Гогольнең дошманнары, спектакль караудан битәр, авторны кара каретага утыртып алып киткәннәрен тамаша кылырга җыела... Пьесаның кульязмасы кулдан-кулга йөреп укыла, жандарм идарәсе пьесада крамола ярылып ятканын күрә, городничийлар үзләрен таный. Ду килә Петербург халкы. Спектакльгә Николай патша да килә. Пьеса бер сулыш белән уйналып бетә, залда дәһшәтле тынлык урнаша. Сәхнәдә ияге асылынып төшкән шәхесләр, залда тораташ калган тамашачы, бу кадәр дә олы күсәкле сатираны карагач кул чабаргамы, әллә чыгып качаргамы, дигәндәй утыручы галерка. Барысы да Николай ложасына карап каткан. Николай да хәйран калган. Жандармнар, Гогольне өстерәп алып чыгып китәргәме, юкмы, дигәндәй, Николайның ишарәсен көтә. Ниһаять, Николай патша ап-ак бармакчалар кигән кулын күтәреп, ике бармагы белән сул уч төбенә өч тапкыр сугып:

— Браво! Браво, Николай Васильевич! — ди.

Шуннан соң «браво»ны галерка, балкон, партер вә ложалар күтәреп ала. Дөнья куптара тамашачы, алкышлый, «брависсимо» кычкыра. Гогольне сөргенгә сөрергә килгәннәр чәчәккә чыгып йөгерә. «Ревизор»ы белән Гоголь җиде кат күккә менеп китә.

Кәбир, тукталып, салкын чәй уртлап куйды. Тукай, ике яңагына таянган хәлдә, уйга калган. Ниһаять, ул тирән уеннан чыгып:

— Могҗиза! — диде. — Кат-кат укып та башыма килмәгән? Үз режимына язылган коточкыч сатираны Николай ничек рөхсәт иткән? Алкышлаган. Ни өчен, агакеше, ә?

Тукай Кәбиргә туры карады. Күзен алмады, тарсынмады, кыенсынмады. Кәбир дә, һич рыясыз, яңа дустына текәлеп торды. Бу карашның нурлары өзелерлек түгел иде, бу караш гомерлеккә дус булырга ант билгесе кебек иде.

— Беләсеңме, Габдуллаҗан, — диде Кәбир. — Хәйлә соңгы ремаркада, дидем... Әле генә Хлестаков, ялган вәкил, кешеләрне алдап, талап, кызларын кочып, качып китте. Яңа хәбәр! Жандарм кереп:
«Приехавший по именному повелению, ягъни патша
исеменнән, из Питербурга чиновник требует вас сей
же час к себе. Он остановился в гостинице», ди... Бу хәбәр бөтен ришвәтчене, әхлаксызларны, городничийны тораташ итә, ягъни Питербургтан чын, гадел вәкил килгән, аны патша үзе җибәргән гаделлек урнаштырырга; бу юлы ришвәт белән генә, кыз биреп кенә җаваптан котылып булмаячак.

Гаделлек кылычы аларны кунакханәдә көтә. Ул кылычны кем җибәргән? Николай патша...

Кәбир янә чәй йотты. Тукайда инде чәй кайгысы юк иде, ул аптыраган, ул уйлана, гаҗәпләнә. Авыз ачып сүз әйтергә кирәк түгеллеген Кәбир яхшы аңлады, Тукайның халәтеннән күренеп тора, хәзер ул нидер әйтәчәк:

— Агакеше, — диде шагыйрь. — Николай патша белән Гоголь генә акыллы, калган бөтенебез дә ахмак-беркатлы булып чыгабыз түгелме соң? — Тукай көлеп куйды да, әйтте: — Ә-ә, өченче акыллы кеше — ул син, абзый! — диде. — Николай патшаны мактаганы өчен Гогольне орден белән бүләкләргә тиеш булганнар бит.

— Себергә җибәрмәү — үзе ун орденлык, Габдуллаҗан, — диде Кәбир.

— Гаҗәп! — диде Тукай. — Син, дустым Кәбир Бәкер, серле кеше булып чыктың бит әле. Төңкәнең икенче ягын әйләндереп күрсәттең. Көзгенең теге ягына чыга беләсең икән син, абзый... Син, һичшиксез, театр турында язарга тиеш!

Китәргә вакыт җиткән иде. Тукай ничек утырган булса, шулай әзерлексез кузгалды.

— Габдуллаҗан, — диде Кәбир. — Без фотосурәткә алынырга барабыз.

— Беләм! — диде Тукай, кара күзлеген кия-кия. — Шуңар әзерләнәм бит... Ә-ә, аңладым, син, Казак, яхшы костюм ки, муеныңа кара чүпрәк так, дип әйтергә телисең инде... Кәчтүнем юк, муенчак белән буылып йөрер хәлем юк, болай да тын бетә. Ничек бар, шулай һәйбәт булыр, абзый. Зинһар, «Әльислах»та да, кием, галстук, дип каныма тоз салмасыннар, син әйт аларга, абзый.

Кәбир белән Тукайның җандустлыгы әнә шушы очрашудан башланды. Кәбир дә шушы көннән соң җигелеп эшләргә алынды, мәшһүр театр белгече, театр язучысына әверелде.

Казанга килеп төшкәч тә, Тукай буталчык мохитта кала. Туганнар юк, дуслар юк, хәтта якын танышлары да булыр-булмас кебек. Казан аңа чит-ят шәһәр икән ләбаса. Кичләрен тәрәзәләрдә утлар балкый, һәркем үзенең җылы, якты өендә якыннары арасында рәхәт чигә. Һәр якты тәрәзә өй эчендәге мөкәммәл, нурлы бәхет сарган гаиләнең күзләре кеби балкый. Тукайда аларның гаме юк. Төмле-кайнар ризык җыялар, рәхәт көлә-көлә чәй эчәләр. Тукай ятим. Тукай бу шәһәр өчен юк. Кем аны дус итәр? Кемне ул дус күрер? Сагынып, җирсеп, эчке куану белән ул Казанга кайтты — ләкин бәхет юк. Иншаллаһ, дуслары да табылыр, тик бәхет кенә булмас, олы бәхет аны читләтеп узар. Ялгызы гына урамнарда максатсыз йөргәндә, Тукай әнә шулай уйлый иде. Аның бәхетсезлеге ятимлектә генә түгел; аның бәхетсезлеге торыр урын, даими кереме булмаганнан да түгел; котылгысыз эч пошуы, тормыштан канәгатьсез булуы мәхәббәт алиһәсе, җан сөйгәне булмаганнан килә иде. Ул, шуңа күрә, үзен кимсенүле хис итә иде. Ләкин ул моны зиһене белән түгел, күңел сиземләве белән генә тойды. Алда мәхәббәт нуры, гыйшык шәме булмаса, ир-җегет өчен моннан да зур бәхетсезлек юк.

Тукайның бу «чир»ен Кәбир бер күрешүдә үк аңлады. Тукай да бу адәмнең башкалардан үзгә холыкта, үзгә фикердә икәнен күрде. Кәбирнең сабыр багышлы күзләре чак кына елмая, көлемсери төшеп, тыныч карый һәм синең уйларыңны укый, эчеңне тикшереп бага кебек. Кәбиргә — егерме ике, Тукайга егерме бер яшь. Яшьтәш җегет яшьтәшен аңламасмы? Тукай эчендә инде күптәннән өлгереп олуг бер дәрт утыра. Шигъри куәт кенә түгел, өлгереп җиткән, үсмерлектән җегетлеккә, ир дөньясына килеп кергән кешеләрдә була торган җенси гайрәт, теләк, хатын-кызга куәтле омтылыш утыра Тукай кальбендә. Мондый чакта кеше, һичкичекмәстән, өйләнергә тиеш яки табигый куәтен бурырлык мәгъшука табарга тиеш. Тукай беркайчан да башлап үзе кызларга сүз катмаячак. Үз халәтен ул хатын-кызларга түгел, дус-ишләренә дә әйтмәячәк, ачылмаячак.

Шулай да, Казан Тукай өчен тора-бара ачыла төште, якынайды: ул Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Сәгыйт Рәми кебек олуг дуслар тапты. Болар Тукайның кем икәнен аңлап, кем булачагын алдан сизеп, мәңге хыянәт итмәстән, Тукайга аркадаш, терәк булыр. Әмма Тукай шәхси вә интим мәсьәләләрдә бу бөек дуслары белән һичкайчан да әңгәмә кормаячагын белә иде. Галиәсгар Камал гаилә башлыгы — олы кеше; Фатих Әмирхан үтә нәзакатьле тәкәллеф иясе; Сәгыйт Рәми исә — эстет шагыйрь. Алар белән әдәбият-сәнгатьтән башка нәрсәләр турында сөйләшүе гайре табигый кебек.

Тукайны өйләндерү эше, нинди-дер бер татар җегете Габдулланы хатынлы, өйле итү генә түгел, Казан зыялыларының гына мөһим мәсьәләсе түгел, хәтта бөтен татар халкының да әһәмиятле бер фәгалиятенә әверелде кебек. Бу эшкә иң беренче булып маһир Фатих Әмирхан тотынды. Анасы Рабигага кушып та, танышлары аша да шагыйрьгә көләш эзләү эшен кузгатып җибәрде. Чыннан да, Фатих бәй Тукайны өйле, гаиләле итүне бөтен халык өчен кирәкле шөй икәнен бик яхшы аңлый иде.

Иң атаклы шагыйрьне оялы, җәмәгатьле итә алмаган халык нинди халык инде ул? Халык өчен бу эшне Фатих Әмирхан башкарачак, бу аның Тукай каршындагы һәм, ниһаять, халык каршындагы изге бурычы иде. Ләкин Фатих корган тәдбирләр Тукай холкына бәрелеп, челпәрәмә килә тордылар. Фатихтан башкалар да яучылык, димчелеккә алынып карады; алар да бу эшне майтарып чыга алмады; Тукай риза булып та, очрашуга килеп терәлгәч, качып китә яки теше-тырнагы белән баш тарта килде...

А
Х
И
Р
И

КОЯШЛЫ КӨННӘРНЕ КҮҢЕЛЕҢӘ КҮБРӘК ҖЫЙ!

Сүз һәм гамәл

...Борынгылар ук, адәм баласы олыга-кечегә бүленми: җаннар бер яшьтә, дип санаганнар. Шунысы гаҗәп: «балалар өчен» дип мөһер сугылмаган китапларга да, четерекле тормыш мәсьәләләре хәл ителеп, күңел драмалары уйналып яткан бер мәлдә, каяндыр бала йөгереп керә. Хәтта ерак дәверләр катламын күтәрүче романнарда, ташкүмер эчендә оеп калган урман шавы кебек, балачак тәҗрибәсе яши. Ул — безне туган җир, туган тел белән бәйләп торучы кендек бавы. Ул — кайнар туфракның ярмаланып кыштырдавын, дымсу каз үләненең кетер-кетер үсүен ялан тәпиләрең белән тою шикелле үк, йөрәкне кысып ала торган рәхәт бер тойгы. Сабый һәм үсмер бала күңелен рухи тәҗрибә белән баета торган китаплар әнә шул җирлектә туа.

Һәммәбезгә мәгълүм бу хакыйкать. Әмма ул, сүз белән гамәл берлеге сыналганда, хикмәти хода, күпләргә аңлашылмас була: күзләр томанлана, зиһен томалана, күрәсең.

Ә бит, Эстон илендә яисә Казахстанда фәлән санда нәшрият бар, мөстәкыйль (ул заманда — союзный) булсак, без дә шул бәхеткә тиенер идек, дип хыялланган чаклар әле күптәнме.

Татар баласы өчен дәреслек чыгару изге эш, мөһим бурыч дип, шул максатта яңа нәшрият ачканда туган каршылыклы уй-кичерешләр дә әле суынмаган. Бер караганда, бүрекләрне күккә чөеп куанырлык вакыйга: халкыбызга карата тарихи гаделлекнең торгызылуы. (Мәгърифәтле халыкның беренче китабы дәреслек булган, беренче матбагасы сабак китабы бастырган. Бу — безнең гасыр башында кабынып сүнгән «Мәгариф» нәшрияты рухи варисларының фәлсәфәсе). Икенче яктан — бу заманда, буш урында нәшрият кадәр нәшрият торгызу... (Әле үз җилкәсенә, дәреслек кебек, ифрат четерекле эшне, авыр йөкне аласы нәшрият бит! — Ачы тәҗрибә авазы бусы).

«Мәгариф» нәшриятын төзү турында дүрт ел элек хөкүмәт кабул иткән карарның, һәрхәлдә, бер пункты булса да үтәлде: бөтен байлыгы — үз эшенә бирелгән хезмәткәрләре булган нәшрият, Аллага шөкер, тулы куәтенә эшләп китте. Юк, көн яктысында гади күзгә йолдызлар күренмәгән төсле, өч йөзгә якын исемдә, 6-7 миллион булып басылган китапларыбыз, халкыбыз шикелле үк, исәпкә алынса да, санга сугылмыйдыр. «Мәгариф» нәшрияты тулы куәтенә эшли дип әйтергә нигез биргән нәрсә шул: дәреслек дип бүген башкаларның башы авыртмый, ә читтән карап торган беркатлы агайлар, боларга акчаны өеп бирәләрдер инде дип, чын күңелдән ышаналар бугай...

Заман билгесе: дәрес китабына табындагы артык кашык итеп карачы «зыялыбыз», башкалартык кашык итеп караучы «зыялыбыз», башкалардан да уздырып: «Милләт язмышы — мәктәптә!» — дип лаф орыр. Ә бит, ни ач дәвердә дә, Коръән өстенә басып ипи кыерчыгына үрелү вәхшилек һәм гөнаһ гамәл саналган. Коръән белән Әлифба исә һәрчак янәшә торган һәм... бер үк учакта янган.

Әлифба — халыкның фал китабы. Милләтнең киләчәге аның балалары укый торган дәреслектә «программага салынган». Дәрес китабы аша яшь күңелгә халык әдәбенең, әдип сүзенең чык тамчысыдай саф, шифалы гәүдәләнеше сеңеп кала. Шул ук вакытта без балаларга (бигрәк тә сабыйларга) атап чыгарыла торган һәр басманы, дәреслек дәрәҗәсендә үк, олы вазифалы дип саныйбыз. Нәшриятыбызда мәктәп дәреслеге белән балалар китабы кулга-кул тотынышып барганлыктан, безгә бу юнәлеш якынрак та, җаваплырак та булып тоела. «Сезнең «Мәгариф»тә китап чыгару зур мәртәбә булачак әле», — дигән иде бер әдип. Бу — безнең укучыларыбыз даирәсен күздә тотып әйтелгән сүзләр. Аның хаклыгына без мәктәпләрдә булганда, укытучылар һәм балалар белән очрашкан саен ныграк ышана барабыз. Китапларыбыз аша без һәр укучыга — олысына һәм кечесенә, — шагыйрь сүзләренә кушылып: «Кояшлы көннәрне күңелеңә күбрәк җый!» — дип эндәшәбез.

Мөдәррис ВӘЛИЕВ,
«Мәгариф» милли нәшрияты директоры.

Татарстанның, СССРның халык артисты, режиссер Марсель СӘЛИМҖАНОВ:

Мондый газета безнең халкыбызга күптән кирәк иде. Бу газета әдәбият һәм сәнгать эшләренә олы ярдәм итәр дип уйлыйм. Зур уңышлар сиңа, «Мәдәни җомга»! Чын сәнгать булсын

Татарстанның халык язучысы Гомәр БӘШИРОВ:

Ак юл сиңа, «Мәдәни җомга»! Иң изге теләгебез шул: тормышыбызның мәдәни дөньясына алдан юл ярып, әйдәп баручы булсаң иде.

Гомәр Бәширов

Игътибар: «Мәдәни җомга»га беренче хат

Ышанам-ышанмыйм

Нәрсәгә кирәк иде болар миңа, ә? Болай да авыртудан чыкмаган башны тагын нинди уй белән тутырмакчы булам инде? Мондый буталчыкның очына җитәрлекмени...

Эш менә нәрсәдә? «Советская Россия» газетасы күптән түгел Дәүләт Думасы депутатларының Россия хөкүмәтенә ышанмавы җәһәтеннән исемләп тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгарды. «Башкалар юри уйныйлар, мин, юләр, чынлап уйныйм», — дип шагыйрь Равил Фәйзуллин әйткәндәй, Думаның шушы уенын чын кебек өйрәнеп утырам бит, әй. Менә, депутатларның «Яблоко» фракциясендә хөкүмәткә тагын бер ышанып карыйк дип әйтүче бөтенләй юк икән, барысы да диярлек аны урыныннан алып ыргытмакчы була. Коммунистлар, демократлар, хатын-кызлар һәм Жириновский егетләре дә, бөтенесе бер авыздан, хөкүмәткә тамчы да ышанмыйбыз, дип торалар. Карасана, берләшеп, бер фикергә килеп беткәннәр бит болар, бертуганнар диярсең. Хөкүмәт ягында гайдарчылар да шахрайчылар, аннан килеп, ничек тавыш бирергә белми аптыраган россиячеләр һәм ниндидер «тотрыклылар» гына калып бара ич. Болай булгач, бетте хөкүмәт. Хуш инде, хуш, сөешеп тормадык, күз яшьсез генә аерылышабыз, бигайбә!

Туктале, бу Дума дигәннәрендә безнең депутатлар да бар иде түгелме? Алар көймәне кайсы якка тарта икән? Тартамы, этәме? Уңайгамы, кирегәме? Чынлап уйныймы, әллә юриме? Менә «Алма»лылар арасында И.Грачев фамилиясе бар. Таныйм-таныйм, безнең Иван Дмитриевич инде бу. Газета битендә генә булса да очрашу сөенеченнән җырлап җибәрәсе килә: «Иванами да Марьями гордилась ты всегда». «Ты» дигәне Россия буладыр инде, Татарстан түгелдер. Хәер, горурлыкларыбыз уртак та инде. Мәшһүр шагыйребезгә ияреп, саф татар теле белән, «Россиян мин — нинди горурлык!» дип аз сөйләдекме әллә! Яки менә: «Татарстан — минем республикам, Россиянең матур җирендә». Кызык, Татарстанның матур җирендә нәрсә яисә кем икән? «Ива-а-на-ми-и...»

Бәт-тәч, Иван Грачев та Россия хөкүмәтенә ышанмый икән. Депутат булсам, мин дә хөкүмәткә ышанмас идем. Сайлаучы башың белән, ышандың ни дә ышанмадың ни — безнең фикер беркемгә кирәкми. Шуңа күрә, кәпәч астында фикер дигән нәрсә тотмыйбыз да инде, башны рәхәтләнеп буш йөртәбез. Горур һәм югары!

Ярар, депутатларыбызны барлый идем ич мин, алар гына югала күрмәсен. Гайдарчылар арасында В.В.Михайлов дигәне бар. Валентин Вахтангович, сезме бу? Ни хәлләрдә яшәп ятасыз? Үзгәреш-фәлән юктыр, элеккечә, Россия хөкүмәтенә ышанам дип тавыш биргәнсең. Ие шул, үз хөкүмәтеңә ничек ышанмыйсың ди инде. Килешмәгәнне! Татарстанныкына гына бик исегез китми инде. Карале, Думаның болай «көҗәләнүеннән» ни үзгәрер дә, аның «тавышы» белән кем исәпләшер икән соң? Исәпләшерләр, безнең Россиядә демократия, дисезләр инде. Ельцин әфәнде әйтмешли, так сказать. Демократиядән «так сказать» кына калып бара шу-ул!

Бу Думага Татарстан җиреннән ничә депутат сайланган иде соң әле? Бишәү? Сигез? Әйтәм ич, минем баш аларны исәпләп чыгарырлык түгел. Ачуым да килмәгәе, компьютермы әллә мин? Йә бер тылсым иясеме? Сайлаганда — бер тапкыр да күрмә, сайлап җибәргәч — күрмә, җитмәсә, күзгә күренми торган фәрештәдәй шул депутатыңны исеңдә тот, күз алдыңда йөрт. Алай булмый бит ул. Безнеке, Балтач халкы сайлаганы, Баһаутдинов фамилияле идеме әле? Галәветдиновмы әллә? Татар фамилиясе иде бит инде! Әллә ялгышаммы? Мин сайлауга бардыммы, юкмы? Безне анда чакырдыларммы, чакырмадылармы? Әһә, искә төшә башлады: башта — чакырмадылар, аннары...

Менә-менә, бер җеп очын эләктергәч, хәтергә килә әзерәк, безнең кечкенә генә Балтач районын әллә кайдагы зур-зур Түбән Кама белән бер округка кушканнар иде. Димәк, депутатны алар сайлагандыр. Ә без, так сказать... Менә шуңа, күрми дә калганбыздыр. Белмәссең тагын, бәлки алар депутатны Балтачлар сайлады дип йөриләрдер, ә теге, фамилиясе билгесез кандидат, Думага ике район арасындагы буш урыннан барып утыргандыр. «Ике урман арасы, болын буйлап барасы», — дип җырлыйбыз ич. Шуңа күрә, без депутатны белмибез, депутат безне белми. Вәссәлам. «Аерым үтте еллар, аймыл булды юллар...»

Җырласаң, җырлар күп инде анысы, депутатларыбыз саныннан ким түгел. Эх, егетләр, өч кенә көн булса да, Дума депутаты булып утырсаң иде ул. Сине кем сайлаганны гына түгел, ата-анаңны, үз исемеңне дә онытып һәм онытылып, башың-аягың белән дәүләт эшләренә чумасың! Парламент уеннарына, дисәң дә ярый. Бүген хөкүмәткә ышанмыйм дип ыгы-зыгы кубарасың, иртән торгач, ышанам дип тавыш бирәсең. Көмитнең галәмәт зур булганын яратабыз ич без. Өч көнгә депутат мандаты эләктерсәм, аны дүртенче көндә генә түгел, дүрт ел буена да ычкындырмау әмәлен табар идем анысы. Эх, үзең ярлы булсаң да, акчаң күп булсын иде шул. Акчасыз гына депутат булулары — ай-һай!..

Акча дигәннән, сайлауларны бик чыгымлы эш дип сөйлиләр, кая китә дә, кемгә эләгә икән ул «чыгым»? Мин үзем, кырык ел инде, бер сайлауны калдырмыйм, унөч ел буе авылда иң беренче булып тавыш бирдем, бер бюллетенне дә бозмадым, әмма аның өчен бер тиен түләгәннәре юк. Акча үземнән чыга әле, буласы депутатлар хөрмәтенә, алар җиңүенә куанып, шундагы буфеттан теге ни,.. Кырык ел сайлауга күпме җыела бит ул, ничек алкашка әйләнмәдем микән мин?.. Әллә әйләнеп баруым шушымы? Андый чакта үзең сизми дә каласың, ди бит. Менә ел ярым элек кенә тырышып сайлаган депутатымны да хәтерли алмадым, тикмәгә түгел инде бу. Ул да мине исенә кертеп тә карамый. Бәлки безгә, үз сайлаучыларына, ышанмау белдереп, әллә кайчан тавыш биргәннәрдер инде алар. Шулай булмаса, бер күренеп, «Бик йөдәмәдегезме, безне тагын бер тапкыр сайларлык хәлегез бармы?» дип сорашып, киңәшләрен биреп китәрләр иде. Безнең дә бит кайчан кемгә ышанырга белмичә башлар каткан, аны әйтеп бирерлек тавышыбыз гына юк.

Рафикъ ШӘРӘФИЕВ.
Балтач.

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Шигъри шифа

*Сихри дәва — шигырь...
Шигъри һава...
Шифалы бал,
шифалы су,
шифалы Сүз...
Учыгызны касә итеп тотыгыз да,
йотылып-йотылып,
шигырь эчегез...
Сафланыр җан.
Явыз чирдән
пакьләнер кан...
Рәхим итегез Шигъри сеанска!
Шигъри шанс,
сихри сенсация!.. —
«Аккош үлемен» йолып алам
Сен-Санстан...
Ашыгыгыз Шигъри сеанска!!
Без бик мохтаҗ бүген
Ышанычка!
Ышанычлы көчле Сүзгә —
сихри көчкә
Шигъри шифа, шигъри дәва...
Шигъри һава...
Ява, ява, ява —
шигъри сүзләр...
Дәва, дәва, дәва —
сафланыплар китсен әле
һава, һава, һава...
Akva-vita, viva-vita -
viva!..
Латин сүзләренә сеңгән шифа...
Шигъри vita —
сихри витамин...
Тереклек һәм Яшәү —
vit-A-min!..*

1992.

Безгә бер хәбәр кирәк...

*Безгә бер Хәбәр кирәк:
Йолдызлар аръягыннанмы,
каяндыр шунда — Айданмы, —
өр-яңа хәбәр кирәк...
«Җир шары — безгә терәк, дип,
безгә сез бик тә кирәк, дип,
Исәптә һәрбер йөрәк», дип —
Өр-яңа Хәбәр кирәк...*

*Юкса — яшәүнең мәгънәсе,
юкса — Ышаныч сәхнәсе
бушаган саен бушый.
Хәтта ки җанны тетрәткән,
соң сулыш булып күкрәктән
атылган бөек эшләр дә
кысыр хәсрәткә охшый...*

*Безгә бер Хәбәр кирәк:
Ыгы-зыгы килмәгез, дип,
Харап була күрмәгез, дип,
Тере килеш, күрә торып,
Җәһәннәмгә кермәгез, дип —
Кискен бер Хәбәр кирәк!*

*Әллә ничәнче катлардан,
бездән акыллы затлардан,
Суыкта — тирләтә торган,
эсседә — туңдыра торган,
Могҗиза тудыра торган
гаҗәп зур Хәбәр кирәк...*

*Үлемнең үзен җиңәрлек,
фантастик хәлгә тиңләрлек,
күзәнәк-канга сеңәрлек
яңа бер Хәбәр кирәк!*

*Таң калырлык, шаккатырлык,
чи дарыны шартлатырлык,
багананы уйлатырлык,
тирән мәрттән уятырлык,
сүнгәнне дә тергезерлек,
үлгәнне дә торгызырлык —
Бөек бер Хәбәр кирәк...*

*Яшәеш тизлеге аша,
Мәңгелек күзлеге аша
Күрергә өнди торган,
Кешене — иң бөек көчкә,
Яшәүне — иң бөек эшкә
инанып тиңли торган,
Тик Мәңгелектәдер — мәгънә,
үлемгә — мең дә бер ләгънәт! —
дип Җирне иңли торган —
чып-чын зур Хәбәр кирәк!..*

*Җир сусаган Яңалыкка,
юкса — күңелсез халыкка,
алҗыган халык, ялыккан —
аңа зур Хәбәр кирәк...
Кузгалырлык, көч алырлык,
өр-яңадан ышанырлык,
Изге бер Хәбәр кирәк! —
Юкса шартлый бит йөрәк...*

1995.

Шагыйрь үлми

*Таң алдыннан йолдыз атылды...
Шигъри төнгә нокта куелды.
... Иркенәеп калдыгызмы? —
Җирдә
бер шагыйрьлек бушлык уелды...*

*— Трамвайда, юлда, чиратта...
«Җәннәт ишеге» ачыла шыгырдап.
Шагыйрьләрнең гомер озынлыгын
еллап түгел — сана шигырьләп...
... Ә Вакытның аның үз үлчәве,
акыл да чүп аңа, хәйлә дә.
Җир түгел ул — Кояш тирәсендә
бөреле-сугыла Шагыйрь әйләнә.
Көнчыгыштан аккан көннәр-төннәр...
Айдан егылып төшкән мизгелләр...
Көзгеләргә карап сискәнерлек
бик аз җирдә җаны сизгерләр.
Ә Шагыйрьнең әле бер төне бар
түгелә-түгелә шигырь язасы.
Төнге сүзләр белән тулган авыз —
кемнәргәдер чәйнәү әгъзасы...
Үтсә үтә вакыт, әмма бетми,
дулкын мәңге тынмый, чайкала.
Җирдә яшәп киткән шагыйрьләргә
шаһит булып күктә Ай кала;
Дәшми-тынмый һәм күзен дә йоммый,
һәрбер шигырь юлын күзәтә...
Шагыйрь китабыннан көлә-көлә,
малтабарлар башын төзәтә...
...Бирәүләргә бәхет — затлы күлмәк,
Җайлы башмак, күндәм матур кыз.
Газраилнең бәхете — шагыйрьләргә*

*капкын кору, куеп матур кош...
«Шагыйрь үлгән, — дигән хәбәр китә, —
ялгыз куышында бикләнеп...»
Юк, бикләнми шагыйрь,
ачыла гына,
ятагында ятмый бөкләнеп...
Айга асылынып үлүләрне
көтмә бездән, шомлы Газраил!
Шагыйрь үлсә, бераз һәркем үлә, —
аңлый микән шуны азрак Ил?!.
Юк, үлми дә Шагыйрь, яши һаман,
кала җирдә, булып матур төш...
... Суынып бетмәс борын
тук авыздан
суырып чыгарылган алтын теш,
«Ник мин Шагыйрь теше түгел!» — ди дә,
сүгенә-сүгенә китә базарга...
Исән шагыйрь исә,
яшәп калыйм
үлгәнче, дип, утыра язарга...*

1994-95.

Рудольф Нуриев белән хушлашу

*Татарлардан — хушлашырга
син бармадың...
Мин бармадым.
Барып җитеп буламыни?!.
И, татарлык...
Иллә, гарьлек...
И, фәкыйрьлек, иллә тарлык...
Кыен, читен...
Кабер чите...
Нәзек билле, нәзакәтле
балерина
өч бармагын
нәфис кенә маңгаена,
иңнәренә тидереп алды...
һәм гүренә мөселманның
чукынылган
чәчәк салды...*

*Үрелеп-үрелеп карап калды
ничә мәчет манарасы...
Тагын китте
без татарның
бер баласы,
ир баласы,
сер баласы...
Китеп барды
түрдән — гүргә
Нур баласы, чор баласы...
Ясин укып калды микән
безнең мәчет манарасы?
Парижларга, Лондоннарга
әле тагын кем барасы?..
Ил җылысын тоялмыйча,
үз йөрәген тыялмыйча,
дөньясына сыялмыйча,
очып китте тагын Җирдән
бу татарның бер Баласы...*

1993.

Үтте...

*Җиләк чаклар, җилкән чаклар
очты-китте җил булып.
Йөри идем «бер кыз» булып,
Җилдән нечкә бил булып.*

*Күлмәгемнең чәчкәләре
үсә иде болында...
Гөлләр түгел, чәнечкеле
теләр инде юлымда.*

*Беркем дәшмәс «җаным», диеп,
Инде мин «ханым» гына.
Кан да чыгар, дан да чыгар,
чыкмасын җаның гына...*

*Җилдә — яфрак, җирдә — яфрак,
коелам да, коелам.
Кара көздә — кара болыт,
кар булырга җыенам.*

*Ап-ак җилкән — җиләк чиккән,
кайсыгыз бар күргәне?
Карлы кырга җыр чәчәсем
төшемә дә кермәде.*

*Мин бер кыз идем җиһанда,
Иркә колындай идем.
Бер ягымда минем — Кояш,
бер ягымда — Ай иде...*

*Яшел ташлы йөзегемне
тапмасымны белсәм дә,
Җиргә ятып еласам да,
җилгә басып көлсәм дә, —*

*Килми һаман ышанасым
кар булып явасыма...
Иске җырлар истә калсын,
түл җыям яңасына.*

*Мин йолдыз булып бу җиргә
күктән атылган идем...
Бер битемдә минем — кояш,
бер битемдә — ай иде...*

1990.

Кичерегез!

*Бер тилереп ала йөрәк —
Гүя, һаман егермедә...
Кичерегез, дип әйтергә
Калдым Сезгә өлгерми дә.*

*Кичерегез шаяртуны,
«Төнге күбәләклегемне».
Ялгыш кына очып кереп,
Әллә үпкәләттем инде...*

*Утыгызга омтылуым —
Гөнаһсыз бер шуклык кына.
Гыйшык уты — ул тиз сүнә,
Гыйшык угы — ул тиз сына...*

*Яшен белән ук тизлеге —
Гыйшык өчен ул да озак...
Минем алда — Сез гаепсез,
Сезнең алда — минем йөз ак!*

*Мәхәббәтем минем биктә,
Ача алмый юлаучылар.
Ялгышалар — бик тиз моны
Ачармын, дип уйлаучылар.*

*Гашыйк булып уйный гына —
Мәхәббәтен саклый йөрәк!
Мин — Сандугач ирекгәге,
Ә Сез — сандугачсыз тирәк...*

1995, июнь.

Александр ФАДЕЕВТАН

Шаулашты да, пышылдашты да ул көнне Мәскәү кешеләре:

— Фадеев үлгән!..

— Атылып үлгән...

— Хаты бар икән. Тик ул югалган икән...

Шулай, Александр Александровичның үзенә кул салуы турында матбугатта хәбәр ителсә дә, аның хаты җәмәгатьчелектән яшерелде. Моннан, димәк, Фадеев олыдан кубып турыдан бәргән, ил җитәкчеләрен дер селкеткән, дип фараз итәргә нигез бар иде. Шуны раслап, ул көннәрдә Мәскәүдә мондый хәбәр таралып алды: имеш, олы бер язучы ил башында торучыларның берсеннән Александр Фадеевның үлеме сәбәбен белешкән икән. Тегесенең җавабы кыска булган, ул безнең барыбызның да кесәсенә көкәй итте, дигән. Бу кадәресе хактырмы, юкмы — хәер, халыкта йөргән сүз гадәттә дөреслеккә туры килә — әмма хатның эчтәлеге, кырык ел чамасы узып, аның белән танышкач, залимлеккә һәм башка әшәкелекләргә протест булуын анык аңлыйсың.

Ул вакытта үзенә кул салучы олы шәхесләрне зурлап җирләү тыелган иде. Ә Александр Фадеевка мөнәсәбәттә партия җитәкчеләре тәртипне үзгәртергә мәҗбүр булдылар. Мәскәүлеләр һәм бөтен ил халкы Александр Александровичны соңгы юлга хөрмәтләп озатты. (Мин бу көннәрдә Мәскәү җирендә идем). Чөнки Александр Фадеев җәмгыятьтә әдәбиятның урынын һәм бурычын тирәнтен аңлаган, халык мәнфәгатен кайгырткан Язучы иде. Моны аның түбәндәге сүзләре кире кагылмаслык итеп раслый: «Әйе, без — халыкка һәм дәүләткә үз каләмнәрен һичшиксез үзебез теләп һәм аңлы рәвештә биргән язучылар, һәм безнең совет халкы һәм дәүләте интересларыннан бүтән интересларыбыз юк».

А.Фадеев бөтен иҗат тормышын хәзерге һәм килер буыннар өчен үрнәк булырлык герой образы тудыруга багышлады, озак еллар буена СССР Язучылар берлегенең җитәкчесе буларак, ил халыклары әдәбиятларын үстерү өчен күп көчен куйды. Шул исәптән, ул татар әдәбияты белән дә якыннан кызыксынды, безнең әдәбиятның торышы, үсеше хакында язучылар җыелыш-җыеннарында сөйләде.

Александр Фадеевның үлеме алдыннан язган хаты, «югалтылган» хаты, ниһаять, табылды. Һәм менә аның, язучының стилен — язу рәвешен сакларга тырышып, татарчага тәрҗемәсе:

Мәгъсум ХУҖИН.

ҮТКӘННӘН КИЛГӘН ХАТЛАР

Алга таба яшәү мөмкинлеген күрмим, чөнки мин тормышымны биргән сәнгать партиянең чамадан тыш үзенә ышанган томана җитәкчелеге тарафыннан харап ителде, һәм хәзер аны ипләү мөмкин түгел. Әдәбиятның әйбәт кадрлары — алар арасында яхшылыклары белән патша залимнәренең төшләренә дә кермәгәннәре бар — физик юк ителделәр яки власть ияләренең җинаятьчел узынуы аркасында һәлак булдылар; әдәбиятның әйбәт кешеләре яше җитмәстән үлделәр; чын хәзинә иҗат итәргә азмы-күпме сәләтле барлык калганнары 40-50 яшенә дә җитмичә вафат булдылар.

Әдәбият — иң мөкатдәс нәрсә — бюрократларга һәм халыкның иң артта калган адәмнәренә ботарлауга бирелде, — Мәскәү конференциясе яки XX партсъезд кебек иң «югары» трибуналардан «Ату ее!» дигән яңа лозунг яңгырады. Хәлне «төзәтергә» дип сайланган юл ачуны чыгара: шундый ук әзәрлекләүләрдән җәфа чигүче һәм шуңа күрә дөреслекне әйтә алмаучы аз санлы, намуслы кешеләрне исәпләмәгәндә, наданнар төркеме җыелды, — һәм нәтиҗәләре бик тә антиленинчыл, чөнки бу нәтиҗәләр бюрократик гадәтләрдән килеп чыга, шул ук «чукмар» белән куркытуга нигезләнә.

Минем буын Ленин вакытында әдәбиятка азатлыкның һәм дөнья хөрлегенең олы хисе белән килеп керде, йөрәктәге көчләр иксез-чиксез иде, һәм без гүзәл әсәрләр иҗат иттек һәм тагын да иҗат итә ала идек!

Ленин үлеменнән соң, безне малайлар хәленә төшерделәр, юк иттеләр, идеологик куркыттылар һәм шуны «партиялелек» дип атадылар. Һәм хәзер, барысын да төзәтергә мөмкин чакта, төзәтергә-ипләргә тиешле кешеләрнең, чамадан тыш үзләренә ышанганлыкның ачу куптаргыч микъдары янәшәсендә, түбәнлеге, томаналыгы ачыкланды. Әдәбият талантсыз, вак, кара эчле кешеләр кулына бирелде. Йөрәгендә изге утны саклаган аерым кешеләр тибәрелгәннәр-хокуксызлар хәлендә калды һәм — олыгаеп — тиздән үлеп бетәчәкләр. Һәм иҗат итәргә күңелдә бернинди стимул юк инде...

Коммунизм хакына зур иҗат өчен туган, уналты яшемнән партия, эшчеләр һәм крестьяннар белән бәйле, Аллаһ биргән зур талантлы кеше буларак, мин халыкның коммунизмның гүзәл идеаллары белән берләшкән тормышны тудырырга сәләтле иң югары фикерләргә һәм хисләргә бай.

Ләкин мине йөк ташучы олаучыга әйләндерделәр, мин бөтен гомерем буе сәләт таләп итмәүче, акланмаган, һәркем башкара алырлык исәпсез бюрократик эшләр йөге астында сөйрәлдем. Һәм хәтта хәзер, үз тормышыма йомгак ясаганда, җикеренүләрнең, шелтәләүләрнең, акыл өйрәтүләрнең һәм гап-гади идеологик кимчелекләрнең барысын да искә төшерүгә түзеп булмый. Андый хәлләр миңа — безнең искиткеч халкыбыз минем чын һәм рухи тыйнак, тирән коммунистик талантым белән хаклы рәвештә горурланырга тиешле кеше өстенә ишелеп яуды. Әдәбият — яңа стройның югарыдагы җимеше — түбәнсетелде, агуланды, туздырылды. Бөек Ленин тәгълиматы тирәсендә кайнашучы сәләмә җаннарның кәпрәюе, хәтта алар бу тәгълимат белән ант иткән чакта да, минем тарафтан үзләренә ышанмауга китерде. Чөнки алардан залим Сталин кылганнан да хәтәррәк-яманрак гамәлләрне көтәргә мөмкин. Сталин хәт белемле иде, ә болар — томаналар.

Язучы буларак, минем тормышым һәртөрле мәгънәсен югалта. Һәм мин бик тә зур шатлык белән, әшәкелек, ялган һәм яла ягу өстенә ишелеп торучы бу кабахәт рәвештә яшәештән котылу буларак, бу тормыштан китәм. Шушыны дәүләт белән идарә итүче кешеләргә хәт әйтергә соңгы өметем бар иде, ләкин инде 3 ел дәвамында, минем үтенечләремә карамастан, мине хәтта кабул да итә алмыйлар.

Мине әнием янәшәсендә күмүегезне сорыйм.

А.ФАДЕЕВ.
13.Ү.56.

Латыйф ҖӘЛӘЙДӘН

Әлеге хатны безгә өлкән журналист Нур Хәмиди алып килде. Аның әйтүенчә, мәшһүр тел галиме Латыйф Җәләйнең бу соңгы хаты озак еллар буена Нур аганың архивында сакланган. Гарәп хәрефләре белән язылган әлеге мәктүб 1966 елның 11 маенда Татарстан китап нәшриятының шул чактагы директоры Салих Вәлиди исеменә юлланган. Нур ага үзе болай дип искә ала: «Нәшриятта эшләп, тираж комиссиясе утырышларында катнашкан көннәрем. Хатны алгач, һич тә сузмыйча, үзебезнең китап кибетләре белән элемтәгә кердем, хатны баш редакторга да күрсәтеп, Вәлидинең үзенә бирдем. Вәлиди исә, карап танышкач, хатны янә миңа кайтарды һәм әйтте: «Син моны сакла...» — диде».

Әйе, хат, чыннан да, сакланган һәм ул менә безнең газетада беренче тапкыр басыла. Латыйф Җәләйнең бу гыйбрәтле хаты аңлаган кешегә үткән көннәрнең хәл-халәтен дә, бүгенге көннәрне дә, киләчәкне дә дөресрәк күзалларга — исәннәрнең кадерен ныграк тоярга, үлгәннәрнең каберен белергә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

ХАТ-ҮТЕНЕЧ

Хөрмәтле дустыбыз, кардәшебез, замандашыбыз һәм шул замандагы авырлыкларны кичерүдә, милләттәшебез Салих Борһан улы Вәлиди, гомерең озын, ямьле һәм данлы булсын! Бу — минем теләк. Шуның белән бергә, иске әлифба белән язганга гаепләмәгез. Күзләрем начар, күрү сәләтен югалтып баралар. Шунлыктан хәзерге хәрефләр белән яза алмыйм, тик кешеләрдән генә яздырам.

Салих, син борчуым өчен мине гафу ит. Үзе борчылган кеше башкаларны да борчый торган була. Мин исә мең төрле борчылулар белән камап алынган кеше, ягъни мине тормышта борчулары табигый...

Үзегезгә мәгълүм, Каюм Насыйри бу хакта «... татар теленә 35 ел хезмәт иттем, ләкин берәү дә моңа игътибар бирмәде», дигән фикерен бер китапта язып калдырган. Каюм Насыйрилар чоры өчен бу бик табигый ятышып тора. Безнең чорда, социализмнан коммунизмга бару чорында, мондый зарланулар урынсыз булыр иде. Ләкин чоры зарландыра да. Шул чорда яшәүче кайбер бәндәләр безнең ишеләрне зарланырга мәҗбүр итәләр.

Мин татар теленә һәм әдәбиятына үз гомеремнең 50 елын багышладым. Бу хезмәтемнең күренеп торган нәтиҗәсе дә бар. Алар, мәсәлән, үзегезгә мәгълүм: татар диалектологиясе дигән фәнне яңабаштан аякка бастыручыларның беренчесе булдым. Сезнең нәшрият хезмәткәрләре минем хезмәтләремне, матбугатка чыгарып, халыкка җиткерделәр. Алар турында бер генә яман сүз дә ишетмәдегез. Алар чыктылар, дөньяга таралдылар. Складларда ятып, череп калмадылар. Алай гына түгел әле, бүгенге көндә миннән ул китапларымны күрше дус илләрдә дә соратып яталар. Ләкин аларның бер данәсе дә сакланмаган, хәтта үземдә дә сакланмаганнар. Мин Казан университетында татар бүлегендә 25 еллар укыттым. Шушы дәвердә мин, татар әдәбиятын, татар теле тарихын фәнни эшкәртеп, студентларга лекция укый килдем. Хәзерге көндә ул курсның шәкертләре үзләре укыталар. Татар теленең тарихы, грамматикасы курсын төзү һәм укыту минем өскә төшкән иде. Монысы тагын да катлаулырак, авыррак өлеше буларак, миннән күп көч салуны таләп итте. Мин аяксыз калдым, йөри алу сәләтемне югалттым. Ләкин эшемне ташламадым, бурычымны үтәдем. Бу курсны да төзедем. Сез — нәшрият хуҗаларына — татар теленең тарихи фонетикасы дигән өлешен басма хәлендә китердем. Дөньяга чыгардыгыз. Монысы да сатылып бетте.

Димәк, татар теленең тарихи грамматикасы дигән зур курсның бер өлеше дөньяга чыккан була инде. Мин бу курсның икенче өлешен, ягъни тарихи морфологияне фәнни эшкәртеп, басмага, сезгә тапшырдым. Бүгенге көнгә чаклы сез шуңа тираж бирә алмый утырасыз. Яшь галимнәребездән берәү: «Китапны язуы кыен, тиражны кирәкле китап үзе җыя», дигән иде. Һичшиксез, бу акыллы сүз иде. Минем китапларның таралуына һич шикләнмим. Дөрес, бер көн эчендә генә таралып бетмәс. Әмма складларда ятып калмаячаклар. Бер-ике елдан бу китап көндез шәм яндырып эзләсәң дә табылмас. Сәбәбе ачык: беренчедән, татар теле грамматикасы дигән курсны хәзерге көнне программалы курс итеп укыталар. Әмма ул курсны ничек итеп укыталар, нинди материаллардан файдаланалар, нинди материаллар белән тәэмин итәләр — мин белмим. Һәм бу сезгә дә билгесез. Бәлки, бу курсны укытучылар кыйммәтле гомерләрен әрәм итә торганнардыр. Мин, укытучылар белән гәпләшеп йөри алмасам да, читтән күреп, аларның бу тарихи эшләрен белеп, сизеп ятам (...)

(...) Әлегә төрки телләрнең берсенең дә тарихи грамматикасы язылмаган, дөньяга чыкмаган.

Татар диалектологиясен фәнни эшкәртү буенча без СССРдагы төрки халыклар арасында беренче урынга чыккан идек. Менә шуны истә тотсагыз иде (...)

(...) Салих! Татарстан китап нәшрияты портфелендә минем берничә хезмәтем ята. Әмма мин, үзем исән шушы көннәрне, бер тиен акчасыз утырам, карчыгым, үлеп китү сәбәпле, материаль тормышыма кыенлык китерде.

Шушы җимерек гаиләне яңадан аякка бастырасы бар. Моның өчен материаль ярдәм кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла. Кыскасы, үтенеч шул. Ләкин, бер дә тартынмый, икеләнмичә генә, минем китабыма тираж бир. 23 съездда фәнне үстерүгә зур урын, игътибар бирелә (...)

Сәлам белән
аз азыклы, күп языклы
ҖӘЛӘЕГЕЗ...
Унберенче май, 1966 ел.

ГАРМУН УЙНЫЙ БЕЛӘСЕҢМЕ?

ХАЛЫКНЫ МОҢ ЯШӘТӘ

Татарстанның атказанган артисты Рәсим Сәләховтан «Гармун уйный беләсеңме?» дип сорау бик үк урынлы да түгелдер. Без аның мондый мәһирлыгын җырлы-биюле спектакльләрдә дә күрәбез. Әмма сәхнә остасы белән оештырылган бүгенге әңгәмәдә театр сәнгате серләре түгел, ә нәкъ менә гармун, халык бәгыреннән аерылгысыз булган шушы уен коралына бәйле хәлләр үзәккәрәк алынды.

— Кеше күңелен, аның халәтен чагылдыра торган, аның рухына туры килә торган көйләр була. Рәсим әфәнде, күңелгә уй төшкәндә яки киресенчә, күңел канатланып йөргәндә бармаклар нинди көй уйный башлый?

— Кулыңа нинди гармун аласың бит. Әйтик, тальян икән, анда бөтенләй башка көй уйнарга кирәк. Татарның моңлы, озын көйләрен. Ике рәтле хромка гармун тотсаң, ул күбрәк рус көйләрен ярата. Татар көйләре дә бик әйбәт чыга, әлбәттә. Ә инде менә Саратов гармуннарының үзенчәлекле яклары бар: әйтерсең, алар кыска һәм дәртле көйләр өчен яратылган. Мондый хасиятне сүз белән генә дә аңлатып бетереп булмый. Кыскасы, һәрбер гармунның үз холкы, үз сагышы, үз моңы. Халкыбызның, әйтик, «Күбәләгем» көен Саратов гармуныннан да матур яңгыратучы гармун юк. Уйнаучысы киң күңелле, олы җанлы кеше булса, билгеле.

— Сез баянда да, аккордеонда да уйнарга өйрәнә алгансыз. Ә шулай да җаныгыз кечкенә генә Саратов гармунына ныграк тартыла кебек?

— Ә-ә, аның үзенә күрә сере бар шул. Бу кечкенә гармунны кулыма алсам, яшьлегем хатирәләре яңара, авыр сугыш еллары искә төшә, авылда үткән балачагым еллары... Бу гармун беренче мәртәбә минем кулыма сугыш елларында килеп керде. Мин ишле гаиләдә үстем, без биш бала идек. Ә сугыш елларында берсеннән-берсе кечкенә биш балалы гаиләнең хәлен күз алдына китерү кыен түгелдер. Ул чакта тормыш базар аркылы алып барыла иде бит инде. Хәзерге шикелле кибетләргә кереп, җаның ни теләсә, шуны ала алмыйсың. Акча дигән нәрсә юк, бар нәрсә алмаштыру юлы белән табыла. Әйтик, бәрәңгең, оның булса гына кирәк нәрсәңне юнәтә аласың.

Менә шул елларны безнең әни базардан Вараксин гармуны сатып алып кайтты. Бу бик моңлы тавышка ия булган көмеш телле гармун иде. Әлбәттә, ул абыема алынган иде. Абыем миннән дүрт яшькә зуррак. Мин әле ул чакта дүрт кенә яшьлек малай. Шуңа күрә бу гармунда уйнарга абыйга гына рөхсәт ителә. Әни эшкә киткәндә, гармунны сандыкка салып, өстенә ястыклар, мендәрләр өеп китә. Мин сандыкны үзем генә күтәреп ача алмыйм, шуңа күрә күрше малае Фасилне чакыра идем. Сандыкны ачып, гармунны алабыз да, икәүләп уйнарга өйрәнәбез. Җәй иде. Күпме вакыт узгандыр инде, берчакны әни эштән иртәрәк кайтып керде. Күрә: өйдән гармун тавышы килә, тавыш кына да түгел, көй ишетелә. Шуннан кем уйный икән, дип керсә, моны мин маташтырып ятам икән. Көй әйбәт үк чыккан, күрәсең. Инде шуннан соң әни гармунны бөтенләйгә минем ирекккә тапшырды. Менә кайчан өйрәнеп киттем мин уйнарга.

Безнең авылда гармун ул вакытта юк диярлек, түбән очта бер кешедә генә тальян бар иде. Әлеге егет тальянда җыр көйләрен генә уйный, бию көйләрен белми иде. Нишләптер, мин башта бию көйләрен уйнарга өйрәнгәнмен, шуңа күрәдер, мине гел вечерга чакыралар иде. Кичке уеннарны безнең якта шулай вечер дип атыйлар. Авылыбызда клуб юк иде. Мәктәпкә җыелган яшьләр, парталарны бер якка тезәләр дә, түгәрәк ясап, туйганчы бииләр. Мин — 4-5 яшьлек бәләкәй малай. Әнидән сорап киләләр, малаеңны безнең янга җибәр әле, диләр. Әни әйтә: буран бит, баланы ничек чыгарып җибәрим, ди. Шуннан мине чанага юрган белән төреп утырталар да, тартып алып китәләр, бию көйләре уйнатып, кире кайтарып куялар иде.

Бу гармун менә шушы ягы белән минем бик нык истә калды.

— Сугыш вакыты, газаплы еллар... Ирләр фронтка китеп беткән. Тормышның иң авыры хатын-кыз өстенә төшкән. Болай да дөньяның очын-очка көчкә ялгап барган ялгыз хатын, ягъни әниегез, базардан гармун сатып алырга ничек җөрьәт итте икән?

— Шушы хакта үзем дә еш уйлыйм. Бу, күрәсең, болай булгандыр. Безнең әти фронтка сугышның беренче көннәреннән үк, колхоз председателе булып эшләгән җиреннән китә. Яшерен-батырын түгел, колхоз председателе инде ул барыбер хәлләрәк яшәгәндер, дип уйлыйм мин. Әле сугышның беренче елларында без авырлыкны бик үк күрмәдек. Әтидән калган мал әле берничә елга җиткән, күрәсең. Гармун шушы «хәллелек» нәтиҗәсендә килеп кергәндер, дип уйлыйм. Шулай килеп кергән гармун соңыннан фаҗигале рәвештә чыгып та китте.

Сугыш бара торды. Авылдагы хәлләр дә көннән-көн авырлашты. Бервакыт, әле дә хәтерлим, ашарга бетте. Он юк та юк инде. Бәрәңге дә калмады. Без өч ир бала үстек, ике кыз бала. Әни берзаман әйтә: «Балалар, гармунны сатмыйча булмас, — ди. — Юкса, сезнең үзегезне саклап калу бик авыр булыр».

Шуннан соң гармун китте базарга. Анда моны күрше авылның тегермәнчесе дүрт пот ярым арыш онына алыштырып алган. Шуның белән без, бәлки, үлемнән дә котылып калганбыздыр. Чыннан да, ул безне ач үлем тырнагыннан йолып калды.

Гармун китте, моңы калды. Аны сагынулар!.. Яз җитте. Су буена төшсәң, шунда гармунның моңы килә. Болынга барсам, шуның моңын ишетәм кебек. Төшләремдә газиз гармуным тавышын ишетеп уянам.

Могҗизалар була, кызык хәлләр була. Шулай бервакыт өйдә утырганда, җәй көне бу, каяндыр минем гармун тавышы ишетелә. Йөз гармун уйнап торса да, үземнекенең тавышын таныйм мин. Төш тә түгел, югыйсә, каян ишетелә?! Урамга йөгереп чыктым. Карасам, күрше малае капка төбендә минем гармунда уйнап утыра. Яшьтәшем яхшы белә: бу бит минем гармун. Теге кеше аны яңадан сатып җибәргәч, гармун шулай күршебезгә кайтты. Гармунны кулыма алдым. Бармакларым көмеш телләрен үлеп сагынганнар, көй үзеннән үзе агыла башлады. Гармун кайтты! Мин еш кына күршеләргә кереп уйный идем. Шулай йөрәгемне юаттым. Гармун безнең авылда торып калды. Үсеп җиткәч тә, китеп-кайтып йөргән чагымда да сагындырып торган шул гармунда уйный идем.

Гармунның тавышын тану дигәннән, тагын бер хатирә. Җәйнең кызу көннәре. Бәрәңге утый торган вакыт. Безнең олы апа белән абый колхоз эшенә киткәннәр. Без — өч бала — бәрәңге утыйбыз. Өйгә катып кергән әни гармунның юкка чыкканлыгын абайлап алган. Безнең янга йөгереп чыкты. Тегеннән карыйбыз, моннан карыйбыз — юк кына бит. Ул вакытта ишек бикләү юк иде, безнең авылда белмиләр иде аны. Авыл кешесе алмый, урласа — шундук сизелә бит. Шуннан бер атна дигәндә, әни гармунны табып кайтты районнан. Беләсезме, әниебез авылларда ничек йөргән? Кичен кайсы авылда гармун тавышы ишетелә, шуннан эзләгән. Гармунның тавышыннан эзләп тапкан. Мари авылы бар иде. Бишенче дигән авыл. Мари халкы да ярата мондый гармунда уйнарга. Кеше гармунына кагылырга ничек җөрьәт иткәннәрдер?! Алар инде, алып кына тордык, дип аңлатмакчы булганнар. Гармуныбыз яңадан кайтты. Бер китте, бер кайтты — шулай йөрде. Язмышы үкенечле дә, кызыклы да булды.

— Сез хәзер Татарстанның танылган артисты. Спектакльләрдә күп уйныйсыз. Гармунчы кешегә сәхнәләрдә уйнавы җиңелрәкме? Әллә авырлыклары да бармы? Гармунчы аннары мутрак кеше дә бит әле ул. Шуңа күрә рольләрнең кызыграгы да эләгергә мөмкин. Сезнең белән дә шулай булмадымы?

— Артист әгәр үзе гармунда уйный белсә, бу, һичшиксез, отышлы. Хәзер, гомумән, артистлар үзләре уйнарга тырышалар. Андый рольләр туры килгәләде, Аллага шөкер. Әйтик, Аяз Гыйлаҗевның «Я кайтырбыз, я кайтмабыз» дигән пьесасы буенча эшләнгән спектакльдә уйнадым. Сугышка гармун уйнап китә иде героем. Аннан соң «Бәхетсез егет» тә кечкенә генә бер эпизодта катнаштым. Тамашачылар, бәлки, хәтерлидер. Каракчылар типтерәләр подвалга җыелып. Шунда мин «Алтын-көмеш» көен уйный идем. Кечкенә генә эпизод, ләкин гармун уйнап җибәрү бәләкәй генә рольне дә бизәп җибәрә, образны халыкның күңеленә сеңдерә.

Шулай ук Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» исемле әсәрендә дә кечкенә генә роль бар. Татар яшьләре җыелып утыралар. Мәшһүр Тукайның үзен кунакка чакырган болар. Менә шунда Тукай алдында бер егет гармунда уйный. Бик борынгы көй инде ул. Сүзләре бик матур яңгырый аның:

Ак перчәткәң бар мәллә,
Бармакларың тар мәллә?
Өйләнәсең дә карыйсың —
Әйтер сүзең бар мәллә?

Халыкның моңы шушы гармуннардан башлана инде. Чыннан да, тальян биниһая моңга ия. Ә менә бу Саратов гармуннарында — күпме дәрт, очкын. Сугыш вакытында уйнаган бию көйләрен башкарып күрсәтсәм, биемәс җиреңнән очып китәрсең. Искиткеч күренеш иде ул. Әйтик, безнең авылда биючә егетләр бик күп иде. Рәҗәп исемле абый чыгып бии башлый, биюне ак тула оек белән матур иттереп чабатасын киген Газдали абый әләктереп ала. Ә кызлар чыкса!.. Бик матур истәлекләр калган ул чаклардан. Бер уйласаң гаҗәп инде: халык үзе ач булган, ә күңел сафлыгын, күңел көрлеген барыбер югалтмаган. Киләчәккә ышанычы булган, күрәсең...

Сугыш вакыты дигәннән бер фаҗигале вакыйганы искә төшерәсем килә. Берзаман тол хатыннар җыелган. Барчасының ирләре сугышта. «Балалар, сез тик кенә утырыгыз, мин кич утырырга керәм», — ди әни. Бераздан соң мине чакырып керттеләр. Гармун белән инде. Керсәм, бер генә дә ир заты юк — гел хатыннар. Миннән гармун уйнатып бииселәре килә икән боларның. Мин уйныйм, болар бииләр. Бик озак биегәннәр инде, мин йоклап та киткәнмен гармунны кочаклап.

Менә шул хәлнең сәбәпләрен мин еллар үткәч кенә аңладым. Әлеге хатыннарның фаҗигасын кара син! Сугыш вакытында да дәрт бар бит, бииселәре килә! Ә күңелләрен юатырлык берденбер нәрсә шул биш яшьлек малай кулындагы гармун булган.

Авылда гармун тавышы ишетелмәсә, эт өрмәсә, бака бакылдамаса, нинди матурлык бар?

Бервакыт авылда этләрне бетергәннәр. Кайтсам, туган җирдә нәрсә җитми, дим. Баксаң, эт тавышы юк икән. Әтәч тә кычкырмаса, гармун да югалса, авылның шигърияте бетә. Кешенең рухы да сүрелә.

Еллар үткәч, Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» трагикомедиясе нигезендә куелган спектакль белән авылга кайттык. Бер төркем сәхнәдәшләр әбиләрдә утырдык инде. Аш мәҗлесе булды. Таң атып килә. Без авыл буйлап төшеп киттек. Ирек Баһманов баян уйный, шундый матур иттереп сыздыра инде! Әле авыл халкы тормаган. Без, уйный-уйный елга аркылы чыгып, тауга менеп киттек. Бу хәлгә бөтен авыл халкы уянып, ай, Ходаем, көтү куарга соңардык, дип ятакларыннан сикереп торганнар. Бер кеше дә ачуланмады. Радио уйный башлаган дип уйлаганнар алар.

— Сезнең авыл Башкортстан чигендә, Татарстаннан ераграк урнашкан. Бүленеп, утрауда калган кебек. Хәзер нинди хәлдә сезнең авыл? Элеккеге матурлыгы азмы-күпме сакланганмы?

— Барыбер дә сакланган. Тайгада калган авыллар бар бит: кеше күзеннән, үзектән читтә. Безнең авыл да үзенә генә хас сыйфатларын саклап калган. Ул бик кечкенә иде. Җөйләү дип атала. Исеме дә ничек матур бит. Районнарда кечкенә авыллар таралып беттеләр. Безнең авыл, киресенчә, үсә генә, матурлана гына барды. Шушы яктан бик кызык иде бит: Уфадан да ерак, Казаннан да ерак. Уфага барсаң, син татар, диләр. Казанга килсәң, син башкорт, дип, теңкәне корыталар. Ике яктан бүленеп калганбыз. Менә хәзер дә шушындый драматик хәл кичерә бу районнар. Әйтик, Илеш, Дүртөйле... Баксаң, чын татар районнары. Бик матур сөйләшүләре, телләре. Хәзер инде, Аллага шөкер, мәктәпләрдә татар телендә укыта башладылар, югыйсә. Башкортчага күчергәннәр иде башта.

Минем каян башыма килгәндер: җиденче классны үзебездә бетергәч, Актаныш районына чыктым укырга. Юкса, әйтүче-өйрәтүче дә булмады. Күңел тарткандыр инде үз халкың янына. Урта мәктәпне Байсарда бетердем, Актаныш районында. Ул бездән ерак түгел иде, Сөн аркылы гына чыгасы. Шуннан соң мине язмыш инде Казанга тартты.

— Урта мәктәптә укыганда гармунны аеруча күп уйнарга туры килгәндер инде. Гармун күпмедер дәрәҗәдә ирекне кысмыймы?

— Ничек?..

— Башкалар кызлар белән рәхәтләнеп бииләр, җырлыйлар, ә гармунчы гел ахырдан гына урыныннан тора...

— Ә-е, анысын әйтәсез икән.

— Менә шушы яктан кимсенү дигән нәрсә юк идеме? Әйтик, безнең авылда бер гармунчы бар иде. Шундый халәткә килеп керә, уйнаган җиреннән гармунын ташлый да өенә кайтып китә...

— Ә мин үзем гармун уйныйм, күзем һәрчак биючеләрдә иде. Кызларны акрын гына күзләп утыра идем. Болай җайлырак та әле. Махсус күзләгән шикелле түгел. Үзем яшьләрне биетәм, ә үзем карап утырам рәхәтләнеп кенә. Аһ, бу кыз матур бии, сылулыгы, чибәрлеге дисеңме, аһ, бу кызны озатсаң иде, дип. Урта мәктәптә укыганда укытучылар безне кичәләргә йөрүдән тыялар иде. Аның саен авыл яшьләре килеп чакыра. Егет булып йөрисе килә бит әле. Ә укытучылар моны бик өнәп бетермиләр. Хәзер алай түгелдер, әлбәттә.

...Без биш бала үстек, дидем, өч ир туган. Өчебез дә гармунда уйныйбыз. Кайтсак, без өчәүләп тә гармуннарны тартып җибәрәбез Сабан туйларында. Абыем — Әбүзәр, энем — Роберт. Олы апам бик матур җырлый, сеңлем дә аннан калышмый. Гомумән, без көй-моңнарны яратып үстек. Әниебез бик матур җырлый, шигырьләр яза иде. Шигъри күңелле хатын булган мәрхүмә. Сугыш вакытында лампа яктысында кич утырдылар бит инде. Әни җырлый, үзеннән-үзе сүзләрен чыгарып җырлый. Әнигә кайчакны әйтәбез: гөлләр, чәчәкләр турында җырлар күп, ә менә йозак турында җырлап буламы? Күзебез шул чакны йозакка төшкән булган, күрәсең. Шунда инде әниебез, уйчанланып куя да, көйли башлый:

...Эленеп тора ак йозак,
Көтә-көтә күзем талды
Ник кайтмыйсың бик озак...

Әтине сагынуыннан өзгәләнеп җырлавы булган икән.

«Әни, ә утынга нәрсә җырлап була соң?» — дибез

Кич утырып утын яктым
Шартлый-шартлый янсын, дип.
Ходай безгә теләгәндер
Ирдән ялгыз калсын, дип.

Мин, гомумән, үзебезнең халыкка гаҗәпләнеп карыйм. Кая гына барсак та, Уфада булыйкмы, Себер якларындамы, Урта Азиягә чыгып китикме, халкыбыз җыр-моңны, сәнгатьне үлеп ярата. Безнең спектакльләр көчле алкышлар астында үтә... Заллар һәрчак тулы. Казанны гына карагыз: ике-өч театр эшләп ята. Шул ук вакытта тулы залларда күпме концертлар бара. Ә бу хәлне башка халыкларда күрә алмыйсың. Урыс театрларына, әнә, халык йөрми. Мәскәүнең нинди бөек театрлары бик аяныч хәлдә. Без аларны буй җитмәслек театрлар итеп күрә идек. Хәзер алар кычкырып яналар. Шундый чакны безнең академия театрыбыз, Тинчурин исемендәге театр гөрләп эшли. Шушындый халкыбыз яшәгәндә, безнең театрыбыз да яшәр, сәнгатебез дә үлмәс, кешеләрнең җаныйнда җырга-моңга һәрчак сусау булыр. Иншалла, мин шуңа ышанам һәм шулай булыр да!

Әңгәмәне
Ракыйп ГАФФАР оештырды.

Китап күңел үстерә

Ил яшәве — җыр белән

Өстәлемдә яңа китап ята. Исеме ике сүздән генә торса да, ул сүзләр күңелгә бик тә якын һәм кадерле: «Татар җырлары»*. Чәчәкләр белән бизәлгән китап тышлыгындагы бу сүзләр халкыбыз тарихына тыгыз бәйләнгән өч әлифба үрнәгендә — гарәп, латин һәм кириллицада язылганнар. Татар җыры үткән озын тарихка, гүя, бер ишарә әлеге имлялар. Әйе, милли җырларыбыз чишмәсенең башы чал тарихлар түренә барып тоташа. Дөньяда иң матур туган телебез, иң гүзәл җырларыбыз-моңнарыбыз, иң газиз Ислам динебез, иң кыйммәт борынгы басма китапларыбыз — шулар түгелме халкыбызны югалып-эреп бетүдән саклап калган кодрәтле көчләр, мөкатдәс чыганаклар!

Китап битләрен актарам. Анда әүвәлдән мәгълүм җырлар белән беррәттән, соңгы вакытларда ишетелә башлаган халык җырлары белән янәшәдә шагыйрьләр һәм композиторлар тарафыннан язылганнары да тупланган. Җәмгысе 550 дән артык җыр. Җыр мәҗмугалары басу тарихында әле болай саллы итеп, зәвыклы итеп төзелгән җырлар китабы юк иде сыман. Тарихны искә алуым юкка түгел. Чөнки җыр китаплары бастыруның озын гына тарихы бар: ул татар халык җырларын туплаган кечкенә басмалар чыгарудан башлана. Моннан йөз илле еллар элек. XX гасыр башында исә «Менә дигән шәп җырлар» сериясендәге нәни китапчыклар, ел саен берничә тапкыр нәшер ителеп, татарлар яшәгән бөтен тобәкләргә диярлек таратылган. Аларны китап белән сәүдә кылучы агайлар, арбаларга төяп, авылдан-авылга сатып йөргәннәр. Шул китапларның кайберләрен мин Пенза, Мордовия якларындагы татар-мишәр авылларында фольклор экспедицияләре белән йөргәндә күреп хәйран калган идем. Аларның дини китаплар белән бер шүрлектә саклануларыда гаҗәпләндерә торган бер хәл бит.

Форсаттан файдаланып, мин соңгы чорларда популяр җыр китаплары төзеп халкыбызның моңга булган сусавын басарга булышкан һәм милләттәшемнең исемен хөрмәт белән телгә алып үтәр идем. Сүз илленче-алтмышынчы елларда бу өлкәдә күп хезмәт күрсәткән музыка белгече Зәйнәп ханым Хәйруллина һәм соңгы ун елда «Җырларыбыз», «Җырлап ачыла күңел» дигән матур җыентыклар белән куандырган мәгълүм шагыйрь Зиннур Мансуров турында бара. Миңа да бер аралыкта «Җырлар китабы», «Җырлыйк әле» дигән җыентыкларны дөньяга чыгару насыйп булган иде. Боларны искә алуның бер мәгънәсе бар. Чөнки алар әле яңа гына китап кибетләренә чыккан «Татар җырлары» басмасының буш урында барлыкка килмәвен һәм шул ук вакытта аның яңалыгын, өстен якларын чагыштырма билгеләү өчен зарур нигезләр.

«Татар җырлары» җыентыгын танылган шагыйрь Харрас Әюп төзегән. Бу эшкә ул күп көч куйган. Мондый җыентыкларны әзерләгәндә төзүченең асыл максаты җырларны белеп, күңел аша үткәреп сайлауга кайтып калуын искә төшерик. Җырның шигъри текстын гына түгел, көй-музыкасын да истә тоту бик мөһим. Чөнки җыр ул — музыкага салынган шигърият әсәре бит. Китапка сайланган җырларның күпчелеге нәкъ менә шундый әсәрләр. Бу исәпкә мин иң әүвәл халкыбызның борынгы һәм без яшәгән дәвердә иҗат ителгән җырларын кертер идем. Китапта аларның йөздән артык үрнәге бирелгән. Аерым шагыйрьләрнең татар халык көйләренә язылган җырлары да елдан-ел күбәя бара. Җыентыкта алар да онытылып калмаган.

Шагыйрьләр белән композиторлар иҗат иткән җырларга, ягъни авторлы җырларга килсәк, монда хәл катлаулырак. Китапта бу жанрга караган 430 дан артык җыр кителгән. Байтагы чын мәгънәсендә вакыт сынавын узган, киң таралган, ихтирам казанган җырлар. Аларның үзәк өлешен С.Хәким, Ә.Ерикәй, М.Ногман, Г.Зәйнашева, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Р.Миңнуллин, Р.Харис, Р.Вәлиев кебек күренекле шагыйрьләр иҗат иткән. Мондый җырларның саны ике йөздән артык. (Мин аларның икенче авторларын — композиторларны бирәдә санап тормыйм, чөнки бүген сүз җырларның шигъри өлешен туплаган китап турында бара бит). Җыр жанрын баетуга олы хезмәт куйган бу шагыйрьләр сафы артыннан өметле яшьләр килүе куандыра.

«Татар җырлары» китабының бер яңалыгы дип әйтимме, төзүче җыр текстларын һәр очракта да шигырь дип атый. Мантыйк буенча шулай булырга тиеш кебек. Җырның тексты шигъри фикергә һәм хискә ия сурәтле әсәр буларак истә калырга тиеш. Алай да бу җыентыкта шигырь булудан шактый ерак торган тезмәләр дә очрый. Төзүче, бәлкем, аларның музыкасы әйбәт, алар популяр санала бит, дип акланыр. Мондый җавапның вакытлыча дөрес булуы да мөмкин. Бер генә мисал китерим. Мәгълүм җырчы Хәния Фәрхи язган «Сагынам сине, Питрәч» тезмәсен искә төшерик. Бу җырның көе халыкныкы, ә сүзләрен шигырь дип әйтергә һич тә тел бармый. Рифмаларына гына күз салыйк: «югалам-саклаган», «кайталар-сабыйлар», «адашып-яратып». Анда истә калырдай сурәтле фикер дә, хис тә юк. Р.Тимербаевның «Сагындым авылымны», Ф.Садриевның «Җырлагыз, кызлар» исемле җырларга язган текстларына да шул ук кимчелекләр хас.

Китапта үкенечле хата да киткән. «Яран гөл» дигән популяр җырның шигырен Резеда Вәлиева язганлыгын күпләр белә дип уйлыйм. Чөнки берничә ел әүвәл «Татар җыры» конкурсында әлеге әсәрнең (музыкасын Сәүбән Чуганаев язган) авторлары югары бүләккә лаек булганнар иде. Китапта шагыйрәгә исеме урынына «халык сүзләре» дип язылган.

Эчтәлеге һәм образлары белән безнең бүгенге заман рухына туры килеп бетмәгән, искергән һәм инде репертуардан төшеп калган кайбер җырларның яңа басмаларга кертмәү хәерле булыр дигән теләк әйтәсе килә. Сүз «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Ә.Ерикәй), «Ак каен» (Х.Туфан), «Яшәсен кияүләрем» (М.Хәсәен) кебек җырлар турында бара. Әмма иң әһәмиятлесе: матур рәсемнәр, милли орнаментлар белән бизәлгән һәм бүләк рәвешендә затлы кәгазьдән әзерләнгән бу китап җыр сөючe меңләгән милләттәшләр өчен чыннан да кадерле бер бүләк булачак.

Илбарис НАДИРОВ.

---

* Татар халык җырлары. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1995. -640 бит.

Мәгыйшәт кануннары

«Халык зур ул, көчле ул, әдип ул, шагыйрь ул!..»

Бөек Тукаебызның бу канатлы сүзләренә тулы нигез белән: «Халык — тәрбияче ул, педагог ул!» — дип тә өстәп булыр иде. Чөнки халык элек-электән үк үзенең матур гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре һәм бигрәк тә авыз иҗаты әсәрләре аша кешеләрдә югары рухи сыйфатлар тәрбияләп килә. Фольклорны һич арттырусыз: халыкның әдәп-әхлак кодексы, җәмгыятьтә үз-үзеңне тота белергә өйрәтүче язылмаган кануннар, дип бәяләргә мөмкин.

Танылган фольклорчы-галим, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Хуҗи Мәхмүтовның күптән түгел генә дөнья күргән «Язылмаган кануннар» дигән китабы* нәкъ менә шушы мөһим теманы — фольклорда күтәрелгән әдәп-әхлак мәсьәләләрен яктыртуга багышланган.

Китап өч бүлектән тора. Беренче бүлекнең төп эчтәлеген «Күркәм холык малдан артык» дигән исеме үк ачык аңлата. Биредә сүз халкыбыз тарафыннан гаять югары бәяләнә торган һәм аның үзенә дә хас булган гүзәл рухи сыйфатлар: Туган җиргә, Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек, ата-анага, олкәннәргә хөрмәт-итагать, хезмәт сөю, һөнәргә, белемгә омтылу, батырлык, гаделлек, сабырлык, тыйнаклык, кунакчыллык, юмартлык, пөхтәлек һ.б. хакында бара. Автор бу темаларның һәркайсына махсус бүлекчәләр багышлый: «Үз илең — гөлстан», «Белем — гомер чырагы»**, «Батыр егет — ил күрке», «Кунак килсә — өйгә ямь», «Икмәктән олы аш юк», «Пакьлек сөйгән сау булыр» һ.б. Автор фольклор әсәрләрендә гәүдәләнгән мондый алдынгы идеяләрнең реаль тарихи җирлеген ачуга да даими игътибар бирә. Әйтик, Идел Болгарстанында фән, мәдәният, һөнәрчелек һ.б. ларның югары дәрәҗәгә ирешүе турында борынгы чыганаклардан дәлилләр китерә. Халык карашынча, кешедәге аеруча күркәм рухи-әхлакый сыйфатлардан берсе — югары тел культурасына ия булу. Китапның «Әдәп башы — тел» дип исемләнгән икенче бүлеге тулысы белән шушы темага багышланган. Ул «Туган телем, иркә гөлем» дигән бүлекчә белән ачыла. «Туган тел — ул халыкның гомерлек юлдашы, терәк-таянычы, шатлык-юанычы. Туган тел үзенә халыкның зирәк акылын, тирән фәлсәфәсен, саф әхлагын, күркәм гореф-гадәтен, кыскасы, аның бөтен барлыгын, бөтен асылын сыйдырган. Шуңа күрә дә халыкның яшәешен, аның язмышын, киләчәген бары тик туган тел белән аерылгысыз бәйләнештә генә күз алдына китерергә мөмкин», — дип яза автор.

Тирәнтен уйлап әйтелгән бу сүзләрнең никадәр хаклылыгын китапның өченче бүлеге белән танышканда да ачык тоябыз. «Хикмәтле энҗеләр» дип аталган бу бүлектә галим телебездәге күп кенә сурәтле тәгъбирләрнең, мәкаль-әйтемнәрнең мәгънәләрен, кулланылыш үзенчәлекләрен аңлата, аларның ничек барлыкка килүләре тарихын ачыклый. Чыннан да, хикмәтле икән ул мәкальләр тарихы! Авторның эзләнүләре безне ифрат та мавыктыргыч, тылсымлы һәм гыйбрәтле өлкәгә — борынгы йола-ышанулар, мифлар, риваять, легенда, әкиятләр дөньясына алып китә...

Һәркемгә аңлаешлы җиңел һәм матур тел белән язылган бу китап киң катлау укучыларга халкыбызның бай рухи дөньясын тирәнрәк һәм тулырак аңларга, аның иксез-чиксез акыл-зиһен, тел-сүз хәзинәләрен, күп гасырлар буена тудырып, туплап килгән югары әдәп-әхлак кагыйдәләрен, күркәм гореф-гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итәчәк.

Укытучылар, тәрбиячеләр, мәдәният хезмәткәрләре үзләренең укыту-тәрбия эшчәнлегендә Хуҗи Мәхмүтовның «Язылмаган кануннар» исемле бу яңа китабыннан шулай ук зур файда һәм ярдәм табарлар, дип ышанабыз.

Фәнис ИСЛАМОВ.

---

* Хуҗи Мәхмүтов. Язылмаган кануннар. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1995. -174 бит.

** Чыраг — шәм, лампа. Биредә «яктырткыч» мәгънәсендә.

Билер ягы телевизор караучылар игътибарына!
24, 25, 26, 27 июль көннәрендә, техник элемтә чараларына планлы ремонт үткәрелү сәбәпле, барлык каналларның тапшырулары иртәнге сәгать 8 дән кичке 5 кә кадәр трансляцияләнми.

ДҮШӘМБЕ 24 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 Мультфильм. 18.40 Балалар өчен концерт. «Данирә белән Ләйсән». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 «Очрашулар». Рәзил Вәлиев, Надир Дәүләт. 21.15 Ренат Ибраһимов җырлый. 21.35 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Необыкновенный матч». 7.30 «КиноМеню». 7.45 «Эфирда — музыка». 8.20 Нәфис фильм: «Чанди» (Һиндстан). 1 нче серия. 9.50 «Эшмәкәрлек — саннарда». 10.20 Музыкаль программа: «Игорь Саруханов җырлый». 10.50 Кыска метражлы нәфис фильм: «Покорители гор» (Грузия). 11.15 «Супер-чэннел» программасы. 17.00 Документаль фильмнар: «Моя крылатая Россия». 2 нче кисәк, «Мой Мышкин», «Воронеж: мгновения веков». 17.50 Чегән романсларын Виктор Светлов башкара. 18.20 «100 градус» программасы. 18.45 «КиноМеню». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.30 — «Шәһәр». Информацион программа. 20.45 «Телеэкспресс». 21.10 Казан: атна йомгаклары. 21.25 Нәфис фильм: «Цвет денег». 23.50 «TAP RECORDS» коллекциясеннән. Хулио Иглесиас җырлый.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.20 — Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 10.55 Спортның җиде көне. 11.25 Документаль фильм: «Жизнь прекрасна». 12.20 Телесериал: «ТАСС уполномочен заявить». 13.35 Клип-ревю. 14.00 Информацион күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 «Җырга мәхәббәт белән». Балалар хор коллективлары җырлый. 15.20 Эфирда «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 Йолдызлар сәгате. 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Тет-а-тет». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Әгәр». В.Познер алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 А.Солженицын белән очрашу. 22.00 Алла Ларионова «Анна на шее» фильмында. 23.05 Юрамалар. 23.50 «Гол».

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Россиягә Грузиядән караш. 9.20 Нәфис фильм: «Ка-ка-ду». 10.25 «Чегән романслары». Олег Погодин җырлый. 10.55 Телегазета. 11.05 РТВ — сайланмалар. «О-о-о...» Юрий Каледин. 11.35 Милиция хроникасы. 10.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 14.20 — Яңа тармак. 12.30 Эшлекле Россия. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 Көн дә бәйрәм. 16.30 Мульти-пульти. 17.20 Яңа тармак. 17.50 «Минем сугыш». П.Михайлов. 18.20 «Алыргамы-алмаскамы». 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 Нәфис фильм: «Последний автобус в Вудсток». 21.30 Клип-антракт. М.Шуфутинский. 21.40 Репортер. 22.00 Хакыйкать мизгеле. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Кинофестиваль хәбәрчесе. 23.55 Нәфис фильм: «Океан».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 Төш юрау. 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм. 13.35 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.50 «Музыка мизгеле». 14.00 «10 канун». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.40 «Кадимче». 16.10 Нәфис фильм: «Собака Баскервилей». 21.40 «Санкт-Петербург» телевидениесе. 22.45 Телефильм: «Предчувствие». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Пляж волейболы буенча Россия чемпионаты. 23.40 Музыкаль шоу: «Телекомпакт».

СИШӘМБЕ 25 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 Мультфильмнар. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Болл клубы». 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Пульс». Медицина программасы. 20.30 «Кафедра» хорының иҗат кичәсе. 21.15 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Война и мир». 2 нче серия. 1 нче кисәк. 22.10 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Футбольные звезды». 7.30, 20.20, 23.50 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (24 июль тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «Чанди» (Һиндстан). 2 нче серия. 9.45 Музыкаль программа. 9.55 Документаль фильмнар: «На Валаам!», «Владимир Высоцкий. Фотоальбом». 10.10 Кыска метражлы нәфис фильм: «Три жениха» (Грузия). 10.35 «Супер-чэннел» программасы. 17.00 Нәфис фильм: «Через тернии к звездам». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 19.20 Мультфильм: «Черный заяц». 19.30 «Без сайлыйбыз». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 «Казан автосалоны». 22.00 Россия киносы көне. Нәфис фильм: «Афганец-1».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.15 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Кеше, һәм закон». 10.50 «Спортның җиде көне». 11.20 «Экслибрис». 11.30 Документаль фильм. 12.20 Телесериал: «ТАСС уполномочен заявить». 13.25 Музыкаль программа: «Минем кадерлеләрем». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 «Ел әйләнәсендә — яшелчә бакчасы». 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 Яшь талантлар конкурсы. 16.40 «Сер итеп кенә». 17.00 «Кыска яңалыклар». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.40 «Беренче куллардан». 21.55 Владимир Высоцкий «Плохой хороший человек» фильмында. 23.30 «Юрамалар». 23.50 Джаз дөньясында. Төнге канал: 0.40 Кече театр фильм-спектакле: «Заговор Фиеско в Генуе». 2.05 С.Оснашвилиның иҗат кичәсе.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Телегазета». 11.05 «Зур низаг». 11.35 «Милиция хроникасы». 11.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.15 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Мазай бабай кунакханәсе. 16.45 «Клип-антракт». Шандор. 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Җиңү адымнары» телемарафоны (Төмән). 18.00 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 1 нче серия. 18.25 Әдәби-публицистик цикл: «Россия. «Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 «Сәүдә йортлы». 19.10 «L» клубы. 20.25 Нәфис фильм: «Осеннее солнце». 22.00 Киноафиша. 22.15 Хәтер театры. «Гамлет». В.Высоцкий. 22.45 «ЭКС». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Кинофестиваль хәбәрчесе. 23.55 Нәфис фильм: «Океан».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 8.00 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.00 Телесериал: «Четыре танкиста и собака». 10.10 «Төш юрау». 10.35 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм. 13.35 ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны. 13.50 Музыка мизгеле. 14.00 «10 канун». 14.30 Нәфис телефильм: «Мануэла». 15.15 Бакчачыларга киңәшләр. 15.30, 22.40 — ТВ мәгълүматлары. 15.40 «Музыка мизгеле». 15.45 Нәфис фильм: «Караул». 17.25 Телефильм-концерт: «Павловские музы». 18.15 «Бөтен Россия буйлап». 22.15 «Киномания» Канны баскычы яныннан репортаж. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Телеклассика». Н.Лесков. «Очарованный странник».

ЧӘРШӘМБЕ 26 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.25 Эфирда — эшлекле мәгълүмат. 18.30 «ЗИПОПО». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Ритм. Ритмика. Актер». 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Язучы фикере». Тәүфикъ Әйди. 21.05 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Война и мир». 2 нче серия. 2 нче кисәк. 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Таланты и поклонники», «Первый автограф». 7.30, 20.20, 23.45 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (25 июль тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «Командо» (Һиндстан). 1 нче серия. 9.30 «Грация». 10.10 Иерусалимнан язмалар. 10.40 «Супер-чэннел» программасы. 17.00 «Яңа сезоннар». 17.50 «Палитра: Тулуз-Лотрек». 18.20 Документаль фильмнар: «Киноэскиз о жизни и смерти», «Авангард Леонтьев». 18.45 Мультфильм: «Что услышала медуза». 18.55 «100 градус» программасы. 19.40 «Эфирда — музыка». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 Мультфильм: «Разными глазами». 21.15 Юмористик программа: «Бөтен җирдә су...» 21.35 «Үз кешеләр». 22.10 Нәфис фильм: «Афганец-2».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.25 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Хайваннар дөньясында». 10.50 «Спортның җиде көне». 11.25 Документаль фильм. 12.20 Телесериал: «ТАСС уполномочен заявить». 13.25 «Хит-конвейер». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Телеуен: «Мине аңла». 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 «Күңелле ноталар». 16.20 Мультсериал: «Путешествие в прошлое». 16.50 «Фэп-клуб». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Җыр-95». 20.45 « Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Орсон Уэллс фильмы: «Мистер Аркадин». 23.30 «Юрамалар». 23.45 XIX Халыкара Мәскәү фестивале көндәлеге. 0.00 Яңа обывательләр. Төнге канал: 0.50 Кече театр фильм-спектакле: «Заговор Фиеско в Генуе». 2.05 Музыкаль программа: «Замокта күргән төшләр».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Документаль фильм: «Мир искусства». 11.35 «Клип-антракт». 11.40 «Телегазета». 11.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.20 «Яңа тармак». 17.50 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 18.20 «Беркем дә онытылмаган». 18.25 Әдәби-публицистик цикл: «Россия. «Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 Барлык буын кешеләре өчен музыка. 19.25 «Үз уены». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.20 Михаил Боярский доминосы. 21.55 «Көтү залы». 22.40 «Бию-экспресс». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Кинофестиваль хәбәрчесе. 23.55 Нәфис фильм: «Женщина в песках».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 «Төш юрау». 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Нәфис телефильм: «Подзорная труба». 13.35 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.50 «Музыка мизгеле». 14.00 «10 канун». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.15 Бакчачыларга киңәшләр. 15.30, 22.40 — ТВ мәгълүматлары. 15.40 «Музыка мизгеле». 15.45 Нәфис фильм: «Торможение в небесах». 17.05 «Тарихи альманах». 17.35 «Балаларга — музыка». 22.05 «Санкт-Петербург» телевидениесе. 22.15 «Хатирәләребез җырлары». А.Колькер. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Гыйбадәтханә». 23.40 Нәфис телефильм: «Жермена и Бенжамен».

ПӘНҖЕШӘМБЕ 27 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.25 «Эфирда — эшлекле мәгълүмат». 18.30 Мультфильмнар. 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Без нинди?» Психолог Рамил Гарифуллин алып бара. 20.20 Сәнифә Рангулова җырлый. 20.35 Нәфис фильм: «Белый пароход». 21.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Метеор на ринге». 7.30, 20.20, 0.15 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (26 июль тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «Командо» (Һиндстан). 2 нче серия. 9.35 Экран яңалыклары. 10.10 «Җир ничек эшли?» 10.30 «Супер-чэннел» программасы. 17.00 «100 градус» программасы. 17.25 «Барысын да белергә телим». 17.35 Мультфильмнар: «Веселая карусель», «По лунной дорожке». 17.55 «Ушуайя». 18.15 Телесериал: «Саломея». 19.15 «Коммерция әйләнмәсе». 19.40 «Кыюлар һәм матурлар». 20.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Эфирда — музыка». 21.15 «Турыдан-туры элемтә». Студиядә Казан мэры К.Ш.Исхаков. 22.20 Атна фильмы: «Ухожеры».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.00 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 10.55 «Спортның җиде көне». 11.25 Документаль фильм: «Очарованные жизнью». 12.20 Телесериал: «ТАСС уполномочен заявить». 13.25 «Стоп-шоу». Клиплар. 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Телеуен: «Мине аңла». 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 «Мультитроллия». 16.20 «Золушкада кунакта». 16.40 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 17.00 «Кыска яңалыклар». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «16 яшькә кадәр булган үсмерләр һәм өлкәннәр өчен тапшыру». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.00 «Пик сәгате». 19.35 «Лотто-миллион». 20.05 «Хәтерләсеннәр өчен...» С.Гурзо. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.40 «Мәскәү — Кремль». 22.05 Телесериал: «Камо Грядеши». 1 нче серия. 23.05 «Юрамалар». 23.25 «Алтын шлягер». Төнге канал: 0.25 Телесериал: «Тень, или Может быть, все обойдется». 1 нче серия. 1.30 Музыкаль тапшырулар программасы. «Крестьянка» тәкъдим итә.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.20 «Вакыт елгасы». 8.25 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... Кирәк...» 8.55 «Төп мизгел». 9.05 «Святослав Рихтер». Артист тормышыннан сәхифәләр. 9.45 «Телегазета». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Музыкаль экспромт». 11.30 «Сәүдә йорты». 11.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 14.20 «Яңа тармак». 12.30 «Эшлекле Россия». 16.05 «Артек дусларын җыя». 17.20 «Яңа тармак». 17.50 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 18.20 «Беркем дә онытылмаган». 18.25 «Безнең бакча». 18.55 «Әйдәп баручы фаразы». 19.20 «Руслан караоке». 20.25 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.20 «Фортедан пианога кадәр». 21.55 «Гадәттән тыш канал». 22.45 «Клип-антракт». В.Байков. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 «Кинофестиваль хәбәрчесе». 0.00 «Хроно».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм. 13.35 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50 «Музыка мизгеле». 14.00 «10 канун». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.15, 22.40 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30 ТВ мәгълүматлары. 15.40 «Музыка мизгеле». 15.45 Нәфис фильм: «ЧП». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Нәфис телефильм: «Жермена и Бенжамен».

ЖОМГА 28 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 – 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 «Ералаш» киножурналы. 18.10 Мультфильмнар. 18.30 «Болл клубы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 «Әлли-бәлли-бәү». 19.55 «Урак өсте». 20.15 «Ислам чакыруы». 20.25 «Жомга көн кич белән». Альманах. 21.15 Ирина Хәкимова бенефисы. 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.00 Мультфильм: «Возвращение с Олимпа». 7.30, 20.20, 22.25 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 «Турыдан-туры элемтә». (27 июль тапшыруын кабатлау). 9.00 Телеэкспресс (27 июль тапшыруын кабатлау). 9.20 Нәфис фильм: «Русалочка». 10.40 Документаль фильм: «Ғайны пирамид». 2 нче кисәк. 11.30 «Супер-чэннел» программасы. 17.00 Телесериал: «Криминальные истории». «Погоня». 17.50 «Ә кеше трубада уйный». 18.50 Телесериал: «Саломея». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Суперспорт». 21.25 «Экология хәбәрчесе». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.50 Клод Шаброль фильмы: «Тихие дни в Клиши» (Франция — Италия — Германия).

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.30 — Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Жыр-95». 10.50 «Спортның җиде көне». Хоккей. 11.15 Документаль фильм. 12.20 Телесериал: «Два капитана». 1 нче серия. 13.25 «Компас». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Телеуен: «Мине аңла». 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.30 «Кеше һәм закон». 20.00 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Телесериал: «Камо Грядеши». 22.40 «Юрамалар». 23.00 «Караш». 23.50 XIX халыкара Мәскәү кинофестивален ябу. 0.50 Музыкаль күзәтү. Төнге канал: 1.50 Телесериал: «Тень, или Может быть, все обойдется». 2 нче серия. 2.55 «Спорт-дайджест». 3.15 «Хит-конвейер». 3.45 «Вадим Казаченко җырлый».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Хакыйкать мизгеле». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Телегазета». 11.10 «Музыкаль экспромт». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сәүдә йорты». 11.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Көнгерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Яңа тармак». 17.50 Нәфис фильм: «Двойной обмен». 19.25 Мульти-пульти. 19.40 «Кайнар уңлык». 20.25 «ЭКС». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Шәһәрчек». 22.05 «К-2» тәкъдим итә: «Перпендикуляр кино». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 «Кинофестиваль хәбәрчесе». 0.00 «Аерылышуларга ышанма, картлач». Ю.Визбор.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 «Төш юрау». 10.35 «Кумирлар». 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм. 13.35 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50 «Музыка мизгеле». 14.00 «10 канун». 14.30 Режиссер В.Виноградов фильмнары: «Взгляд». 15.00 Нәфис телефильм: «Подзорная труба». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 22.40 ТВ мәгълүматлары. 15.40 «Музыка мизгеле». 15.45 Нәфис фильм: «Стрекоза». 17.20 «Информ ТВ — Европа калейдоскобы». 22.25 «Иминлек телехезмәте». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Нәфис фильм: «Католики».

ШИМБӘ 29 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 – 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Өй академиясе». 19.45 «Әлли-бәлли-бәү». 19.55 Г.Ахунов. «Габбас хәзрәт». Телеспектакль. 6 нчы бүлек. 21.35 Чуваш җырлары фестивале. 22.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.15 Эфирда — музыка. 7.30 «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (28 июль тапшыруын кабатлау). Узган атна тапшырулары: 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (25 июль көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Видеомода». 8.55 «Артмобиль». 9.25 «700 нче клуб». «Җаваплар». 9.55 «Казан автосалоны». 10.25 «Үз кешеләр». 11.00 «Без сайлыйбыз». 11.20 Эфирда — музыка. 11.30 Нәфис фильм: «Али-баба и сорок разбойников» (АКШ). 13.00 Документаль фильм: «Этот трясущийся мир».13.55 «Режиссер И.Хейфиц». 14.15 «Р.Немчинская — цирк артисты». 14.50 Нәфис фильм: «Через тернии к звездам». 1 нче, 2 нче серияләр. 17.10 Телесериал: «Тропическая жара». 18.05 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ).22.25 Настассия Кински «Гарем» нәфис фильмында.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.30 — Яңалыклар. 9.20 «Джунгли чакыруы».9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.25 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.15 «Сәламәтлек». 11.45 «Провинция». 12.15 «Бомонд». 12.30 Нәфис фильм: «Кубанские казаки». 14.30 «Көзге». 15.20 «Зур узышлар». 15.50 Музыкаль программа: «Йолдызлы дулкын». 16.35 «Хайваннар дөньясында». 17.10 «Алтын кадр». И.Андроников. 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.25 «Брейн-ринг». 19.15 Кристофер Ламберт «Почему Я?» комедиясендә (АКШ). 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Телесериал: «Камо Грядеши». 22.40 «Оба-на». 23.25 Велосипедта узышу. Мәскәү Кремле әйләнәсендә Мастер Критериум. 0.05 «Һәркемнең телендә». Төнге канал: 0.55 Телевизион нәфис фильм: «Летучая мышь». 1 нче серия. 2.00 И.Лученокның иҗат кичәсе.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Шөрептән башлап». 8.45 «Беренче дубль». 9.00 «Винил джунглилары». 9.30 Пилигрим». 10.15 «Парламент атнасы». 11.00 Документаль фильм: «Никас Сафронов». 11.25 «Ничек яшәрбез?» 12.10 Нәфис фильм: «Тайна Королевы Анны, или Мушкетеры тридцать лет спустя». 13.30 «Дөнья экраны йолдызлары». 14.20 «Де-факто». 14.35 Нәфис фильм: «Револьвер Мегрэ». 15.20 «Август аенда кино». 15.30 «Хайваннар дөньясында». 16.25 Информацион-нәфис программа: «Фаэтон». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. «Спартак» (Мәскәү) — «Жемчужина» (Сочи). 18.55 «Шарман-шоу». 20.25 Нәфис фильм: «След дождя». 22.05 «Үтә яшерен». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Кинофестиваль хәбәрчесе». 0.10 «А» программасы. 1.10 «Төнге сөйләшү». 1.15 Өлкәннәр өчен мультфильм: «Декамерон».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Нәфис фильм: «Черный принц Аджуба». 11.20 Мультфильм. 11.45 «10 канун». 12.15 А.С.Пушкин. «Евгений Онегин». 13.35 «Рандеву». Татьяна Буланова. 14.05 «Теледоктор». 14.25 «Тарихи альманах». 14.55 Нәфис фильм: «Ярослав Мудрый». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 17.25 Документаль фильм: «Объектив». «Флоту быть». 18.20 «Әкият артыннан әкият». 22.25 «Санкт-Петербург» телевидениесе. 22.40 ТВ мәгълүматлары. 23.00 Нәфис фильм: «Не сошлись характерами». 0.15 Музыкаль шоу: «Кул чабыш».

ЯКШӘМБЕ 30 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.10 Мультфильмнар. 18.40 Балалар өчен фильм: «Калоши счастья». 20.00 «Телевизион буклет». Тапшыру анонслары. 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 Чуваш җырлары фестивале. 20.50 «Бер көрәшү — үзе бер гомер». Аксубай районы. 22.45 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

8.00 Эфирда — музыка. 8.10 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). Узган атна тапшырулары: 10.00 Коммерция әйләнмәсе (27 июль тапшыруын кабатлау). 10.25 «Ушуайя». 10.45 «Мавыгулар дөньясы». 11.15 Юмористик программа: «Бөтен җирдә су...» 11.35 «Суперспорт». 11.55 Эфирда — музыка. 12.05 Нәфис фильм: «Багдадский вор» (Бөекбритания). 13.50 Документаль фильм: «Юрий Завадский». 14.50 «Җир нинчек эшли». 15.40 Мультфильмнар: «Василиса Прекрасная, «Василиса Микулишна». 16.15 Телесериал: «Тропическая жара». 17.20 Нәфис фильм: «Русалочка». 18.40 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.35 Эфирда — музыка. 19.45 «КиноМеню». 20.20 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.30 «Без бергә!» Америка телевидениесе хезмәткәрләре Татарстанда. 20.55 Нәфис фильм: «Риск без контакта». 22.20 «Исәнмесез!» (29 июль тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 0.40 — Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультсериал: «Утастик». 10.15 «Бар да өйдә чакта». 10.45 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». 12.05 Тележурнал: «Бөтендөнья географиясе». 12.50 «Бөтен Россия». Исәнмесез. 13.20 «Безгә һәм безнең балаларыбызга». 13.45 «50 ел элек бу көннәрдә». 14.00 «Пи» билгесе астында. 14.45 «Төшке ашка — спорт». 15.20 «Эфирда «Музыка». 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.00 Америка М.Таратута белән. 17.25 Мультсериал: «Доктор Айболит». 18.00 «Вакыт». 18.20 «Көмеш шар». Е.Евстигнеев. 19.00 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Кумирлар, кумирлар...» Лариса Долина. 20.15 Мадонна «Шанхайский сюрприз» фильмында (АКШ). 22.00 «Якшәмбе». 22.50 Футбол буенча халыкара турнирның финал матчы. Төнге канал: 1.05 «Минем белән җырла». 1.25 Телевизион нәфис фильм: «Летучая мышь». 2.35 «Көлке панорамасы».

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Документаль фильмнар. 9.00 «Озынайтылган көн». 9.30 «Футболга чикләр юк». 10.15 «Хәерле иртә». 10.45 «Аты, баты...» 11.15 «Консолидация». 11.20 «Рус лотосы». 12.05 Документаль фильм: «Три столетия славы: Флоту быть». 13.25 «Клип-антракт». 13.45 «Сезнең партнер». Россиянең тимер юллары. 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык». 14.35 Нәфис фильм: «Револьвер Мегрэ». 15.30 «Синең мөмкинлекләрең, кеше». 16.00 «Формула-1» классында автоузышлар буенча дөнья чемпионаты. Германия гран-прие. 18.00 Диснейның тылсымлы дөньясы. «Русалочка». «Новые приключения Винни Пуха». 19.00 «Йолдызлы яңгыр». 20.25 Нәфис фильм: «Рай». 22.25 «Ксюшада кунакта». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Тапшырулар тартмасы». 23.55 Э.Радзинский программасы: «Мәхәббәт табышмагы». 0.25 «Шәхси коллекция».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Нәфис фильм: «Черный принц Аджуба». 11.30 «10 канун». 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 «Карарбыз». 13.25 «Парадлар парады» МФ-3 группасын тәкъдим итә. 14.10 Телефильм: «Русская пастораль». 14.30 «Классика-5». 15.30 Депутатларга сүз бирәбез. 16.00 Мультфильм. 16.15 Нахимовчылар җырлыйлар һәм уйныйлар. 16.45 «Класс». «Беренче оптимист-класс». 17.15 «Ватан даны өчен». 22.45 «Санкт-Петербург» телевидениесе. 23.40 ТВ мәгълүматлары. 23.50 «Адәм һәм Хава плюс».

ДҮШӘМБЕ, 24 ИЮЛЬ

6.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.45 Татарча өйрәнәбез. 6.53 Һава торышы. 6.55 Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 14.00. Радио-1. А.Леман әсәрләре. Татарстан радиосы. 17.45 «Язучылар — балаларга». 18.30 Радио-1. 19.15 Соңгы хәбәрләр. 19.45 Һәвәскәр башкаручылар концерты. 20.45 Татарча өйрәнәбез. 20.53 Тапшырулар программасы, һава торышы. 21.00 Радио-1.

СИШӘМБЕ, 25 ИЮЛЬ

6.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.45 Татарча өйрәнәбез. 6.53 Һава торышы. 6.55 Белдерүләр. 7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.25 Тапшырулар программасы. 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.05 Соңгы хәбәрләр. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.25 Һава торышы. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 Радио фондыннан. «Соңгы очрашу». М.Мәһдиев белән әңгәмә. 14.30 Радио-1. 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темаларына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 18.30 Радио-1. 19.15 Соңгы хәбәрләр. 19.45 Л.Шагыйрьҗан һәм Ш.Җиһангирова шигырьләренә язылган җырлар. 20.45 Татарча өйрәнәбез. 20.53 Тапшырулар программасы, һава торышы. 21.00 Радио-1.

ЧӘРШӘМБЕ, 26 ИЮЛЬ

6.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.45 Татарча өйрәнәбез. 6.53 Һава торышы. 6.55 Белдерүләр. 7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 12.25—13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.25 Тапшырулар программасы. 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.05 Соңгы хәбәрләр. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.25 Һава торышы. 13.30 Радио-1. 18.00 «Кардәшлеккә чикләр юк». 18.30 Радио-1. 19.15 Соңгы хәбәрләр. 19.45 Сораулар буенча концерт. 20.43 Татарча өйрәнәбез. 20.53 Тапшырулар программасы, һава торышы. 21.00 Радио-1.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 27 ИЮЛЬ

6.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.43 Татарча өйрәнәбез. 6.53 Һава торышы. 6.55 Белдерүләр. 7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 12.25—14.30 — «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.25 Тапшырулар программасы. 12.30 «Балалар җырлый». 13.05 Соңгы хәбәрләр. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.25 Һава торышы. 13.30 Д.Зөбәерова. «Куш өянке шаһит». Радиопостановка. 14.30 Радио-1. 18.05 «Радио фондыннан». И.Гази. Хикәяләр. 18.30 «Радио-1». 19.15 Соңгы хәбәрләр. 19.45 Н.Җиһанов. «Түләк һәм Су-Слу» операсыннан фрагментлар. 20.50 Татарча өйрәнәбез. 20.58 Тапшырулар программасы, һава торышы. 21.05 Радио-1.

ЖОМГА, 28 ИЮЛЬ

6.00 «Балкыш», 6.43 Татарча өйрәнәбез. 6.53 Һава торышы. 6.55 Белдерүләр. 7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 12.25—13.30 — «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.25 Тапшырулар программасы. 12.30 Нажия Теркулова концерты. 13.05 Соңгы хәбәрләр. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.25 Һава торышы. 13.30 Радио-1. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 18.30 Радио-1. 19.15 Соңгы хәбәрләр. 19.45 Популяр музыка концерты. 20.45 «Татарча өйрәнәбез». 20.53 Тапшырулар программасы, һава торышы. 21.00 Радио-1.

ШИМБӘ, 29 ИЮЛЬ

6.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58 Һава торышы. 7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 8.15 «Сезнең хатларыгыз». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Катнашу». Әдәби редакция программасы. 9.30 «Мирас». 10.10 «Сезнең китап киштәләрегезгә». 10.30 Ж.Дәрзаман. «Нур-Заде». Әкият-поэма. 11.00 Радио-1. 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 Рәшит Әхмәтҗан. «Аучылар кибетендә». Радиокомпозиция. 14.00 «Әбугалисина клубы». 14.30 Тапшырулар программасы, һава торышы. 14.35 Радио-1.

ЯКШӘМБЕ, 30 ИЮЛЬ

7.00 Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 7.58 Һава торышы. 8.00 Радио-1. 9.00 «Малайларга, кызларга». 9.30 «Игелекле хезмәттә үткән гомер». Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Госман Әхмәтҗанга 70 яшь. 10.15 Радио-1. 11.45 «Яктылыкны һәм изгелекне яклап». Өлкәннәр һәм балалар өчен программа. 12.15 «Тел күрке сүз». 12.45 Ял концерты. 13.40 Тапшырулар программасы, һава торышы. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.15 «Илһам». Шагыйрь Марсель Галиевнең иҗат кичәсе (трансляция буенча язма). 16.00 Радио-1.

НИШЛӘВЕГЕЗ БУ, ЕГЕТЛӘР?!

(Ахыры. Башы 8,9 нчы битләрдә.)

Рәшит Әхмәтҗановны мин соңгы тапкыр 1994 елның 27 декабрендә күрдем. Эшкә барган идем. Нәкъ элеккечә: «Ниләр язасың, Рәшит?» — дип сорадым.

— Әй, Кояш-дус килгән! Язам гынамы соң — шигырьләрем журналда басылып ята, инде корректурасы килде, тыңла! — диде дә, мең кеше йөреп торган корректорларыбыз бүлмәсенең ишек төбендәге урындыгына чүмәшеп, укый башлады:

Дәшәрмен тегә дөньядан:
«Без һаман дамы бергә? —
Бергәме?! Үлмә, бәгырем!
Мин кердем синең гүргә...»

Рәшит соңгы чакта үлем, гүр кебек кирәкмәгән нәрсәләр турында ешрак сөйләнә башлаган иде. Тагын шул. Ачуым чыкты:

— Тапкансың язар нәрсә! Матурлык хакындарак уйлап яз әле, шомлысы синең шигырьләрдән башка да — буа буарлык! — дидем дә, башкасын тыңламас булдым.

Яңа 1995 ел туды. Беренче көннең таңында ук телефоныбыз шалтырады.

— Котлыйм, дуслар! — ди Рәшит. — Йокыгыздан бүлдемме?

— Нинди йокы инде, Рәшит. Котлавың өчен рәхмәт! Яңа елны ничек каршы алдың? — дим.

— Безгә артистка Асия Галиева килергә тиеш иде. Шуны каршыларга чыгып, аймылыш булдык. Ике сәгать урамда басып тордым, туңдым, мин гел туңам бит...

— Килдеме соң Асия ханым?

— Ул, адашып, кире кайтып киткән. Хатыным такси белән барып алды, — ди.

Көлештек. Бу сөйләшүебез әле кешечәрәк булды. Ә соңгысын искә төшерүе дә авыр. Гыйнвар башында кешеләр атна буе ял итте бит. Яңа ел бәйрәменә урысларның Раштуасы ялганды, эшләмичә ыгы-зыгы килеп, халык гел өендә ятты. 4 гыйнварның кичке ягында Рәшит кабат шалтырата.

— Кояш, мин үләм бит, — ди.

— Әй, Рәшит, синең бүтән эшең юк шул! — дим. Кем белә бит?! Кем белә аның шул сүзе хак сүз булып чыгасын?! — Минем монда өй тулы кунак, кухняда ашым ташый, үлми тор әле, яме! — дим.

Рәшит шаркылдап көлде: «Әле генә үлмиммени?» — ди.

— Соң, Рәшит, шулай дими ни диим, үлмичә калган кеше юк. Барыбыз да үләбез...

Мондый буш фәлсәфә сатып утырганчы, бөтен кухнясын, бөтен кунакларны ташлап, чыгып йөгергән булыр идем дә бит... Кем белә?! Икенче көнне, 5 гыйнварда Рәшитнең үлгәнлеген хәбәр иттеләр. Бәгырьне көйдереп яңгыраучы шигырьләре генә калды. Аның миңа багышланган «Җылы сүз» шигыре болай тәмамлана:

...Ул үзе дә анда орфиядәй,
Нәзек кенә шәлен ябынган;
Күзләребез сүнсә, сүз эзләгез
Без кабызган сихри янгыннан...

Мөхәммәт абый Мәһдиев турында әллә ни күп язмыйм. Аңа багышланган күп мәкаләләр чыгар әле. Ул, Такташ әйтмешли, тал чыбыгын Рәшит кебек үк артык күп ашамады бугай. Китапларны да, татарчалап-урысчалап, шактый бастырды, эше дә, чагыштырмача, тыныч иде. Аннары Гомәр ага Бәширов кебек мохтәрәм әдибебезнең кияве булу да аңа ниндидер бер терәк вазифасын үтәгәндер, могаен. Әмма, миңа калса, әле яши генә башлаган иде бит ул, яшьли, ифрат вакытсыз китте. Нәкъ үзе теләгәнчә, һичнәрсәне яшермичә язар көннәр туып кына килә бит әле. Ул исә... юк инде. Аның белән соңгы күрешүебез дә мәгънәсезрәк чыкты.

Язучылар берлегенә Төркия әдипләре килгән иде. Безне дә чакырдылар. Барсам, Мөхәммәт абый да шунда.

— И-и, Мөхәммәт абый, исәнмесез! Төркиягә баргансыз икән. Сәфәрләрегез котлы булсын! — дидем.

— Кем әйтте? — ди каләмдәшем.

Беләм инде: мактатасы килә. Чөнки Мәһдиев Төркиягә, башка язучылар кебек, өтелеп-төртелеп, кемнеңдер чакыруы буенча гына түгел, ә бик мәртәбәле дәүләткүләм мөһим делегация әгъзасы буларак барды. Аларның һәр адымын телевизордан күрсәтеп тордылар, Мөхәммәт абыйның чыгышларын яңгыраттылар. «Кем әйтте?» дип, ул миннән шул зур сәфәргә карата хуплау сүзләре көткәндер, мөгаен. Мин — юләр, гадәтемчә, кирегә тырнадым:

— Соң, Мөхәммәт абый, монда берәүнең дә әйтүе кирәкми — әнә бит, өстегезгә төрекләрнең күн тужуркасын кигәнсез. Хәзер инде аны ит чабучылар гына кия. Җитмәсә, бүген төрек язучылары белән очрашуга да шуны киеп килгәнсез. Алар, күз салуга ук, ә-ә, бу Казан төреге Истанбулның фәлән бәй кибетендәге иң арзанлы тужурканы алган икән, диячәкләр. Салып куегыз, ичмасам, — дим.

Мөхәммәт абый әле бу беренче сүзләрне дә уенга бормакчы булган иде:

— Слушай, анда безнең акчага башка әйбер алып булмый бит...

— Ник булмасын? — дип, мин һаман шул мәгънәсез бәхәсне дәвам итәрәм. — Әнә Ибраһим ага Нуруллин да, Тәүфикъ Әйди дә әллә ничә ручка алып кайттылар. Миңа да бүләк иттеләр. Башкалар шул күн бишмәткә ябыша. Язучы кешегә ручкадан да шәбрәк ни бар?

Ниһаять, Мөхәммәт абыемның ачуы чыкты:

— Беләсең килсә, анда ручка да бик кыйммәт, сиңа бүләк иткәннәре өчен үкенеп йөриләрдер әле, — диде. — Юньле бер сүз ишетермен, димә инде синнән!

Аңа нибары 65 тулган булган икән. Минем әтием дә шул яшьтәрәк вафат булган иде. Ул чакта миңа әтиемнән дә яшьрәк үлгән кеше юктыр кебек тоелган иде. Әҗәл өчен яшьлек тә, картлык та юк икән. Мин өлкәннәребезнең вафатын да бик авыр кичерәм. Ни дигән сүз ул — өлкәнлек. Адәм баласы бигрәк аз яши бит. Уйлап карагыз, башта сабыйлык белән ничә еллар уза, аннары җәфа чигә башлый: укый, һөнәргә өйрәнә, тормышын көйли, гаиләсен, йортын-фатирын булдыра, ачы тәэмин итәргә тырыша. Инде бары да булды, дигәндә, ул инде «өлкәнлек»кә чыга, янәсе, инде үлсә дә ярый. Юк, ярамый! Шул кадәр мәгънәсез, мантыйксыз яратылыш була алмый. Монда, бәлки, безнең иманнан яздырылуыбыз комачаулыйдыр. Ислам дине дөнья яратулышын, Җирдәге кешеләр гомерен бөтенләй башкача аңлата лабаса. Без бу Җиргә, бөтен яшәү шартлары булган Җиргә, сыналыр өчен генә җибәрелгәнбез. Чын тормыш Кыямәт көненнән соң, Җирдә калган гамәлләреңә имтихан тотканнан соң гына башлана. Нигә моңа ышанмаска?! Инде кайбер галимнәр дә әйтәләр: кеше организмы Җирдәге хәлләргә караганда күктәге үзгәрешләргә ныграк тартыла, аларны ул алдан сизә, тирәннәнрәк кичерә, димәк ки, кеше Җирдә түгел, күктә яратулган, диләр.

Кайберәүләр, әдәбият-мәдәният-сәнгать әһелләренең бик яшьли һәм күпләп вафат булуы хакында сүз кузгалса, озын-озак уйлап тормыйча: «Әй, алар юньле тормыш кичермиләр, эчәләр, тарталар, хатын аералар...», дип, яман гадәтләрне санап китәләр. Мин, бөтен җаваплылыгын үз өстемә алып, бу гаепләүләрне кире кагам. Безнең 25 тән нибары 19 га калган университет төркемебездәге егетләр эчми дә, тартмый да иде. Авызларына да алмадылар алар бу хәрәм нәрсәләрне. Бар кайгылары уку, өс-баш бөтенлеге, тамак туклыгы булды. Соңгы вакытта бөтен Русияне томалап алган эчкечелек баткаклыгына безнең буын һичнинди хәзерлексез, көтмәгәндә һәм, әлбәттә, һич тә теләмичә куып кертелде. Егетләребезнең вафатында төп сәбәпне мин җәмгыятьтәге коточкыч гаделсезлекләрдән күрәм. Барына да ихластан ышанып яшәгән нечкә күңелле, саф җанлы, мәдәни тәрбияле егетләребез гомерләре буена алданып яшәүләрен аңлагач... сындылар да куйдылар.

Сажидәкәй-күбәләк бер дә юкка гына өзгәләнеп яздымыни: «...Буйсындыр, ләкин сындырма! Буй-сыным — Агыйделдән!» Тик бу җан ачысы белән әйтелгән үтенечне ишетергә теләмәде җәмгыять, тотты да сындырды безнең ышанычны.

Әнә кайларга тоташа ул кара кабер юллары.

Мин шулай уйланам да, егетләребезнең безне ташлап китүләренең сәбәпләрен әллә кайлардан эзләргә тотынам. Ислам дине кануннарын Бакый ага яхшы белә иде. Берсендә ул әйтте: «Адәм балаларының язмышы — Аллаһы тәгалә карамагында. Без һәр көн үләргә әзер торырга тиешбез, әмма малны мәңгелеккә җитәрлек тупларга кирәк. Мал туплау — эшләү, хезмәт итү ул... — диде. Шушындыйрак акыл бирүче киңәшчеләребез дә булмаган, ичмасам. Барлары да бере артыннан бере китеп бара. Мәңгелеккә. Теләсәң чыда, теләсәң ела, теләсәң җырла. Беркөнне Георгий Ибушевның җырлавын ишетеп, иңрәп куйдым:

...Чәмчәп-чәмчәп камчы сугдем,
Үргән саен килде лә ой үрәсем;
Якты йөзле дусларымны
Күргән саен килә лә ой күрәсем.
Ак каеннан чаңгы юндым,
Шуармын дип, ой, биек
лә таулардан.
Сезнең кебек дусларымны
Эзләп-табып алыйм соң мин
кайлардан?..

Әҗәл дигән шәфкатьсезлек безне бер-беребезгә игътибарлырак, ягымлырак булырга өйрәтсен иде. Юк бит бездә шул гадәт. Өйрәтелмәгәнбез. Мин озаграк йөрелгән командировкалардан соң, өйгә кайтып кергәч, әниемне кочаклап-үбеп күрешергә ярата идем. Әни исә, бахыр, этеп җибәрә: «Кит инде, марҗалар кебек чупыр-чупыр үбешмик, бәбкәм!» — ди торган иде. Ул ятакка егылгач, эштән кайтуыма, иң беренче аның янына килеп, бит алмасыннан үбеп ала торган булдым. Бусында әнием ачуланмый иде инде: «И-и, бәбкәм, исән-сау кайткансың, Аллага шөкер!» — дип, канәгатьлеген аңлата. Күрәсең, җылы мөнәсәбәт аңа рәхәтлек биргән, тик аны сиздермичә, әйтмичә генә гомер уздырган ул. Үзебез дә шул бит. Гөр-гөр килеп яшисе урынга, очрашу белән бер-беребезне мыскыл итәргә, тузга язмаган сүз әйтеп, кешенең «җенен чыгарырга» тотынабыз. Әле чит ил фильмнарын караштырам да хәйран калам. Анда кешеләрнең бер-берсенә: «Мин сине бик яратам, һәрчак яратачакмын!» — димәгән минутлары юк. Шул сүзне ишетеп тору кемгә рәхәт түгел инде?! Без шул алай тәрбияләнмәгән. Югыйсә, бүген — бар, иртәгә — юк бит инде без. Аңларга бик вакыт, шуңа төшенеп, һәр минутны, һәр дусның кадерен белергә бик кирәк.

Үлем турында уйланганда, күңелем түрендә Марсель Галиевнең бер шигыре баш калкыта. Бу дустым да соңгы мизгелләр турында күп уйлана, күрәсең. Озаграк сөйләшеп утырырга туры килсә, мин аңардан: «Марсель, укы әле теге шигыреңне!»— дип үтенәм. Кайсы шигырь турында сүз барганын ул яхшы белә. Карашын аска төбидә сабыр гына башлап җибәрә, бераздан аның күзләрендә дым ялтырый башлый, мин яшермичә-нитмичә елап утырам. Белмим, берәр басмада чыкты микән аның ул шигыре, юк микән? Менә мин күңелемнән язарга булдым, укып карагыз әле.

...Җирдә урын кысанырак бугай:
Бу гомернең уйлыйм соң мәлен;
Кайгы белән сезне мәшәкатьләп,
Мин, ахыры, Җирдә үлмәмен.
Уйнап-көлеп кенә хушлашырбыз.
Вакыт булыр,
Бер алманы бишкә бүләргә
Самолетлар очмас,
Сез китәрсез кайтып өйләргә.
Мин калырмын ялгыз гына
көтеп.
Ачылыр да һава юллары
Ак канатлар күтәрерләр мине
Мең борчулы Җирдән югары!
Болытлардан өстә кабул итеп
Көтелмәгән язмыш карарын,
Яшәү дигән бөек газапка мин
Менә шунда җавап табармын.
Тик, кызганыч, соңгы ачышымны
Сезгә инде яза алмамын. —
Сез калырсыз уртак хыял белән,
Тормыштан күп кызык
табарсыз!..
Бер сүз аша мин хәтергә төшсәм,
Йолдыз арасына карарсыз!..

Адәм баласының күңеле күкләргә тартылуга менә тагын бер мисал инде. Шигъри мисал, минем күңелемә дә бик хуш килә торган мисал бу. Ислам дине — иң шәфкатьле дин. Ул адәм балаларын, сиңа Аллаһы тәгалә җәннәт әзерләп куйган, мәңгелек җәннәт, дип тәкрарлый. Шуңа күрә әҗәлдән курыкмаска, Җирдә күбрәк яхшылык кылып, үзеңне мәңгелеккә әзерләргә өнди. Мөселман кешесенең вафатын ишеткәч тә, бәргәләнеп еларга түгел, иплән кенә: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», дип, дога кылырга куша. Мәгънәсе: һәммәбезне Син яраткансың, һәммәбез кабаттан Синең тарафыңа кайтабыз.

Якыннарымны югалтудан чарасызлык чоңгылына тәгәрәвемне сизгәндә, мин хәзер шул сүзләрне кабатлыйм. Мәрхүмнәребезнең авыр туфраклары җиңел булсын! Тик шулай да Җирдәге мөмкинлектән кешеләрчә файдаланырга, матур, тату, гадел иттереп яшәргә иде әле, егетләр!

«Казан утлары»нда эшләгән чакта, һич гаепсезгә, бик нык рәнҗетелүемне ишетеп, Нәкый ага Исәнбәт мине өенә чакыртып алды да әйтте:

— Кызым, гомер кыскарта торган яман хәлләр шаукымын күзләрең-колакларыңнан ары үткәрмә, бәгыреңне таламасыннар, — диде. — Баш белән йөрәкне сакларга кирәк!..

Аксакалның шул киңәшен барлык замандашларыма ишеттерәсем килә: кулдан килгәнчә, саклыйк әле, дусларым, баш белән йөрәкләребезне, саклыйк әле!

Мөхәррир мөнбәре

N29, 1025

Каләм изгегә тартыр



(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шулай да бүгенге каршылыклы дәвердә мәдәниятне үзәккә алып яктыртучы матбугат мәйданының пәйда булуын бары тик яхшыга гына юрыйсы, талчыккан елмаю белән егерменче гасырга горур рәвештә атлаучы милләтебезнең киләчәк язмышы хакына дәүләт мәнфәгатьләреннән чыгып гамәл кылучыларга ихлас рәхмәт кенә күндерәсе килә. Зур сәяси-иҗтимагый әһәмияткә ия булган әлеге вакыйга зирәклегебез дәлиле төсендә тарих битләренә язылып калсын.

Мансуров

Үзенең бәһаләп бетергесез рухи маясы җәһәтеннән татар халкы махсус мәдәни газета чыгарырга күптәннән өзер иде. Тырбайчыклык галәмәте булмасын: мондый элитар көндәлек басма чыгара башларга, бәлки, теләсә нинди халык вәкилләре җөрьәт итмәстер. «Аз санлы»лар рәтендә саналсаң, бигрәк тә, чөнки бәлеш табадан зуррак була алмый.

Бүгенге бәйрәм вакыйгасы, әйе, очраклы вакыйга түгелдер. Өстәвенә, Татарстанның мөстәкыйльлек юлын сайлавы да аңа зарурият дәрәҗәсендәге өстәмә вазифалар йөкли. Әйтик, суверен дәүләткә Төп закон, флаг, герб, гимн ише атрибутлар тиеш булган кебек, безгә үзебезнең киностудия, фәннәр академиясе, милли университет... махсус басмалар да кирәк. Иншалла, зыялыларыбыз еллар үзенендә сүнеп калган «Әльислах»лар учагын яңача тергезеп, басма сүзгә табынуны элекке халәтенә кайтарырлар. Татар доньясында әлегә берданбер булган бу уникаль басма халкыбызның мәдәнилек дәрәҗәсен атна саен җиһанга күрсәтеп торсын.

Әдәплелек, зирәклек, иманлылыкка ихтыяҗ зур булган хәзерге катлаулы чорда «Мәдәни җомга» иҗат әһелләренең биниһая бәрәкәтле көч-куәтен туган халкыбызга, җөмһүриятебез тәрәккыенә хезмәт иттерүгә юнәлтсен иде. Хөрмәтле каләмдәшләр! Инде дистәләрчә айлар дәвамында бәяләрнең өзлексез күтәрелүеннән, һәрторле тетрәнүләрдән, афәт-фаҗигаләрдән тәмам йончыган халык бездән күңелгә өмет-ышаныч иңдерерлек шифалы сүзләр көтә, милли яңарыш, икътисад үзгәрешләре куласасына таяк тыгып, болганчык суда балык тотучы сорыкортларны кояш астына бер-бер артлы чыгаруыбызны тели. Соңгы вакытта бераз таркала төшкән сафыбызны «Мәдәни җомга» хакыйкатькә, игелек, матурлыкка төбәлгән олуг максатларга туплаясын. Башка халыклар үзләренең файдасына зур-зур кальгалар алганда, «татарланып», тар казаныбызда тарткалашып ятмыйк. Бәгъзеләребезнең куенында таш булса, аны яңа туган газетаның нигезенә салу хәерлерәк. Мондый ташлардан гыйбадәтханәләр калыксын. Каләмебез гелән изгегә тартсын. Бер әдибебез әйтмешли, һич югында язу өстәлебез биеклегеннән төшмәскә иде. Без, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, үзебезне Күк белән сөйләшүче затлар итеп саныйбыз икән, шуны һәрдаим истә тотарга тиешбез: пәйгамбәрләр арасында «суллар» белән «уңнар» да, «либераллар» белән «консерваторлар» да була алмый. Мәдәният узгынчы сәясәтләрдән өстенрәк.

Мәгълүм ки, язышып торучы авторларсыз берниндн матбугат басмасы да яши алмый. Мөхтәрәм каләм осталары, мәдәният әһелләре, сәнгать белгечләре, галимнәр! Дистәләрчә еллар буе зарыгып көткән вакыт сәгате сугып, доньяга үз сүзегезне даими ишеттерү өчен заман тарафыннан янә бер мөмкинлек бирелде, һәм шул ук вакытта сезгә тагын бер җаваплы миссия өстәлде: яшәтик «Мәдәни җомга»ны, кулыбыздагы шушы басманы татарның йөз аклыгына, зыялылар тәрбияләү мәктәбенә әверелдерик. Атналыкның озын гомерле булуы сездән тора! Беренче саныннан аның мәсләк-кыйбласы бераз күзалланадыр. Иҗтиһат итик. Даһи хәлфәбез Габдулла Тукай сүзләрен кабатлап әйткәндә, «Безнең мәйданымыз милләт каһарманнарының мөбарәзәсе (бергә-бер чыгып көрәшүе. — **З.М.**) өчен ачыктыр. Килсеннәр, ул шанлы вә намле каләмнәрен уйнатсыннар!.. Языңыз, языйк, таратыйк, гамәле исламга нур сачик, нурланыйк, тырышыйк!»

Кадерле мөштәриләр-газета укучылар! Ташка басылган сүзгә элек-электән мөкиббән булган халыкның балалары икәнлегегезне раслап, яңа газетаны киләчәктә дә элемтәчеләребез аша алдырып укырсыз дип ышанабыз. Басманың беренче тарихи саны кулларына килеп эләккән милләттәшләребез игътибарына:

«Татарстан хәбәрләре» җирлегендә оештырылган
«Мәдәни җомга»га язылу дәвам итә.
Газетаның индексы — 54129.
Дүрт айлык бәясе — нибары 8 мең 800 сум.

Яңа газета сезне һәрьяктан канәгатьләндерер, өегезне тагын да нурландырып җибәрер.

Изге җомга көнне озын сәфәргә чыктык. Хәерле сәгатьтә, ватандашлар!

Зиннур МАНСУРОВ.

Яшь музыкант, «Яңа исемнәр» Халыкара хәйрия программасы стипендиаты Муса МАЛИКОВ:

Яңа газетада исемнәр иҗатына игътибар булыр дип ышанабыз: Аңа теләгебез изге. Мин яшә, „Мәдәни җомга"! Муса Маликов 1995 июль.

ЯҢА ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ БАРА

— Нәфсең ни теләде, Тукаев әфәнде?
— «Мәдәни җомга» йөзенә бер карар идем...

Кысла һәм Арыслан йолдызлыклары астында туганнар

21 июль — Хәйруллина Асия Хәсән кызы — Татарстанның атказанган артисты, педагог, **Әхтәмова** Фирдәвес Кыям кызы — Татарстанның атказанган артисты; **22 июль — Галиуллин** Тәлгать Нәби улы — галим, язучы, педагог; **23 июль — Гәрәев** Мәхмүт Әхмәт улы — хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире; **26 июль — Муллин** Ростәм Хан улы — Татарстанның атказанган артисты; **27 июль — Васильев** Владимир Михайлович — РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының баш дирижеры, **Галиев** Фәнил Ислам улы — язучы, юрист, **Ибраһимов** Рәшит Габдрахман улы — язучы, очучы, **Сәнгатуллин** Хәмит Газиз улы — Татарстанның атказанган архитекторы, **Хәйретдинова** Клара Әкрам кызы — Татарстанның халык артисты.

Бу санда Ә.ШӘФИГУЛЛИН, Т.КАЗАКОВА, В.ЗОТОВ, М.ШАКИРҖАНОВ, Н.СЕДОВ, В.АБРОСИМОВ фотолары, Р.ШӘМСЕТДИНОВ, А.СӘГЫЙТОВ, Р.ХӘСӘНШИН, А.ҮТӘГӘНОВ рәсемнәре файдаланылды.

«Мәдәни җомга»
Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасары Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-06-76 — баш мөхәррир урынбасары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-66-22 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-59-22 — әдәбият бүлеге;
32-57-48 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау, хатлар бүлеге;
32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
609403 МФО 265566
в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы:
420503, Казан,
Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 14000
Заказ